Безнең Мирас

ISSN:2500-011x

06

июнь 2016

ФӘННИ-ПОПУЛЯР, ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ДОКУМЕНТАЛЬ ЖУРНАЛ

ТАРИХИ, МӘДӘНИ, ПЕДАГОГИК, ДИНИ МИРАС, ТӨПЛЕ ФАРАЗ, ӘДӘБИЯТ ҖӘҮҺӘРЛӘРЕ

21 майда «Изге Болгар җыены»нда Болгар ислам академиясе нигезенә беренче истәлек ташын салу тантанасы булды. Мәгълүм ки, 922 елның нәкъ менә шушы көнендә Идел буе Болгар дәүләтендә рәсми рәвештә ислам дине кабул ителә.

Изге Болгарда – ислам академиясе!

Фотолар president.tatarstan.ru сайтыннан алынды.

*Болгар ислам академиясен төзи башлау тантанасында катнашучыларның КИЛӘЧӘК БУЫННАРГА МӨРӘҖӘГАТЕ*н *ошбу санның* ***43 нче битеннән*** *укый аласыз.*

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.

Дәрдемәнд

Безнең МИРАС 12 +

6(53)
июнь 2016

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.



14

64 ХАТИРӘЛӘР КАЙТА ЯҢАРЫП...
Дания Гайнетдинова

106 «ӘБИ ПАТША» КАРЕТАСЫ.
Гүзәлия Җәләлева

ЭЧТӘЛЕК

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 **Тәүфикъ Әйди**

ТАРИХИ МИРАС

6 **Болгар. Ханнар төрбәсе.** *Н.Шәйдуллина*
8 **Чыңгызхан хәйләсе.** *Ә.Мөхәммәдиев*
14 **Казанның беренче ханнары.** *Ә.Әхсәнов*
18 **«Шенас» – кызыксынучан акыл.** *Л.Мортазина*

ТАТАР ГАМЕ

28 **Мөхәммәдьярларга тиң шәхес.** *Х.Миңнегулов*

ПЕДАГОГИК МИРАС

36 **Кыз балаларга тәрбия бирү хакында.** *Т.Биктимерова*

ДИНИ МИРАС

40 **Шәех Хәбибулла кыйссасы.** *Т.Ялчыгол*
43 **Киләчәк буыннарга мөрәҗәгать**

ӘДӘБИ МИРАС

44 **Кутадгу билик. (Котайткыч белем).** *Й.Баласагуни*
48 **Шагыйрә Газизә Бәһаветдин кызы Сәмидова.** *Җ.Алмаз*
52 **Үтерүче.** *З.Ишаев*
64 **Хатирәләр кайта яңарып...** *Д.Гайнетдинова*
68 **Гомерлек иман.** *Л.Лерон*

СӘНГАТИ МИРАС

72 **Тетрәндереп киткән алиһә!** *Р.Сәгъди*

ОЧТЫ ДӨНЬЯ ЧИТЛЕГЕННӘН

79 **Нурихан Фәттах.** *Р.Фәттахова*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

82 **Әтине бер күрдем... төшемдә...** *Ә.Шәрипов*

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ
(Ләбиб ЛЕРОН)
(843) 222-09-83 (17-91)

Баш мөхәррир урынбасары-
җаваплы сәркатип
Марат Закиров
(Марат Закир)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә
Разил Вәлиев
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Илдар Гыйльметдинов
(Татар федераль милли-мәдәни автономиясе Советы рәисе)
Айрат Зарипов
(Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча Республика агентлыгы җитәкчесе)
Андрей Кузьмин
(«ТАТМЕДИА» АҖ генераль директоры)
Рөстәм Мөхәммәдиев
(«Татнефть» ААҖ генераль директоры урынбасары, «Рухият» фонды рәисе)
Айрат Сибагатуллин
(ТР мәдәният министры)
Энгель Фәттахов
(ТР премьер-министры урынбасары – ТР фән һәм мәгариф министры)

Редколлегия
Ислам Әхмәтҗанов
Марсель Әхмәтҗанов
Ирада Әюпова
Альберт Борһанов
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ринат Закиров
Зиннур Мансуров
Ким Миңнуллин
Гөлчәчәк Нәҗипова
Сөмбел Таишева
Рафаил Хәкимов
Ирек Шәрипов

Бүлек мөхәррирләре
Ленар Гобәйдуллин
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-90)

Дизайнер һәм биткә салучы
Диләрә Нәүрүзова
(843) 222-09-83 (17-92)

Корректор
Дания Фәйзуллина
(843) 222-09-83 (17-90)

Гомуми мәсьәләләр буенча мөхәррир
Рәдиф Сәгъдиев
(843) 222-09-83 (17-91)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре,
Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта:
yanamiras@mail.ru

«Наше наследие»
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал (на татарском языке)

87 **Гали ага киңәшләре...** *Р.Сафин*
89 **Әтиемнең фронт эзләреннән.** *А.Хәмзин*
97 **Афәт.** *Ә.Фәйзрахманов*

ХӘТЕР САГЫНДА

102 **Җәлил мирасы.** *Н.Фәттахова, Л.Харасова*
106 **«Әби патша» каретасы.** *Г.Җәләлева*

ТЕЛ КҮРКЕ – СҮЗ

108 **Миллият сүзлеге.** *А.Тимергалин*
111 **Сүзләр картаямы?..** *Р.Низами*

100 ЕЛ ЭЛЕК...

114 **«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның июнь ае.** *Л.Гобәйдуллин*

ШАЯН МИРАС

116 **Көлке куа килә...**

119 **Мирасворд**

120 **«Безнең мирас» елъязмасы.** *Июнь*

Заказ №М-1307. Тираж – 1700 данә. Формат 70 Х 108 1/16
Басарга кул куелды: 24.05.2016
Журнал айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле

Журнал 2012 елның 17 апрелендә
Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә
ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә килгән язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми. Бу хакта техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин төшергән, авторларның һәм Татарстан Милли музее архивларыннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан фотосурәтләр, җиде томлык «Татар тарихы»ннан рәсемнәр файдаланылды.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

Тышлыкның 1 нче битендә – «Болгар. Көнчыгыш төрбә». *(Фрагмент)*
Кәгазь, пастель. 2012 ел. *Фәрит Суюров рәсеме*

ТӘҮФИКЪ ӘЙДИ
(1941-2001)



«Милләткә яшәү дәртен анның иң алдынгы карашлы, тирән белемле, ата-баба васыятенә тугрылыклы, гореф-гадәт, йолаларга хөрмәтле, көчле ихтыярлы, намуслы һәм гайрәтле, эшлекле һәм кәсепчел өлеше бирә, гаммәне үз хосусиятләрен саклауга шул рухландыра, бүтән халыкларның кешелекле, саф хисле һәм зирәк акыллы катламы белән аңлашуга шул ирешә һәм дөньяда яшәүгә хокукы, дәрманы барлыгын исбатлап, төрле расага, дингә, телгә, культурага бүленгән кавемнәр арасында үзенә лаек урынны табып гомер итә. Башкаларны буйсындырырга һәм үз максатларында файдаланырга, аларның җирен-суын, хезмәт җимешләрен үзләштерергә теләгән илбасар менә ни өчен беренче нәүбәттә анның шул милли идеалны, яшәү рухын кадерләп саклаучы аңлы өлешен юк итәргә тырыша, анның урынына җиңелгән халык арасыннан кыйбласыз, имансыз, колларча куштан һәм ялагай, сатлыкҗаннарны үстерә һәм үзенә карусыз хезмәт иттерә».

(«Дунай буендагы кардәшләр»)

«Һәр милләт бәйсез дәүләтен төзергә омтыла, чөнки шул очракта гына ул үзе теләгәнчә иркле яшәргә һәм үсәргә мөмкин. Бу беренче нәүбәттә яшь буынны ата-баба рухы белән сугарып тәрбияләүдә, киңрәк алганда, милли мәктәп концепциясен гамәлгә ашыруда, аерым алганда исә, туган телне, әдәбият-сәнгатьне сабый күңеленә ана сөте белән үк салуда тормышка ашырыла. Тагын да бер әһәмиятлесе – өлкән буыннар тормышын, ата-баба хәтерен яңартып, мәктәптә милли тарихны өйрәнү. Камил акыллы кеше бары шулай гына тәрбияләнә ала.

Әлбәттә, бәйсез милләт милли тәрбия бирүне мәктәптән тыш та дәвам итә – сәнгать әсәрләре, этнографик, археологик тикшеренүләр, музейлар, театрлар, филармонияләр эшчәнлеге аша».

(«Гөлчәчәкләр иләндә кара болыт»)

«Бәйсез, иркле яшәү – һәр милләтнең татлы хыялы. Бәйсезлеген югалтмау өчен халыклар канкойгыч, фаҗигале сугышлар алып барудан да тайчанмыйлар».

(«Гөлчәчәкләр иләндә кара болыт»)

«Йола, гореф-гадәт законнан өстенрәк, чөнки алар әлгәрерәк барлыкка килгән, гасырлар кичеп сыналган, дөрес һәм гадел, файдалы һәм кирәкле булуы шик уятмый торган тотрыклы кыйммәткә әверелгән. Милли йолаларын һәм гореф-гадәтләрен кадерләп саклаучы халыкның гына киләчәге бар».

(«Кечкенә дә төш кенә»)

«Без озак еллар сәламәт әхлакны, шәфкатьне онытып, бер-беребезне сыйныфларга, акларга-кызылларга, ватанпәрвәрләргә-сатлыкларга бүлеп гаепләдек,

эзәрлекләдек, астык-кистек... Гасыр башында Тукай телгә алган ун-унбиш миллионнан тагын да үрчисе урында, без соңгы сиксән ел эчендә җиде миллионга калдык, анысының да әхлакый түбәнәюенә, рухи фәкыйрьләнүенә тәгәрәдек».

(«Йөртә безне язмышлар»)

«Гасырлар дәвамында без әдәбият, сәнгать, фән, сәясәт һәм башка тармакларга дистәләгән, йөзләгән олы шәхесләр үстереп биргәнбез, шулардан кайберләре, башка халыкларның рухи дөньясына, дәүләт идарәсенә үтеп кереп, гасырлар пәрдәсе аша бүген дә җемелдәп торган якты эз калдырган. Татарның милли горурлыгы үсүдән, димәк ки, аны милләт буларак юк итү эше кыенлашудан куркып, безгә озак вакытлар әлеге даһи шәхесләребез хакында авыз ачарга да ирек бирелми киленде. Андый шәхесләребезнең кискен бәрелешләргә бай, искиткеч тырышлык һәм киеренке хезмәт куеп казанган уңышларга, җиңешләргә мул гыйбрәтле тормышы – милләтебезнең киләчәккә бару юлында якты маяк, ышанычлы рухи терәк бит ул. Аның башкалардан һич тә ким түгеллеген, мәңге яшәргә тулы хакы барлыгын раслый торган дәлил! Шөкер, хәзер инде алар турында да иркенләп сүз алып бара башладык».

(«Аһ, туган каумем газиз!»)

«Республикабыз җитештерә торган байлык әз түгел, ләкин аның майлы калҗалары әле һаман шунда тир түгүчеләргә эләкми. Үз малыңа үзең хуҗа булмау, колониянең колы, авыр, кара эшләрне башкаручы алашасы гына хәлендә гомер сөрү аркасында бу».

(«Йөртә безне язмышлар»)

«Империячел аң һәм омтылышлар яралгы хәлендә һәр халыкта була. Күбрәк санлы халыкларда, элегрәк куәтле дәүләтләрен корган, бүтәннәрне талап, кысып яшәргә өлгергән кавемнәрдә инде империячел хисләр бигрәк тә куәтле була – алар, сөяктән аерылырга теләмәгән эт кебек, корбаннарын кулдан ычкындырмаска, ычкынган хәлдә, аны яңадан кайтарып алырга тырыша. Бу юлда алар һичбер әхлакны, халыкара килешүләрне танымый, алдашу, яла ягу, хыянәт, шәфкатьсезлек, икейөзлелекне эшкә җигә, көч куллануны иң гадәти гамәлгә әйләндерә».

(«Оҗмах утравы»)

«Теләсә кайсы халыкның милли горурлыгы басып алынган халыклар, илләр саны, җирләр күләме белән түгел, иҗади куәтенең гомумкешелеккә хезмәт иткән ачышлары, фән һәм мәдәният өлкәсендәге казанышлары белән бәяләнергә тиеш. Аның басып алынган халыкларның иҗади сәләтен, көчен буып торуын яки, гомумән, юкка чыгаруын да истә тоту хакыйкатькә, тарихи гаделлеккә каршы килмәячәк».

(«Гөлчәчәкләр илендә кара болыт»)

«Адәм баласының башка җан ияләреннән мөһим бер аермасы, өстенлеге – хәтерле булу. Бу аңа, үткән буыннарның тормыш тәҗрибәсен, казанышларын файдаланып, үз тереклеген югарырак баскычтан дәвам итәргә мөмкинлек бирә. Без, бүген яшәешебезнең мәгълүм бер әхлакка, тәртипкә нигезләнүе, матди һәм рухи яктан мулрак, мәгънәлерәк дәрәҗәгә күтәрелүе өчен, ата-бабаларыбызга бурычлы. Менә шуңа күрә татарда ким дигәндә җиде бабаңны белү, аларны хөрмәт белән искә алу гадәткә кергән.

Җиде бабаңны белү шул ук вакытта алардан үрчегән җиде буын нәселне – кардәшләреңне дә белү дигән сүз. Адәм баласы ялгыз яшәми, шатлыкта да, кайгыда да аңа иш-иптәш, таяныч кирәк. Иң ышанычлы иш, таяныч, – әлбәттә, кан кардәшләрең. Кан кардәшләргә, гадәттә, тел, гореф-гадәт, йола-зәвык, җыр уртаклыгы да хас. Уртаклык, охшашлыклар күп булган саен, бер-береңне аңлау, нәселдәшләрең белән тормыш авырлыкларын җиңү дә җиңелләя. Нык, ишле нәсел язмышның кар-бураннарын, җил-давылларын ансатрак кичә, үз йөзен әйбәтрәк саклый, димәк, сәламәт рухын, ирекле яшәү мөмкинлеген яхшырак тәэмин итә. Бары шул очракта гына адәм баласы рухи тынычлык, канәгатьлек, рәхәтлек тоя һәм сәләтен тулырак ачып алга бара».

(«Исәнме, Гагаузстан!»)

«Кеше берәр хәвеф-хәтәргә юлыкса, гадәттә, аңа иң әүвәл ярдәм кулын туганнары суза. Бу – милләтләр арасында да шулай. Мисалга урысларны гына алыйк. Алар кан кардәшләре болгарларга, сербларга һәм словакларга гасырлар дәвамында терәк булды, финнар – эстоннарга, эстоннар мариларга һәм удмуртларга булышып килә. Бу – бик табигый һәм әхлаклы бер эш. Әмма шушы матур гадәт соңгы дәвердә төрк халыклары арасында шактый ук җуелды».

(«Кардәшләр кочагында»)

«Югары мәдәнияткә, бай икътисадка ирешү өчен, төрк милләтләренең үз тарихи ватанында туган гореф-гадәт, йолалар, әхлакый кануннар кысасында гомер итүе шарт. Аерым шәхес, милләт, туган телен, мәдәниятен, милли холык-фигылен җуймыйча яшәгәндә, асыл сыйфатларын гармоник үстерә ала. Күнегелгән табигый тирәлектә генә тотрыклы рухи халәтне, яшәү дәртен һәм сәләтен саклау җиңел. Шундый шартларда шәхес тә, милләт тә төрле тетрәнүләрдән, тискәре комплекслардан азат була, гомер итүен билгеле бер тәртипкә салып, сәламәт тормышын көйләп җибәрә, башкалар тәҗрибәсен киң файдаланып, яңадан-яңа уңышларга ирешә».

(«Кардәшләр кочагында»)

«Төрк кавемнәренең бер-берсен йотуы – һәлакәтле күренеш. Безгә бер-беребезнең хосусиятләрен хөрмәт итәргә, көчле төрк халыклары бердәмлегенә күптөрлелек аркылы гына барырга кирәк. Кушылуны уңай, аерымлануны тискәре бәяләүчеләр – кешелек дөньясы үсешен тупикка кертүчеләр алар. Һәр шивә вәкиле, үз табигый микроклиматы, хосусиятләре нигезендә яшәгәндә генә, рухи комфорт тоя, шул очракта гына аның сәләте иркен, нормаль үсә. Күптөрлелек фикере, безгә үзара рәхәт, ансат аралашыр өчен, төрек телен өйрәнергә комачауламый. Уртак ата-бабаларыбыз рухы, ят халыклар чолганышында уртак мәнфәгатьләребезне саклар өчен берләшү ихтыяҗы – төрклекнең көчәюе өчен иң ышанычлы нигез һәм юнәлтүче чара. Без киләчәктә дә төрле булачакбыз, ләкин бер-беребез өчен җаныбызны да, каныбызны да бирергә әзер торачакбыз. Бары үз кавемең белән мавыгудан айну гомумтөрк мәнфәгатьләре өчен көрәштә соңгы киртәләрне алып ташлар, эчкерсез кардәшлеккә, дуслыкка, хезмәттәшлеккә киң юллар ачар».

(«Кардәшләр кочагында»)

Гыйбарәләрне ***Рөстәм Галиуллин*** *әзерләде.* ■

Болгар. Ханнар төрбәсе

Сәхифәне Нурсөя Шәйдуллина алып бара.

Кече манарадан төньяк юнәлештә өч төрбәнең хәрабәсе сакланган, аларның берсе *Ханнар төрбәсе* дип атала. Ханнар төрбәсе – XIV-XV гасыр башындагы архитектура биналары космплексының бер өлеше, бу биналар көнчыгыштан көнбатышка таба бер сызыкта ята. Алар XVIII гасыр чыганакларыннан мәгълүм. Комплекс археологлар тарафыннан 1914 елда һәм 1968-1969 елларда тикшерелгән. Төрбәнең янкормасында мич һәм җылылыкны идән астыннан алып баручы каналлар табылган. Төрбәдә консервация-реставрация эшләре 2005-2006 елларда үткәрелә.

Шул ук вакытта әлеге районда Кече манарадан көньякка һәм көнчыгышка таба, XIV гасыр ахыры-X гасыр башына караган архитектура корылмаларының нигезләре ачылган. Җылыту системасы калдыкларына караганда, алар төрле зурлыктагы төрбәләрдән генә түгел, башка максатларда кулланыла торган биналардан да гыйбарәт. Аларның барысына да консервация ясалган һәм алар карау өчен ачык. Төрбәләрнең таш биналары, алар эчендәге кирпечтән корылган кабер ташлары һәм төрбәләр моның аксөякләр төрбәсе булуы турында сөйли.

2011-2012 елларда реставрация ясаучылар төрбәнең көнбатыш һәм көнчыгыш өлешләренә соңрак куелган бетон блокларны һәм цемент ярдәмендә тезелгән кирпечләрне сүтте. Көнбатыш төрбәнең диварлары, киселгән таш тезеп, элек консервацияләнгән өлешкә тәңгәл итеп торгызылды. Көнчыгыш төрбә диварларын бут кирпеченнән төзеделәр. Үзәк төрбәнең гөмбәзен чистарттылар, комплексны чыланмый торган гидрофобия составлары белән эшкәрттеләр. ■

Чыңгызхан хәйләсе

Әзһәр Мөхәммәдиев

Көннәрнең берсендә Бибарс, тук-тук итеп шактый иртә үк шакыган тавыш ишетеп, капка биген чыгып ачты. Каршында басып торучы бай киемле ир-ат, аргамагының тезгенен Бибарска биреп:

– Җик әфәнде өйдәме? – дип сорады.

Остазын эшеннән бүлдерердәй түрәләрнең берсе иде булса кирәк ул... Бибарсның ни дип әйтергә дә белми торуын сизенеп, әлеге кеше:

– Вәзир Баттал йомыш белән килгән, дип әйт! – диде.

– Тыңлыйм, әфәндем!

Бибарс аргамакның тезгенен капка баганасындагы боҗрага бәйләп куйды да, ашыгып өйгә таба юнәлде. Ул да булмады, ишектән чигүле түбәтәен төзәтә-төзәтә чыгып килүче остаз үзе дә күренде, ике кулын сузып, кунак белән күреште.

Вәзир Баттал өялдына кереп, ашыкмый гына читеген салды һәм киез палас җәелгән түр якка – ирләр ягына узды.

Келәм җәелгән ян сәке буенда ачып куелган төрле китаплар, кәгазьләр яткан язу өстәле тора. Вәзир, сәкегә утырып, эченнән генә, иреннәрен кыймылдатып, дога укып алды. Аннары:

– Исән-имин генә яшисезме, Җик әфәнде, җәмәгатең, бала-чагаларың исән-саумы? – дип хәл-әхвәл сорашты.

– Иншаллаһ, сезнең хәер-фатихада, вәзир хәзрәтләре, рәхмәт! – диде дә Җик, Бибарска борылып: – Бар әле, улым, абыстаңа әйт, чәйгүнгә[1] күмер салып, чәй әзерләсен безгә, – дип өстәде.

Бераздан Бибарс, Рушания абыстаена ярдәм итеп, ялт итеп чистартылган, кайнап торган бакыр чәйгүнне күтәреп килеп кергәндә остаз Җик белән вәзир Баттал үзара кызышып ук гәпләшеп утыра иде инде. Баттал сүзен дәвам итеп:

– Син, Баян, күп илләрдә: Мисырда, Гыйракта, Сүриядә, Туранда һәм Иранда булган, күпне күргән, күпне белгән кеше. Әйт әле миңа, нигә дип бу болгавыр заманда Болгарга яңадан әйләнеп кайтып, дөнья көтәргә уйладың?

– Язмыш юллары бихисап күп, вәзир хәзрәтләре. Яшь вакытта читкә китү – офык артындагы яңа, билгесез һәм серле җирләрне күрергә омтылу – ул табигый нәрсә. Әмма дә, олыгайган саен, туган туфрактан да кадерлерәк, аннан да газизрәк, туган җир суыннан да тәмлерәк су булмаганлыгын тирәнрәк аңлый башлыйсың. Берәүләре бу уйларын тормышка ашыра – туган иленә кайта. Икенчеләренең

Башы журналның 2 нче санында.

[1] Формасы белән балчык чүлмәкне хәтерләткән, ләкин торбасы һәм аскы якта утлы күмер өчен җайланмасы булган, ә төбенә «А» хәрефен хәтерләткән болгар тамгасы сугылган мондый бакыр чәйгүнне (самоварны) без Мәскәү археологлары белән Бөрҗан шәһәрлеген казыганда табып алган идек (автор искәрмәсе).

сөякләре, кадерсезләнеп, ят җирләрдә ятып кала, нәсел-нәсәбе бетә...

Кунак белән хуҗа шулай тирләп-пешеп чәй эчеп утырган арада, чәй көйләп һәм ясап утырган Бибарс: «Бу зур түрәнең монда килүендә ниндиерәк сер ята икән соң?» – дип уйланды. Бибарсның соравына җавап биргәндәй, вәзир сүзен дәвам итеп:

– Әмиргә сәяхәтнамәң бик ошады, Җик әфәнде, – диде.

Остазның сагышлы күзләрендә бер генә мизгелгә горурлык чаткысы чагылып үтте.

– Рәхмәт, вәзир хәзрәтләре...

– Мангулларга багышланган һәр җөмләңдә аек фикерләү, остаз кулы, остазлык тәҗрибәсе сизелә. Бу начар түгел. Бик һәйбәт. Тик мәртәбәле урында гына утырырга лаеклы кеше, дип саныйм мин сине, Җик әфәнде.

– Мондый олуг фикерең белән мине бик тә зурлыйсың син, вәзир хәзрәтләре!

– Менә дөньялар бозылып тора бит әле, кем, Җик туган. Шәһри Болгар һәм, гомумән, Болгар йорты каршы тора алыр микән дәһшәтле мангул яуларына?

– Син бу мәсьәләдә күбрәк хәбәрдар, күбрәк беләсеңдер, дип уйлыйм, вәзир хәзрәт. Болгар чирүенең саны, коралланувы, аның өйрәтелүе серләре дә, мөгаен, сиңа мәгълүмдер...

– Анысы шулаен-шулай, Җик туган. Әмма чирү күплеге яисә корал җитәрлек булуы белән генә фикер йөртү дөрес булырмы икән? Күр, әнә, Хәрәзем шаһы Мөхәммәтне. Күпме халкы, чирүе, никадәрле таш кирмән-калалары бар иде. Әмма мангуллар аның кирмәннәрен җимертеп, ә үзен тәмам акылдан яздырып юк итте...

Бераз уйланып торганнан соң, вәзир, тәэсирләнеп китеп, сүзен дәвам итте:

– Шәһри Болгарга Чин вә Мачиннан[2], Хәрәземнән, Ираннан күп-күп сәүдәгәрләр йөрер иде... Хәрәзем шәһәрләре, Үргәнеч һәм Сәмәрканд җир белән тигезләнгәч, җимертелгәч, сәүдә юллары, кәрвансарайлар бетте вә хәзер сәүдәчелек тукталды диярлек...

– Көчне бары тик көч кенә җиңә ала, син аны яхшы беләсең, Баттал вәзир. Көч һәм кулга алырлык яңа корал вә бердәмлек мангулларны да җиңә алыр иде, иншаллаһ. Олуг Мөхәммәт шаһның дәүләтендә дә, чирүендә дә бердәмлек булмады. Һәр төмәнбашы, һәр шәһәр әмире үз белдеге белән эш итте. Җәләлетдин, атасы Олуг Мөхәммәт үлгәч, соң булса да, тимер тарбуслы[3] чирү төзеп, аерым кабиләләрне үзара берләштерә алды һәм мангулларга каршы тора алырлык көч туплады. Ләкин башбаштаклык, мангуллардан алган баскын малны бүлешә алмау вә үзара ызгыш-талаш аркасында, Чыңгыз хан аны яңадан җиңүгә ирешә.

– Дөрес фикерлисең, Җик әфәнде. Илдә бердәмлек булмау, тәртип җитеп бетмәү кебек нәрсәләр, чынлап та, эчне пошыра бит! Вәләкин бөтен бер илне юлга салу, тәртипкә кертү, ай-һай, авыр эш... Җитмәсә, без бит үз тормышыбыз өчен генә түгел, ә вәхши викиңнәрдән качып, болгарга килеп сыенган күрше мукшы, чирмеш яки ар кебек күрше халыклар, ягъни ишләребез[4] өчен дә борчылырга һәм көрәшергә тиеш бит!

– Болар барысы да олуглар, затлылар кулыннан килә торган эш. Беләсеңме икән, Чыңгызханның «Яса» дип аталган кануннарында баскын малны бүлешү

[2] Чин вә Мачин – Кытай дәүләтләре.
[3] Тарбус – тәртип.
[4] Иш – союзник (мәс. «товариш» – тауар ише).

турында нәрсә әйтелә: «Кем дә кем сугыш бетмәс борын үз өлешен даулый башлый – муенына чап! Дошманны җиңгәннән соң, шат, бүлешә алырбыз!»

– Безгә дә менә шундый кодрәтле кешеләр кирәк.

Вәзир Баттал, авыз тутырып сөйләшердәй кеше таба алуына куанып, озак кына гәп корып утыргандай тоелса да, шактый ук катлаулы зат булып чыкты. Ул бары тик чыгып китәр алдыннан гына, ашыкмыйча, ни өчен килгәнлеген аңлатты:

– Кем, Җик остаз, Болгар әмире галиҗәнаплары сине күрергә тели. Ул синең сәяхәтнамәңне укыды һәм хуплады. Туранда булган фаҗигале хәлләрне, белгән-күргәннәреңне түкми-чәчми аңа үзең сөйләп бирсәң иде.

– Мин сезнең хәер-дога белән, кем, вәзир Баттал – һәрвакыт әзер!

– Алайса, иртәгә хәерле җомга көнне иртәнге сәгать сигезгә сарайга килеп җитсәң, иллә дә мәслихәт булыр иде...

***

Тәхет залында уздырылган диван утырышында мангуллар ханы Чыңгыз тарафыннан Кашгар сәүдәгәре белән җибәрелгән хат укылды. Баттал чакыруы буенча, диван утырышына Җик остаз да килде. Ул мондый түрәләр арасында утыруга күнекмәгән иде.

Диван мәҗлесен әмир үзе ачты. Чыңгызның хатын кычкырып уку исә колак артына каурый каләм кыстырган нечкә озын мыеклы сәркатипкә тапшырылды.

Хатның эчтәлегендә Чыңгызхан турында «халыклар терәге», «җиде икълимнең[5] гадел падишаһы» дигән һәм башка күптөрле тәфсилле сүзләрдән гайре, йөрәкне тетрәткеч мондый юллар да бар иде: «Без болай дип фараз кылдык: җир йөзенең адәм балалары яши алырдай өлеше бер хан биләмәсенә дә җитәрлек түгел. Чин вә Мачин, Иран вә Туран җирләре Бөек мангул дәүләте белән бер йорт булды. Кыпчак[6] вә Урыс дәүләтләре дә шулар арасында безнең Алтын тәхетебезне бизәгән кыйммәтле асыл ташлар кебек абруйлы урын алсыннар иде...»

– Кем сүз әйтергә тели? – дип сорады әмир, яраннарына карап. Вәләкин, ни гаҗәп, бер генә морза яки сәет тә сүз алып сөйләргә ашыкмады. Әйтерсең лә авызларына су капканнар иде, авыз ачып сүз әйтсәләр, ул шунда ук Чыңгыз ханга барып юлыгырга тиеш иде...

Җик остазның әйтәсе сүзләре бар иде, әлбәттә, тик бу морзалар һәм киерелеп утырган аксөякләр арасында авыз ачып бер генә сүз әйтергә булса да аның ирке юк иде.

Әмирне исә сәркатипкә кычкырып укырга рөхсәт ителмәгән хаттагы мондый сүзләр аеруча борчыды, бәгыренә төште: *«Мәгълүм булганы шулдыр ки: әмир, безгә каршы чиру җыярга җыенасың икән. Кырнак янында хәмер эчеп, безләргә хыянәт итәргә уйласаң, әмир, тиреңне салдырып, салам тутырттырып, Шәһри Болгар капкасына элеп куярга боерырбыз!»*

Юк, янау түгел, ә хаттагы сүзләрдә беркемгә дә мәгълүм булмаган дөреслек ятуы куркытты әмирне. Соңгы вакытта гүзәл кырнак кырында аның ешрак булгалавы да, эч пошканнан дип, кисмәге белән чирмеш алпавыты китергән әче балны

---

[5] Икълим – климат.

[6] «Мангулларның яшерен тарихы»на караганда, ул чорда Болгар һәм Киев – башкалалар буларак кына телгә алына, ә көньяк-көнбатышта, ерактарак урнашкан җирләр »Урыс Җире» дип аталган, Кырымнан алып Иртышка һәм Каспийдан алып Пирмгә кадәр булган биләмәләр шулай ук халык исеме белән «Кыпчак» дип аталган.

«Болгар базары». Р.Заһидуллин рәсеме

капкалавы да хак иде. Тикерактагы мангул ханының боларны каян белгәнлеген генә тәгаенли алмады ул...

– Бәлки әүвәлге хат китергән сәүдәгәрнең үзен тыңларбыз? – дип сорап куйды Күбәк бәк.

– Яхшы, шулай итик, сәүдәгәрне чакыртыгыз! – дип, әмир вәзиргә ымлады. Бу тәкъдим аның үзен дә кызыксындырды.

– Баш өсте! – дип, вәзир тәхет залыннан ашыгып чыгып китте.

Баттал, ашыгып, сарайның икенче башында урнашкан йомышчылар бүлмәсенә юнәлгәндә, келәмгә абынып, чак кына егылмый калды. Аның борчылуы йөзенә чыкты, чөнки бу бик тә яман ишарәтләрнең берсе иде.

Ул урап килгәндә тәхет залыннан төрле-төрле эш кәгазьләре күтәргән катиб чыгып китте. Вәзир, югалыбрак калган сәүдәгәрне ияртеп, залга керде.

– Сәүдәгәрмен. Мөхәммәт Кушлавыч буламын, әфәндем, – диде ул әмиргә баш ия-ия.

Әмир Буян, сәүдәгәрнең сәламен алгач, аңа текәлеп карады. Сәүдәгәрнең кыяфәте бик үк ошап бетмәде аңа. Буе базык, йөзе янган күмер төсле кара чутыр булу өстенә, ул башына керләнеп беткән тар гына чалма ураган, аягында үкчәләре тапталган чарык, ә өстендә кызгылт билбау белән буылган иске җилән иде.

Сәүдәгәрнең шәһри Болгарда уңышлы гына сәүдә итүен, зур табыш алуын да

әмир белә иде. Бу илтифатсызлыкның сәбәбе мангул ханы Чыңгызга аркалану булыр, дип уйлап алды ул. Хәер, сәүдәгәрнең күзләрендә әрсезлек түгел, ә борчылу сизелә иде, тик моның сәбәбенә генә төшенә алмады әмир.

– Чыңгызханның хатындагы кайбер нәрсәләр кызыксындыра безне, – диде ул затлыларда гына була торган бер караш белән, – шәт, Чыңгызханны яхшы беләсеңдер?!

– Белмичә, әфәндем, уйгыр ла мин.

Әмирнең күзләрендә гаҗәпләнү күреп, сәүдәгәр аңлатырга ашыкты:

– Чөнки, Чыңгызхан, хәләд Аллаһы мәләкәһү![7] 601 нче елда ук үзенең дәүләтендә уйгыр имласы кертте. Уйгыр укымышлыларын, сәүдәгәрләрен хезмәткә алып олуглады.[8] Әмир галиҗәнапларына тапшырылган хат язылганда аның чирүе Хәрәзем пайтәхете Үргәнечне камап алган иде...

– Бу кадәресе безгә мәгълүм, сәүдәгәр. Мангуллар Үргәнечне алдылар.

– Сез, әмир хәзрәтләре, миннән күбрәк хәбәрдар?! – дип гаҗәпләнгәндәй итте сәүдәгәр. – Хәер, безнең юлга чыгуыбызга гына да өч ай тулып үтте бит инде...

– Хәрәзем белән Болгар арасындагы кәрван юлының өч айлык икәнлеге безгә дә мәгълүм, сәүдәгәр, – дип өстәде вәзир, – әмма безне мангуллар үзләре кызыксындыра. Кем ул Чыңгызхан? Кемнәр алар – мангуллармы, әллә татарлармы? Төрле сүзләр йөри, кайдан чыккан халык икәнлеген беркем дә тәгаен генә әйтә алмый...

Мөхәммәт Кушлавыч, сүзен башлаганчы, астыртын гына як-ягына каранып алды. «Ә бит сәүдәгәр миннән түгел, мангуллардан курка, димәк, сарайда Чыңгызхан кулы бар!» – дигән уй узды әмирнең башыннан. Сәүдәгәр, сүзләрен үлчәп кенә, ашыкмый гына сөйләп китте:

– Үзең беләсең, әмир галиҗәнаплары, товарлы сәүдәгәрләр ерак илләргә еш кына кызыл мал гына түгел, яңа хәбәрләр дә китерә. «Ерак ил сүзен аркыш китерер», ди мәкаль. Беренче булып мангул яулары турында: «Татарлар килә!» – дип шом салучылар да Кытай сәүдәгәрләре иде. Бигрәк тә мангуллар Кытайны басып алгач, бу хәбәрне Кытай сәүдәгәрләре төрле якларга юнәлгән ефәк юллары аша башка илләргә дә таратты.

Әмирнең кызыксынып тыңлавын күреп, Мөхәммәт Кушлавыч аңлатыбрак бирүне кирәк тапты:

– Ул «татар» дигән кушаматны, кытайчадан тәрҗемә итсәң, «кырагай», ягъни «күчмә» дигән сүз була. Әле моннан мең ел элек язылган елъязмаларда кытайлар үзләреннән төньяктарак яшәгән барлык башка кабиләләрне дә шундый гомуми исем белән атаганнар булса кирәк.

Әмир сәүдәгәргә кызыксынып карады:

– Ә сиңа, сәүдәгәр, ул елъязмаларны үзеңә күрергә туры килмәдеме?

– Юк, әфәндем, бу кадәресен миңа Кытай сәүдәгәрләре сөйләде.

Болгар тарихына багышланган китапларны, шул исәптән, Ибен Ногманның «Болгар тарихы»н да укыган кеше булганга, әмир үзен тарихтан шактый ук хәбәрдар кеше, дип саный иде[9]. Сәүдәгәр исә, һич уйламаганда, бөтенләй ят, таныш булмаган тарих сәхифәләрен актара башлады.

– Алайса, «татар» дигәннәре шул ук мангул була инде.

– Шулай, әмир галиҗәнаплары. Башка халыклар да кытайлардан ишетеп,

---

[7] Хәләд Аллаһе мәләкәһү (гар.) – Аллаһ аның патшалыгын озын кылсын!
[8] Бу вакыйгалар 1204 елда була.

аларны шулай дип атый. Кытайлар «татар» дип башка, үзләренә буйсынган халыкларны, бигрәк тә төркиләрне сүгәргә ярата.

– Уйгырларны да шулай атыйлармы?

– Әлбәттә.

– Ә мангуллар?..

– Хәзер юк.

– Ни өчен?

– Чөнки Чыңгызхан үз дәүләтендә, әйткәнемчә, уйгыр әлифбасын кабул итте. Борынгы төрки шәһәре булган Каракорымда урнашкан пайтәхетендә, кытайлардан гайре, уку-язуны таныган барлык абруйлы хезмәткәрләр дә уйгырлардан тора...

– Ни өчен кытайлылар башка халыкларны шулай атыйлар икән, сәбәбе нидә?

Сәүдәгәрнең күзләре мутланып китте. Ул, борын астыннан гына елмаеп, әрсезләнебрәк җавап бирде:

– Әмир галиҗәнапларына мәгълүм булса кирәк, Болгар дәүләтендә дә күптөрле халык яши. Минем биргә беренче мәртәбә генә килүем түгел. Халыкка кушамат тагып кимсетү, аны типкәләү, изү һәм талау өчен янә бер сылтау гына бит!

– Ялгышасын, сәүдәгәр! – диде вәзир аның сүзен бүлеп, – Әмир галиҗәнаплары – Болгар дәүләте аңа яр булсын – хакимнәр арасында үзенең гаделлеге белән аерылып тора. Безнең илдә төрле халыклар булуы турында дөрес әйтәсең, әмма дә, мең еллар бергә яшибез, ә төрки-болгар телендә аларга карата бер генә мыскыллы атама – сүз дә булмавын бел! Киресенчә, Болгар дәүләте канаты астында алар тынычлыкта яшиләр дә...

– М-мин бит м-мангуллар турында сөйлим! – диде сәүдәгәр, тотлыгып.

– Әйе, әйе, – дип, Гали сәет чал сакалын сыйпады. – Хәтта хак дингә дә көчләп күчермибез: теләмисең икән, анысы синең эш – гүргә кергәч, җавабын үзең бирерсең, дип карыйбыз без...

«Менә монысы инде бик начар, сәет. Бераз үз хезмәтеңне күрсәтсәң дә яраган һәм аркадашларың да ишлерәк булыр иде. Мангуллар көньяктан, ә барча чирмешләр, алар ягына күчеп, төньяктан кубарылып һөҗүм итсә, кая барырсың икән?» – дип уйлап алды Баян. Мангуллар турында болай юк-бар сөйләшеп утыру остаз Җикнең эчен пошырды. Мангуллардан килгән сәүдәгәрдән аларның Болгар иле яшәеше өчен никадәр куркыныч булуларын ачыклау тиеш иде.

– Ил коты[10], сәүдәгәргә бер сорау бирергә мөмкинме? – дип эндәште ул.

Алдарак утырган сәет Гали, көрәк кебек сакалын ике кулы белән дә тотып, Баян остазга таба борылды. Беркем дә белмәгән бу кешенең диван әһелләре әңгәмәсен бүлеп сорау бирүенә гаҗәпләнүе иде аның. Күрелмәгән хәл!

Дәвамы бар ■

[9] Ибн Ногман – XII йөз болгар тарихчысы. Хезмәтләре сакланмаган.
[10] Ил бәхете – Ваше величество.

Энтони Дженкинсон картасында татар җирләре. Лондон. 1562 ел

КАЗАННЫҢ беренче ханнары

Әнвәр Әхсәнов

XV гасыр урталарында Алтын Урдадагы мөһим сәяси вакыйгалар мөстәкыйль ханлыклар барлыкка килүгә сәбәпче була. Тарихи чыганаклар һәм тарихчыларның әлегә кадәр бу сорауга төгәл генә җавап биргәне юк: Казан ханлыгына кем һәм нинди шартларда нигез салган? Бер төркем галимнәр фикеренчә, аңа 1437-1438 елларда Сарай тәхетеннән куылган Олуг Мөхәммәт, ә икенче чыганаклар буенча, 1445 елда аның улы Мәхмүт нигез салган. Соңгы елларда галимнәрнең еш кына икенче фикерне хуплый башлауларын да әйтергә кирәк, чөнки күп кенә тарихи чыганакларда Мәхмүткә мөнәсәбәтле сюжет тасвирлана. Бу мәгълүмат шактый соң, XVI гасырдан башлап, Мәскәүнең югары даирәсе тарафыннан барлыкка килгән, ягъни рәсми булмаган, бәйсез чыганаклар белән дәлилләнмәгән. Ә Казанга Олуг Мөхәммәт хан нигез салуы турындагы караш «Казан тарихы» мәгълүматлары буенча билгеле, әмма аның авторы, вакыйгаларны төгәл тасвирламау сәбәпле, галимнәр тарафыннан шактый тәнкыйтькә дучар булды. Олуг Мөхәммәт Казанның беренче ханы булуы турындагы юллар татар тарихи чыганакларында да теркәлгән (Миргалеев 2012: 96; Миргалеев, Пашаоглу 2014: 45; Смирнов 1887: 207). Шуңа өстәп, елъязмачылар, ягъни вакыйганы үз күзе белән күрүче яки ишетүчеләр, 1430 еллардан башлап Олуг Мөхәммәтнең Мәскәү дәүләтенең көнчыгыш һәм көньяк-көнчыгыш биләмәләренә оештырган хәрби яуларын тасвирлый. Бу фактлардан да Урта Идел буенда ханның булганлыгы аңлашыла (Аксанов 2014: 139-142).

Казан дәүләтчелеге мәсьәләсен тикшергәндә, һичшиксез, Җучи Олысындагы күчмәннәрнең социаль-икътисади шартларга бәйле сәяси традицияләрен игътибарга алырга кирәк. Кыш көннәрендә хан дәүләт белән көньякта, нигездә, Сарай шәһәреннән идарә иткән, ә җәй җиту белән тәхетне төньякка, Болгар җирләренә күчергән. Моннан исә Бату хан заманыннан башлап Болгар шәһәре Алтын Урданың вакытлы башкаласы булганлыгы аңлашыла (Измайлов 2009: 450).

Шуның өстенә, 1420 елларда Казан шәһәрен дә Яңа Болгар

Аксанов А.В. Образование Казанского ханства глазами современников и потомков // Золотоордынское обозрение. 2014. № 2 (4). С.135-147.

Бахтин А., Хамидуллин Б. Политическая история Казанского ханства // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. IV. Татарские государства XV-XVIII вв. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2014. С.289-358.

Беспалов Р.А. Хан Улу-Мухаммед и государства Восточной Европы: от Белева до Казани (1437-1445) // Золотоордынская цивилизация. Выпуск 5. Казань, 2012. С.53-70.

Измайлов И. Булгарский улус: Булгар и другие эмираты // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. III. Улус Джучи (Золотая Орда). XIII – середина XV в. Казань:Институт истории АН РТ, 2009. С.448-470.

Меховский М. «Трактат о двух Сарматиях» // История татар с древнейших времен в семи томах. Т. IV. Татарские

(Болгар әл-җәдид) дип атый башлыйлар (Измайлов 2009: 468; Перевод 2014: 900). Бу Олуг Мөхәммәт һәм аның угыл-оныклары даирәсендә Казан каласының дәрәҗәсе Җучи Олысының башкаласы Сарай белән тиңләшүен, ә ханнар сәяси уңышка ирешкән вакытта хәтта бөтен Алтын Урданың берләшү үзәге була алганлыгын күрсәтә. Моны XV гасырдагы елъязмачылар да дәлилли. Алар, соңрак иҗат иткән авторлардан аермалы буларак, Казан ханлыгын 1430 елларда барлыкка килгән, дип язмый. Шуннан аңлашыла ки, Олуг Мөхәммәтнең Урта Идел буена килүе замандашлары тарафыннан яңа дәүләткә нигез салу буларак кабул ителми. Дөресрәге, алар бу вакыйганы чираттагы тәхет түнтәрелеше вакытында ханның төньяктагы үз биләмәләренә кайтуы буларак кына кабул иткән. Әйтергә кирәк, аннан соң да Олуг Мөхәммәт көньяк олыслар өчен көрәшүдән баш тартмый, 1440 елларның беренче яртысында Дәште кыпчак һәм Кырымда үз хакимиятен тергезә, 1445 елда Мәскәү Бөек кенәзлеген буйсындыра (Беспалов 2012:63; Пономарев 2014: 146; Сабитов, Якушечкин 2015: 179). Шул рәвешле, Олуг Мөхәммәт замандашлары хәтерендә Алтын Урда ханы булып кала. Аның балалары исә дәүләтнең көньяктагы биләмәләрен саклап кала алмый, әмма Алтын Урданың төньяк олысларында хакимиятне үз кулларында тота. Ә иң мөһим биләмә – Олуг Мөхәммәтнең олы улы Мәхмүткә тапшырылган Казан юрты (йорты) булган. Шулай итеп, Мәхмүткә үз атасыннан үзенчәлекле суверенитет – «хөр патша» («вольный царь») титулы мирас булып кала. Бу аңа Болгар олысы, казанлылар белән идарә итәргә тулы мөмкинлек биргән.

Шуның өчен Казанның беренче ханнарының сәяси максаты Кырым, Олы Урда һәм шәйбани чыңгызыйларыныкыннан әллә ни аерылмый. Алар нигездә барысы да Алтын Урда тәхетенә омтылган яки дәүләт таркалганда аның мирасын күбрәк эләктереп калу өчен көрәшкән. Бу турыда метрополит Иовның 1448 елның 15 декабреннән 1461 елның 31 мартына кадәр язган грамоталары да дәлилли. Шунысы игътибарны җәлеп итә: грамота текстының исемендә һәм төп өлешендә дә Мәхмүт хан белән кенәз Шәптәк «Казанныкы» дип әйтелмиләр, әмма хат нәкъ менә адресатлар урнашкан Казан шәһәренә җибәрелгән. Шуның өстенә, беренче грамотаның исемендә Мәхмүт – «татар патшасы», ә икенче грамотага Шәптәк кенәз «цесарьевич» буларак теркәлгән. Бары тик юл читендәге искәрмә генә сүзнең Казан патшасы турында икәнлеген аныклый. Алга таба, Мәхмүткә мөрәҗәгать итеп, Иов берничә мәртәбә «олуг», «бөек» кебек сүзләрне куллана: «твое великое имя и дръжаву», «великое твое господьство», «великомгосподьстве», «твоим великим государьством и жалованием» (Русский феодальный архив 1986: 154-155). Бу хөрмәтләү сүзләре, шул чор сәяси этикасыннан аңлашылганча, ханның башка шундый ук титул йөртүчеләрдән бер башка өстенлегенә

государства XV-XVIII вв.Казань: Институт истории АН РТ, С.823-831.

Миргалеев И.М. Сведения Абдулгаффара Кырыми о Казанском ханстве // Средневековые тюрко-татарские государства. Сборник статей. Выпуск 4. Казань: Институт истории им. Ш.Марджани АН РТ, 2012. С.96-98.

Миргалеев И.М., Пашаоглу Д.Д. Обзор сочинения «Умдет ал-ахбар» Абдулгаффара Кырыми // Золотоордынское обозрение. Казань. 2014. № 2(4). С.35-60.

Перевод фрагмента хроники «Хикайат» об истории возникновения Казани / Пер. И.Мустакимова // История татар с древнейших времен в семи томах. Т.IV. Татарские государства XV-XVIII вв. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2014. С.900.

Полное собрание русских летописей. Т.8. Продолжение летописи по Воскресенскому списку. М.: Языки русской культуры, 2001. X + 302 с.

Полное собрание русских летописей. Т.25. Московский летописный свод конца XV в. / Под.ред. Н.М. Ти-

ишарә булып тора. Мондый сүз белән еш кына Урда тәхетенә омтылган соңгы җучилылар аталган. Мисал өчен, Сәхибгәрәй дә чыганакларда «олуг» («әл-газыйм») дип язылган (Тарханный подтвердительный ярлык 2014:919-920). Зур Урданың ханнары да әлеге мәртәбәле сүздән баш тартмаган (Меховский 2014: 826). Аңлашыла ки, әлеге чыганакның авторы да Мәхмүтне Алтын Урданың ханы буларак кабул иткән.

Моннан тыш, грамота текстларында Мәхмүт дүрт мәртәбә «хөр патша» дип атала. Беренче карашка, Иов аны Урданың мөстәкыйль патшасы буларак тасвирлый сыман. Әмма шуны-сын искә алырга кирәк, бу документта әлеге сүзтезмә «олуг» һәм «татар» сүзләре белән бер контекстта кулланыла. Шул сәбәпле бу очракта «хөр патша» сүзләре Мәхмүтнең хөрмәткә лаеклылыгы-на, югарылыгына, Алтын Урданың башка ханнарына караганда өстенлегенә ишарә генә булып тора. Урта гасыр сәяси система-сында фәкать югары, бөек патша гына «хөр», иректә, ягъни бөтен Җучи Олысының кануни хакиме була алган. Әйтик, Урдага ярлык өчен барган бояр И.Д.Всеволжский да Олуг Мөхәммәткә «хөр патша» дип мөрәҗәгать иткән (Полное собрание 2001: 96).

Метрополит грамоталары текстының баш исеменә «Казан патшасы» сүзтезмәсе урынына «татар патшасына» дип язылу да очраклы күренеш түгел. Мөгаен, мондый мөһим терминоло-гик тайпылышлар, этисеннән үрнәк алып, Алтын Урданың бөтен татарлары «патшасы» булырга омтылган Мәхмүт ханның сәяси амбицияләрен, ният-хыялларын истә тотып барлыкка килгәндер. Иов Урда тәхетенә башка ханнарның да дәгъва кылганын яхшы аңлаган (нәкъ шул сәбәпле, юл читенә «Казан патшасына» дип язылган), әмма бу хат ярдәмендә үзенең Казандагы сәүдә эшләрен уңышлы хәл итү өчен Мәхмүтнең башка җучилылардан өстенлеген таныган.

Кыскасы, мондый бәяләмә чынбарлыкка да туры килгән: Мәхмүт хан һәм аның уллары идарә иткән дәвердә илдә сәяси тотрыклылык урнаша, сәүдәгәрләргә чит илләр белән куркы-нычсыз сәүдә итү өчен шартлар туа, Казанның яңа җирләрдә дә хакимияте ныгый. Нократ төбәге һәм Бөек Пермь дә Казан хан-лыгы йогынтысы тәэсирендә яши башлый (Бахтин, Хамидуллин 2014: 292). Ә 1469 елда дәүләтнең мәйданы Агыйдел буйларын, Иштәк һәм Башкорт җирләрен кертеп, Урал тауларына кадәрге мәйданны колачлый (Полное собрание 1949: 282). Бу заманда Алтын Урда биләмәләрендәге төньяк олысларның байтак өлеше Олуг Мөхәммәтнең угыл-оныклары хакимиятенә керә. Шулай итеп, Урта Идел һәм Көнбатыш Урал буенда статусы буенча Ал-тын Урданың бер өлеше һәм дәвамчысы булган, ә территориаль яктан яңа дәүләт – Казан ханлыгы тарихы башлана. ■

хомирова. М.; Л.: Изд-во АН СССР, 1949. 464 с.

Пономарев А.Л. Ибрагим, сын Махмудека: вхождение во власть и кошельки (1) // Золотоордынское обозрение. № 1(3). 2014. С.128-162.

Русский феодальный архив XIV-первой трети XVI века. Т. 1./ Под ред. В.И. Буганова. М.: Институт истории СССР АН СССР, 1986. 221 с.

Сабитов Ж., Якушечкин А. Кто был ханом в Крыму в 1456 году? // Крымское историческое обозрение. № 2. 2015. С.175-185.

Смирнов В.Д. Крымское ханство под верховенством Оттоманской Порты до начала XVIII века. СПб., 1887. 768 с.

Тарханный подтвердительный ярлык, выданный казанским ханом Сахиб-Гиреем группе лиц (929 г., сафар 13 = 1523, января 1) / Пер. В. Трепавлова// История татар с древнейших времен в семи томах. Т. IV. Татарские государства XV-XVIII вв. Казань: Институт истории им. Ш. Марджани АН РТ, 2014. С.919-920.

«Шенас» – кызыксынучан акыл

(Габдулла Сабир улы Ибраһимов-Шенаси – педагог һәм җәмәгать эшлеклесе)

Ләлә Мортазина

Октябрь революциясенә кадәр татар мәдрәсәләрендә укучы шәкертләрнең киң кырлы белем алулары билгеле. Әмма XIX гасырның урталарына кадәр табигать фәннәрен укыту буенча махсус дәреслекләр булмау сәбәпле, ботаника, зоология, анатомия гыйлемнәре «тарихы табигыя» курсында бирелгән. Физика һәм астрономия дәресләре гарәп һәм фарсы авторлары язган дәреслекләр буенча алып барылган. Татар телендә беренче арифметика, геометрия һәм география дәреслекләре галим һәм мәгърифәтче Каюм Насыйри авторлыгында дөнья күрә. XIX гасыр ахырларында астрономия, физика, география буенча да махсус дәреслекләр күренә башлый. Аларны мәдрәсә мөдәррисләре үзләре язган. Мәсәлән, Ш.Күлтәсинең «Мөфассәл һәйәте җәдидә» китабы, Иж-Бубый мәдрәсәсе мөгаллиме Г.Бубыйның «Кыйраәте фәнния», «Мохтәсар җәгърәфия гомуми» һ.б. дәреслекләр язуы билгеле.

Кайвакыт дәреслекләрне мәдрәсә шәкертләре үзләре дә язган. Мәсәлән, Мөхәммәтзыя Бәхтияри әл-Мәмдәлинең Түнтәр мәдрәсәсендә укыган вакытта ук башлап өйрәнүчеләр өчен арифметика һәм астрономиядән кулъязма дәреслек язуы, озак та үтми аны Казанда бастырып чыгаруы билгеле[1]. Бу, бер яктан, татар мәдрәсәләрендә белем бирүнең куелышы югары дәрәҗәдә булу турында сөйләсә, шул ук вакытта шәкертләрнең кызыксынучан, гыйлемле булуын да раслый. Татар телендә табигать фәннәре буенча дәреслекләр язу, әлеге предметларны укытуның методикасын эшкәртүдә зур өлеш керткән мәгърифәтче-галимнәр арасында татар педагогы Габдулла Сабир улы Ибраһимов (Шенаси) да бар. Ул язган «Мохтәсар кимия» – химия буенча татар телендәге мөстәкыйль дәреслекләрнең беренчесе булып санала[2]. Белгечләрнең раславынча, бу әсбап революциягә кадәрге чорда иң камил дәреслекләрнең берсе булган, шул сәбәпле уку-укыту барышында бик киң кулланылган[3].

Г.С.Ибраһимов 1885 елда Оренбург губернасының Троицк шәһәрендә (хәзер Чиләбе өлкәсенә карый) приказчик гаиләсендә дөньяга килә. Башлангыч белемне туган шәһәрендәге татар мәдрәсәсендә ала. Кече яшьтән үк төрле гыйлем белән кызыксын-

[1] Бәхтияр М. Каванин әл-хисаб. – Казань: Типо-литография Императорскаго Университета, 1898. – 88 б.

[2] Мифтахова Н.Ш. Химия буенча татар телендәге беренче китаплар // Фәнни Татарстан. – 2005. – №3 / 4. – 11 б.

[3] Рахимкулова М.Ф. Преподавание естественных наук в татарских школах дореволюционной России: Страницы истории татарских школ в России. – Оренбург, 1998. – 274 с.

Габдулла Сабир улы Ибраһимов (Шенаси)

ган 15 яшьлек үсмер егет 1900 елда белемен киңәйтү максаты белән Константинополь (Истамбул) шәһәренә китә. Биредә гимназиядә белем ала, соңыннан Константинополь университетының табигать белеме факультетына укырга керә[4]. Үтә кызыксынучан, табигать фәннәре буенча эзләнүләр алып барган студент егеткә иптәшләре «Шенаси» (гарәп телендә «шенас» – «белүче, белемле, тәҗрибәле; кызыксынучан акыл, аңлаучы» мәгънәләрен аңлата) дигән исем бирәләр. Озакламый ул аның фамилиясенең бер өлеше булып китә. Кызганычка каршы, Шенасига университетны тәмамлау насыйп булмый – 2 ел укыганнан соң ул авырып китә һәм кире туган иленә әйләнеп кайтырга мәҗбүр була. Ләкин биредә алган белем һәм

[4] «Татар энциклопедиясе»ндә Г.Шенаси Каһирәдәге «Әл-әзһар» университетында укый, дип күрсәтелә (Татарская энциклопедия: В 6 т. Т.6. – Казань: ИТЭ, 2014. – С.423). Бу дөрес факт түгел, чөнки педагогның шәхси документларында

Габдулла Шенаси туган йорт (Троицк шәһәре)

күнекмәләрен, тагын да тулыландырып һәм камилләштереп, ул гомере буе туган халкын мәгърифәтле итүдә файдалана, иптәшләре тарафыннан бирелгән исеменә тап төшерми.

Г.Шенасиның хезмәт эшчәнлеге Уфа шәһәрендә башланып китә. 1908 елның көзендә ул «Галия» мәдрәсәсе җитәкчелеге чакыруы буенча шунда физика, химия һәм математика укыта башлый. Химия, билгеле булганча, бу чорда бар мәдрәсәләрдә дә укытылмый. Г.Шенаси, мәдрәсәдә эшли башлау белән, татар мәдрәсәләре тарихында беренчеләрдән булып, физика-химия кабинеты оештырып җибәрә һәм анда төрле тәҗрибәләр үткәрә. Татар телендә химия китаплары булмау сәбәпле, ул һәр дәрескә үзе махсус әзерләнеп, лекция конспектлары булдыра һәм шулар нигезендә дәреслек язу кирәклеге турындагы карарга килә. Аның «Мохтәсар химия» дәреслеге нәкъ шушы чорда языла башлый, беренче кисәге 1910 елда Казанда басылып чыга. Автор китапның тышлыгында күрсәткәнчә, ул аны француз телендәге дәреслекләр һәм башка фәнни хезмәтләргә нигезләнеп яза[5]. Дәреслекнең икенче өлеше 1912 елда Оренбург шәһәрендә дөнья күрә[6].

Бу дәреслекнең язылу тарихына тукталып, кереш өлешендә Г.Шенаси болай дип яза: *«Үз телемездә бу фәнгә гаид (караган –* Л.М.*) бер китап булмавы вә госманлыча язылганнарының шивәләре бик авыр булуы мине бик аптыратты. Хәлбуки, шәкертләрнең мөгаллим тәкъриреннән (аңлатуыннан –* Л.М.*) кирәгенчә файдаланулары өчен үзләренә рәһбәр (җитәкче –* Л.М.*) вә мәрҗигъ (мөрәҗәгать итү өчен яраклы –* Л.М.*) булырлык кыска вә мөфид*

Константинополь шәһәре генә искә алына.

[5] Шенаси Г. Мохтәсар химия. 1 кис. Мөкаддимә. Шибһә мәгадин. Франциядә мөгаллимләр җыелышы илә игъдади дәрәҗәсендә фән укытыла торган мәктәпләр өчен тәртип ителгән химия китабы әсас тотылып тәрҗемә вә тәэлиф улынды. – Казан: «Юл» көтепханәсе, 1910. – 172 б.

[6] Шенаси Г. Мохтәсар химия. 2 кис. Мәгадип. – Оренбург: «Вакыт», 1912. -106 б.

Г.Шенаси (сулдан – өченче) Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллимнәре арасында. Аның уң як янәшәсендә – танылган педагог Сөнгатулла Бикбулатов. 1911 ел

(файдалы –Л.М.) бер китап кирәк иде. Менә ошбу кирәклек вә бу юксыллык мине икътидарым белән бик мөтәнасиб булмаган (кулымнан бик үк килмәгән – Л.М.) бер эшкә ябышуга мәҗбүр итте. Шулвакыт кулымда булып, тәртип вә ысулы күңелемә охшаган вә Франциядә мөгаллимнәр җыелышы белән игъдадия (югары мәктәпкә әзерлек класслары – Л.М.) дәрәҗәсендәге фәнни мәктәпләр өчен тәртип французча бер кимия китабын шәкертләрнең икътидары (мөмкинлекләре – Л.М.) вә ихтыяҗларына күрә бераз тәгъдил илә (бераз йомшартып – Л.М.) тәрҗемә итеп, укыта башладым. Ул вакытка чаклы голүме табигыядан (табигать фәннәреннән – Л.М.) һич бернәрсә күрмәгән шәкертләр кимия хакында яхшы ук мәгълүмат алдылар. Вә файдаландыкларыны имтихан гомумидәге җаваплары илән исбатладылар. Файдаландыкларына шәкертләр үзләре дә ышанган булырга кирәккә, соң дәрестә кимия укыган шәкертләрнең барысы да бер авыздан үзләренә яздырылган дәресләрнең китап рәвешендә бастырылып нәшер ителүен үтенделәр»[7]. Г.Шенаси шулай ук әлеге химия дәреслеген бастырып чыгаруның шәкертләрне лекция язудан коткарачагы, шулай ук башка мәдрәсә шәкертләре дә файдалана алачагы турында яза.

Дөньяви фәннәр буенча язылган дәреслекләрнең күпчелеге башка телләрдән тәрҗемә ителүе мәгълүм. Бу хәл бигрәк тә совет чоры дәреслекләрендә күзгә ташлана. Әмма Г.Шенасиның химия дәреслеге, татар тарихында беренче мөстәкыйль дәреслек булса да, моңарчы дөнья күргән башка телдәге китапларның сүзгә-сүз күчермәсе, ягъни тәрҗемәсе түгел. Автор үзе билгеләп узганча,

[7] Шенаси Г. Мохтәсар химия. 1 кис. – Б.2.

китапны язганда француз телендәге химия дәреслегеннән файдала: *«Төркичә вә французча язылган башка китапларны да кулланып, бик тиеш күрелгән җирләрен ислах иттем (үзгәрттем, яхшырттым* –Л.М.*). Бик мөфассал (тулы, җентекле* – Л.М.*) китапларда гына табыла торган бәгъзе һәм нәрсәләрне гыйляв тан иттем (куштым, өстәдем* – Л.М.*)»*[8] .

Әлеге дәреслекнең әһәмиятен ассызыклап, автор аның мөселманнар арасында фәнни белемнәрнең таралуына ярдәм итәчәген әйтә. Шул ук вакытта бигрәк тә табигать фәннәрен өйрәтүдә Европа тәҗрибәсенә таянуның дөреслеген ассызыклый. Чыннан да, махсус предмет буларак химия укытылган барлык мәдрәсәләрдә дә («Мөхәммәдия»дә, «Иж-Бубый»да, «Хөсәения»дә) шәкертләрнең Г.Шенаси дәреслеге белән шөгыльләнүләре билгеле[9].

Бу дәреслек рәсемнәргә бай булуы белән дә, көнчыгыш һәм рус химиклары турында биографик мәгълүматлар бирелүе белән дә кызыклы. Беренче китапта төп химик төшенчәләр (материя, җисем, элементлар, атом, химия законнары һ.б.) бирелсә, икенчесендә металлар турында мәгълүмат бар. Әлеге дәреслек, үзенең камиллеге һәм химия курсын шактый җентекле яктыртуы сәбәпле, татар мәдрәсәләрендә генә түгел, совет чоры мәктәпләрендә дә 1929 елга кадәр кулланылышта була[10].

«Галия»дән соң Г.Шенаси Оренбургтагы «Хөсәения» мәдрәсәсенә күчә. Биредә озак эшләмәсә дә (1910-1912 еллар), «Хөсәения» – Г.Шенасиның педагог, методист һәм оештыручы буларак формалашуына шактый зур өлеш керткән уку йорты. Биредә ул, табигать фәннәре, шулай ук педагогика, дидактика һәм методика укыту белән беррәттән, мәдрәсәнең укыту һәм фән эшләре буенча җитәкче урынбасары булып та эшли.

Билгеле булганча, «Хөсәения» мәдрәсәсендә, оешуының беренче көннәреннән үк, яңа метод буенча укытуга, дөньяви һәм табигать фәннәренә зур игътибар бирелгән. Чөнки әлеге мәдрәсәнең эшчәнлеге беренче чиратта татар дөньяви мәктәбе өчен киң профильле белгечләр – башлангыч белем бирүче укытучылар, урта һәм югары белем бирү белгечләре, шулай ук мәдәният, хуҗалык учреждениеләре өчен кадрлар әзерләүгә юнәлтелгән була[11]. Шуңа күрә анда мантыйк (логика), фәлсәфә һәм фәлсәфә тарихы, культурология (мәгълүмате мәдәния), рус, татар, гарәп, фарсы телләре һәм әдәбиятлары, матур язу, арифметика, геометрия (тригонометрия белән), алгебра, физика, химия, астрономия, география, гомуми тарих, Россия тарихы һәм татар тарихы (ул хөкүмәт рөхсәтеннән башка укытыла), табигать белеме, зоология һәм ботаника, законнар, политэкономия һәм сату эше, бухгалтерия, сызым һәм рәсем, педагогика һәм дидактика, психология, гигиена һәм медицина белеме нигезләре, гимнастика кебек дөньяви фәннәрдән тыш[12], немец һәм француз телләрен өйрәтүгә дә игътибар бирелгән.

[8] Шенаси Г. Шунда ук. – Б.3.

[9] Рахимкулова М.Ф. Преподавание... – С.109.

[10] Рахимкулова М.Ф. Там же. – С.113.

[11] Шарипов А.А. Роль медресе «Хусаиния» в формировании и возрождении мусульманского образования в Оренбургском крае. – Дисс. к.и.н. - Казань 2014. – С.68.

[12] Рахимкулова М.Ф. Медресе «Хусаиния» в Оренбурге. – Оренбург, 1997 – С.17-18.

«Хөсәения» мәдрәсәсе мөгаллимнәре. Урта рәттә утыручылар арасында сулдан икенче – Габдулла Шенаси. 1912 ел

1911 елда «The Moslem World» («Мөселман дөньясы») журналында яңа ысуллы татар мәдрәсәләренең укыту планы классик гимназияләрнеке белән тәңгәл килүе турындагы мәгълүмат бирелә. Гимназияләрдәге латин һәм грек телләре урынына мәдрәсәләрдә гарәп һәм фарсы телләре укытылуы турында әйтелә[13]. «Хөсәения» мәдрәсәсе тарихын җентекләп өйрәнгән галимә М.Ф.Рәхимкулова исә, табигать фәннәренең бирелеше ягыннан караганда, «Хөсәения»нең гимназиядән бигрәк, реаль училищеларга якын торуы турында яза[14]. Физика, химия кебек предметларга аеруча зур әһәмият бирелү шул турыда сөйли.

Г.Шенаси – татарча физика дәреслекләренең авторы буларак та яхшы билгеле. Аның урта мәктәпләр һәм педагогия курслары өчен төзелгән «Хикмәте табигыя дәреслеге»[15]1916-1920 елларда Уфада берничә тапкыр басылып чыга. Дәреслекнең максаты – шәкертләрне физика курсының төп төшенчәләренә өйрәтү. Соңгы басма, авторның үзе билгеләвенчә, авыл мәктәпләре өчен махсус языла. Икенче баскыч мәктәпләр һәм педтехникумнар өчен 3 кисәктән торган «Физика дәреслеге»[16] шулай ук берничә тапкыр дөнья күрә.

1929 елда Казанда атаклы галим һәм педагог Х.Мөштәри белән берлектә Г.Шенасиның 3 кисәктән торган «Физика» дәреслеге басылып чыга. Ул рабфаклар, беренче баскыч мәктәпләр, партия мәктәпләре һәм үзлегеннән физиканы өйрәнүчеләргә тәгаенләнгән[17]. Бу дәреслекләр, исемнәреннән үк күренгәнчә, физика фәненең барлык тармакларын үз эченә ала, җентекле, һәм шул ук вакытта аңлаешлы телдә язылуы белән аерылып тора.

Г.Шенаси дәреслекләре фәнни атамалар бирелеше ягыннан

[13] Марданшин М. Вклад медресе в татарское просвещение в конце XIX- начале XX вв. //dumrt.ru›Русский›.../analytics_1090.html

[14] Рахимкулова М.Ф. Медресе... – С.17.

[15] Шенаси Г. Хикмәте табигыя дәреслеге. Механика, сыеклыклар, газлар. – Уфа, 1920. – 132 б.

[16] Шенаси Г.Физика дәреслеге. 2 нче баскыч мәктәп һәм педтехникумнар өчен. – Казан, 1924. – 167 б.

да шактый камил. Шул сәбәпле, алар совет мәктәбендә дә озак вакыт кулланылыштан төшми. Әмма, ни кызганыч, 1933 елда ВКП(б) ҮКның СССР территориясендә бердәм дәреслекләрне генә куллануга юнәлдерелгән «Башлангыч һәм урта мәктәпләр өчен дәреслекләр турында»гы карары кабул ителгәннән соң, татар телендә язылган барлык дәреслекләр, шул исәптән, Г.Шенасиның табигать фәннәре буенча язылган китаплары да, күләгәдә кала. Моннан соңгы елларда мәктәпләрдә фәкать рус авторларының татар теленә тәрҗемә ителгән дәреслекләрен генә куллану мөмкин була[18]. Әлеге вазгыять 1990 нчы еллар башына кадәр дәвам итте. XX гасыр ахырында, ниһаять, татар галимнәре тарафыннан язылган дәреслекләр (мәсәлән, В.Гайфуллин һәм Р.Исламшинның урта мәктәпләр өчен «Физика», Г.Даутов җитәкчелегендә вузлар өчен язылган «Физика» дәреслекләре һ.б.) кулланыла башлады. Ләкин, ни кызганыч, бу алтын чор озак дәвам итә алмады – XXI гасыр башы Россия мәгариф системасында барган үзгәрешләр татар мәктәбендә дә бары тик үзәкләштерелгән, бердәм дәреслекләрне генә файдалану мөмкинлеген калдырды.

Инде әйтеп узылганча, Шенаси бик әзерлекле, фәннең төрле тармаклары буенча тирән белемгә ия була. Табигать-математика фәннәреннән тыш, ул телләр өйрәнү белән дә бик нык кызыксына. Күп телләр белүгә омтылыш, мөгаен, аның гимназиядә һәм университетта укыганда формалашкандыр. Татар мәдрәсәләрендә гарәп, фарсы, төрек телләре буенча шактый нигезле белем бирелүе билгеле. Әлеге телләрдән тыш, Г.Шенаси француз телен яхшы белгән, үзбәк, азәрбайҗан телләрендә җиңел аралашкан.

Бу мәгълүматны Г.Шенасиның хәзерге көндә ТР Милли музеенда сакланучы документлары дәлилли. 1986 елда күренекле татар мәгърифәтчесе һәм галиме, СССР география җәмгыятенең хакыйкый әгъзасы, татар мәгарифе тарихын өйрәнүгә зур өлеш керткән Мәдинә Рәхимкулова тарафыннан Габдулла Сабир улы Ибраһимовны (Шенасины) «Зур совет энциклопедиясе»нә кертү өчен документлардан махсус папка туплана. 1932 елның 15 февралендә тутырылган «кадрларны исәпкә алу буенча шәхси белешмә»дә Г.Шенасиның нинди телләр белүе һәм аның хезмәт куйган урыннары турында да тәфсилле мәгълүмат бирелә. Моннан тыш, аның үзе тарафыннан 1933 елның 13 сентябрендә язылган автобиографиясе педагогның эшчәнлеге турында шактый тулы чыганак булып тора. Кызганыч ки, әлеге документлар Мәскәүгә барып ирешмиме яисә Г.Шенасины «Зур совет энциклопедиясе»нә кертүне кирәк, дип тапмыйлармы, һәрхәлдә, 1986 елдан соң чыккан басмаларда (бу елларда ул «Зур Россия энциклопедиясе» булып дөнья күрә башлый) күренекле педагогыбыз турында мәгълүмат табылмады. Шунысы куанычлы: «Татар энциклопедиясе»ндә Г.Шенасига багышланган махсус мәкалә бар[19].

Күп телләр белүе Г.Шенасиның педагогик эшчәнлегендә

[17] Шенаси Г., Мөштәри Х. Физика. 1 кис. Механика, сыеклык, газлар. Рабфаклар, 2 нче баскыч мәктәпләр, техникумнар һ.б. өчен дәреслек. Үзлегеннән укучылар өчен ярдәмлек. Казан: Таткнигоиздат, 1929. – 135 б; Шенаси Г., Мөштәри Х. Физика. 2 кис. Молекулалар гипотезасы, җылылык, магнетизм, электричество. 2 нче баскыч мәктәпләр, эшфаклар, техникумнар һ.б. өчен дәреслек, үзлегеннән укучылар өчен ярдәмлек. Казан: Таткнигоиздат, 1929. – 135 б; Шенаси Г., Мөштәри Х. Физика. 3 кис. Тавыш, яктылык, гомумән тирбәнү хәрәкәте һәм радио. 2 нче баскыч мәктәпләр, эшфаклар, техникумнар һ.б. өчен. – Казан: Таткнигоиздат, 1929. – 208 б.

[18] Мифтахова Н.Ш. Химия буенча... – Б.15.

[19] Татарская энциклопедия: В 6 т. Т.6. – Казань: ИТЭ, 2014. – С.423.

Габдулла Шенаси (1930 нчы еллар)

һәрдаим чагылыш таба. Француз, төрек, гарәп телләре буенча белемнәрен ул дәреслекләр язуда (мәсәлән, алда әйтеп узылган химия дәреслеген) файдаланса, француз телен яхшы белүе сәбәпле, «Госмания» мәдрәсәсендә хәтта бу тел буенча факультатив дәресләр дә бирә[20].

Г.Шенаси «Галия», «Госмания», «Хөсәения» мәдрәсәләреннән тыш, 1915-1921 елларда Уфадагы икенче баскыч мәктәптә, педтехникумда, совет партия мәктәбендә, Халык мәгарифе институтында да эшли. 1925 елда Казанга күченеп килгәннән соң, Татар коммунистик университетында (1932 елга кадәр), педтехникумда (1929 елга кадәр), сәнгать техникумында, педагогия институтында (1937 елга кадәр), авыл хуҗалыгы институтында студентларга белем бирә. Моннан тыш, ул Наркомпроста фәнни редактор вазифаларын да башкара.

Революциядән соң яңа мәктәп төзү һәм аны заманча дәреслекләр белән тәэмин итү мәсьәләсе көн кадагына куела. Ана телендә яңа дәреслекләр төзү, аларда татарча атамаларны куллану мәҗбүрияте туа. Моңа кадәрге дәреслекләрдә файдаланылган гарәп-фарсы алынмалары урынына татарча терминнар булдыру мәсьәләсе куела. 1925 елның 17 сентябрендә Гыйльми үзәк президиумы утырышында терминология мәсьәләләре белән шөгыльләнү эше бу өлкәдә шактый тәҗрибәле педагог Габдулла Шенасига тапшырыла[21].

Татар телендә фәнни терминология булдыруның тел үсеше өчен никадәр әһәмияткә ия булуын ассызыклап, Г.Шенаси болай дип яза: *«Бер телнең башка телләр арасында хокуклы булуы һәм дә шул тел белән сөйләшүчеләрне мәдәният дөньясына чыгарырга ярдәм итүе өчен гыйлемнең бөтен тармаклары һәм техника белеменең шул телгә күчерелүе тиеш»*[22]. Бу вазгыять бигрәк тә татар теле өчен зур әһәмияткә ия була. Чөнки моңа кадәр төрек, гарәп һәм фарсы алынмалары нигезендә үсеш алган, чуарлыгы белән аерылып торган фәнни атамаларны татар теленә күчерү мөһим була.

[20] Рахимкулова М. Педагог и общественный деятель // Совет мәктәбе. – 1985. – №2. – Б.58.

[21] Шәмсетдинова Р., Гаффаров И. Шенаси – белем иясе // Фән һәм тел. – 2012. № 2. – 53 б.

[22] Шенаси Г. Ун ел эчендә Татарстанда гыйльми атамалар эшләү нәтиҗәсе // Мәгариф. – 1927. - №4. – Б.71.

Яңа шартларда *«ана телендә беренче баскычтан башлап югары дәрәҗәгә чаклы мәктәпләр ачарга, бөтен фән-техниканы ана теленә күчерергә мәйдан туды»*, – дип яза ул[23].

Гомумән алганда, Г.Шенаси татар атамаларын булдыруга үзенең беренче дәреслекләрен эшләү дәверендә үк беркадәр өлеш кертә инде. Мәсәлән, химия буенча дәреслек язганда ул атамалар куллануга карата үз карашын булдыра: *«Татар шивәсендә язарга тырыштым. Бик мәҗбүрият булганда гарәпчәләрне керттем. Бу вакытка чаклы үз арамызда билгеле булмаган гонсерләрнең исемнәрен вә кимияви истилахларын госманлыча кабул иттем»*[24]. Моннан тыш ул кирәгенчә рус телендәге атамаларны да кертү ягында була, чөнки, *«русча белгән шәкертләргә рус телендәге кимия китапларын аңлау җиңел булсын, дидем. Һәм дә русча исемнәрне белү аркасында җисемнәрне аптекарский магазиннан алып, кимия тәҗрибәләре ясау ансат булачактыр»*[25]. Татарча атамалар эшләүдә ул аның аңлаешлылыгын, төгәллеген, мәгънә белдерүдәге камиллеген беренче урынга куя. Аның фикеренчә, татар дәреслекләрендәге атамаларның барысының да фәкать татар телендә генә бирелүе шарт түгел, чөнки кайбер очракларда, теге яки бу мәгънәне белдергәндә бер генә сүзне кулланып булмый, катлаулы атамалардагы сүзләрнең төрле телләрдән алынган булуы мөмкин. «Физика атамалары» һәм «Математика атамалары» китапларының редакторы буларак, ул, иң беренче чиратта, әнә шуларга игътибар итә. 1927 елда Шенаси: *«Гыйльми үзәкнең һәм татар гыйльми көчләренең тырышлыклары аркасында 15 меңгә якын атама эшләнде, татар теле гыйлем теленә әйләнде»,* – дип яза[26].

Г.Шенаси, табигать фәннәреннән тыш, педагогика һәм тәрбия тарихы, укыту һәм тәрбия методикасына багышланган китаплар, шулай ук фән һәм техника үсешенең төрле тармакларына багышланган фәнни-популяр брошюралар авторы да. Аның «Тәгълим вә тәрбия тарихы вә дөньяның философлары» дигән китабы 1911 елда Уфада, укытучылар институтлары өчен, дини тәрбиягә багышланган «Ысул тәглим вә тәрбиядән фәнни тәдрис» хезмәте 1912, 1918 елларда Оренбургта дөнья күрә. Әмма революциядән соңгы вазгыятьне истә тотып, автор хезмәтенең хаклыгын шик астына куя. 1933 елның 13 сентябрендә язылган автобиографиясендә үз китабын «идеологик яктан зарарлы», дип атый. 1924 елда Казанда укыган «Фән һәм мөселман дине» дигән лекциясендә революциягә кадәрге карашларының дөрес булмавы турында да әйтә. Аның «Кыскача биология», «Матдә төзелеше», «Җан бармы?», «Җир өстендә башлап тереклек яратылу» кебек китаплары, революциягә кадәрге хезмәтләреннән аермалы буларак, материалистик карашка нигезләнеп язылган.

Габдулла Шенаси педагог, галим һәм дәреслекләр авторы буларак кына түгел, киңкырлы җәмәгать эшлеклесе буларак та милләттәшләребез алдында танылу ала.

[23] Шенаси Г. Шунда ук. – Б.71.

[24] Шенаси Г. Мохтәсар химия. 1 кис.– Б.3.

[25] Шенаси Г. Шунда ук.

[26] Шенаси Г. Ун ел эчендә... – Б.71.

1913 елда Уфада Халык мәгарифе университеты ачыла. Г.Шенаси аның президиум әгъзасы була. Нәкъ шушы елларда ул өлкәннәр арасында да мәгърифәт тарату эшен башлап җибәрә. Бу эшчәнлек, иң беренче чиратта, табигать белеме буенча лекцияләр әзерләү һәм аны төрле катлам халык арасында укудан гыйбарәт. Мәсәлән, 1921 елда ул Уфа җәмәгатьчелеге алдында «Материя һәм энергия» дигән темага чыгыш ясый. 1921-1923 елларда шундый ук лекцияләр Эстәрлетамак, Троицк, Чиләбе, Пермь, Оренбург кебек шәһәрләрдә укыла. 1928 елда Г.Шенасиның Сәмәрканд шәһәрендә дә халыкны кызыксындырган сораулар буенча шактый эчтәлекле генә чыгыш ясавы билгеле.

1914 елда Петербург шәһәрендә узган Бөтенроссия физика, химия һәм космография укытучылары съездында, 1917 елның апрелендә Казан шәһәрендә Бөтенроссия татар укытучылары съездында катнашу да Г.Шенасиның фәнни-педагогик эшчәнлегенә зур йогынты ясый. Соңгысында Г.Шенасиның татар мәктәпләрен үзгәртеп кору проекты белән чыгыш ясавы билгеле. Бу съездда мөселман укытучыларның үзәк бюросы оештырыла. Аның составында Г.Шенаси да сайлана. Бюро эше вакытында ул татар башлангыч мәктәп укытучылары өчен программалар әзерләүдә катнаша. Шенаси II Бөтенроссия мөселман съездына һәм анда оештырылган мөселман милли идарәсенең әгъзасы итеп тә сайлана.

«Хөсәения» мәдрәсәсе укытучыларының, шул исәптән, Г.Шенасиның дәреслекләре һәм укыту кулланмалары Идел-Урал, Себер һәм Төркестан мөселман уку йортларында киң файдаланылган[27]. Шенасиның химия, физика дәреслекләре элеккеге СССРда яшәүче күп кенә төрки халыклар – казакъ, үзбәк, башкорт, шулай ук таҗик теленә тәрҗемә ителә. Татар һәм үзбәк урта мәктәпләре өчен физика дәреслеге Казанда басылып чыга. Шулай итеп, Габдулла Шенаси – татарлар өчен генә түгел, башка төрки халыкларның мәгарифе үсешенә дә шактый зур өлеш керткән педагог-галим, дияргә тулы хакыбыз бар. Гомумән алганда, Г.Шенасиның 50дән артык дәреслек һәм фәнни-популяр китабы дөнья күрә. Моннан тыш, төрле фәннәрне укыту, тәрбия, атамалар һәм фән-техника мәсьәләләренә багышланган күп санлы мәкаләләре татар матбугаты битләрендә даими басыла.

Әмма, бик тә кызганыч, сәяси репрессия чорының ачы җиле, татарның башка бик күп зыялы уллары белән беррәттән, күренекле педагог һәм җәмәгать эшлеклесе Г.Шенасины да читләтеп үтми. Габдулла Сабир улы Ибраһимов (Шенаси) 1938 елның 23 мартында «Идел-Урал» эше буенча гаепләнеп кулга алына[28] һәм шул ук елның 3 ноябрендә атып үтерелә. 1958 елның 27 гыйнварында, соңлап булса да, Идел буе Хәрби округы хәрби трибуналы карары нигезендә аның гаепсезлеге таныла, исеме аклана. Кабере Казанның Архангель зиратында... ■

[27] Шарипов А.А.Роль медресе... – С.74.

[28] Степанов А.Ф. Расстрел по лимиту. Из истории политичечких репрессий в ТАССР в годы «ежовщины». – Казань: «Новое знание», 1999. – С.274.

Күпгасырлык татар сүз сәнгате әдип-шагыйрьләргә гаять бай. Аларның саны гына да, мөгаен, ике-өч меңгә якынаядыр. Әмма, ни кызганыч, элеккеге иҗат әһелләренең күпчелеге әле бүгенге укучыга юньләп билгеле түгел.
Бер гаҗиб бу кем шәһәрнең эче тулуг:
Шагыйрь улмыш барча кечек һәм олуг.

Мөхәммәдьярларга тиң шәхес

(Шакир ага Абиловның тууына 100 ел тулу уңаенннан)

Хатыйп Миңнегулов

XVI йөзнең урталарында Казан каласын күздә тотып язылган әлеге юллардан бу шәһәрдә шагыйрьләрнең бик күп булуы аңлашыла. Әмма без аларның бары дистәдән артыгын гына беләбез. Болгар-Хәзәр, Алтын Урда, XVII йөзләр белән дә шундый ук хәл. Гомумән, әдәбият тарихын өйрәнү — шактый кыен һәм катлаулы шөгыль. Ә инде борынгы һәм урта гасыр, өлешчә XIX йөз татар сүз сәнгатен гыйльми тикшерү аеруча авыр һәм мәшәкатьле. Чөнки ул, саф әдәбиятчы булудан тыш, шактый дәрәҗәдә телче, тарихчы, археограф, текстолог, дин белгече булуны, гарәп, фарсы, төрки телләреннән һәм әдәбиятларыннан хәбәрдарлыкны да таләп итә. Шуңа күрә дә бу өлкәгә керүчеләр, анда нәтиҗәле эшләүчеләр бик аз. Г.Утыз-Имәни, Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Р.Фәхреддин, Г.Газиз, Г.Рәхим, Г.Сәгъди, Н.Хәким, Н.Исәнбәт, Б.Яфаров, Г.Таһирҗанов. Х.Госман, Үлмәс Беляева, А.Фәтхи, М.Госманов, М.Әхмәтҗанов, М.Гайнетдинов һәм янә берничә исем. Шакир Шиһап углы Абилов (1915-2004) әнә шул чагыштырмача аз санлы фидакяр затлар арасында үзенә лаеклы урынны били. Ни куаныч, миңа бу олуг шәхес белән өч дистә елдан артык аралашырга, хезмәттәшлек кылырга туры килде. Ул минем кандидатлык диссертациясенең (1972) рәсми оппоненты, аерым хезмәтләремнең мөхәррире, рецензенты булды; минем хакта мәкаләләр дә язды. Әгәр дә мин фәндә азмы-күпме уңышларга ирешкәнмен икән, монда Шакир аганың да сизелерлек өлеше бар. Мин — этисез үскән ятим бала. Бу мөхтәрәм остаз миңа кайвакыт «Хатыйп улым» дип дәшә иде. Шунда минем күңелләр тулып киткәне әле дә хәтеремдә.

Шакир аганың гомер юлы шактый озын, борылмалы, катлаулы [1]. Ул, күп кенә соңгы дәвер татар зыялылары кебек Казан артыннан, яисә Әлмәт, Актаныш, Буа тарафларыннан түгел, ә Урал артыннан — Чиләбе якларыннан. Биредә хәзерге Коншак (Конашак) районы составында үзе дә район үзәге кебек зур, рәсми телдә, Усть-Багаряк дип йөртелә торган татар авылы (Түбәнавыл) бар. Ул Чиләбедән 120

чакрым ераклыкта. Аның бер өлеше элегрәк Яңавыл исемле аерым бер карья булган. Хәзер инде алар кушылган. (Мин биредә 1968 елның июль башларында Казан дәүләт университетының беренче курс студентлары белән фольклор экспедициясендә булган идем. Концертлар да куеп йөрдек. Арада Рашат Низамиев, Рәшит Бәшәр, Нәҗибә Сафина, Әнвәр Хәйри, Рушания Низамова һәм киләчәктә әдип булып танылачак янә берничә студент бар иде). Булачак галим 1915 елның 18 июнендә (Кайбер чыганакларда 15 нче июлендә) нәкъ менә шушы, матур табигатьле Яңавылда игенче гаиләсендә дөньяга килә. Фәндә бу авылга XVII-XVIII гасырларда мишәр татарлары нигез салган, дип карала.

Шакир аганың нәсел-нәсәбе шактый укымышлы була. Аның үзе сөйләвенчә, бабасы Коръәнне яттан белә, китаплар күчереп яза. 1943 елда бакый дөньяга күчкән Шиһап абзыйның 7 баласы була (Шакир — шуларның бишенчесе), шуның өчесе Бөек Ватан сугышында ятып кала, берсе фин сугышыннан инвалид булып кайта.

Ш.Абилов әүвәл үз туган төбәгендәге мәктәпләрдә укый. Алтынчы сыйныфны тәмамлагач, 1932-1934 елларда Свердловск педагогия институты каршындагы татар-башкорт рабфагында белем ала. Биредә аны татар теле һәм әдәбиятыннан Г.Тукай, Г.Ибраһимов, Ф.Әмирхан белән аралашкан, үзе дә әдәби иҗат белән шөгыльләнгән Ризван Алуши (Ибраһимов) (1883-1938) укыта. Булачак галим бу елларда тел-әдәбият белән ныклап кызыксына башлый, шигырьләр дә язгалый. Сүз сәнгате белән мавыгу 19 яшьлек Шакирны Оренбург педагогия институтының татар филология бүлегенә алып килә. Биредә ул 1934-1938 елларда укый.

Мәгълүм ки, Оренбург XIX йөзнең икенче яртысында-XX гасырның беренче чирегендә татар яшәешенең, мәдәниятенең Казан кебек дип әйтерлек мөһим бер үзәге була. Биредә атаклы «Хөсәения» мәдрәсәсе, театр эшли, «Вакыт», «Шура» кебек мәшһүр гәҗит-журналлар чыга, күп меңләгән тираж белән татар китаплары басыла. Ризаэддин Фәхреддин, Дәрдемәнд, Фатыйх Кәрими, Шәриф Камал, Шакир Мөхәммәдов, Зариф Бәшири, Һади Такташ, Шәехзадә Бабич, Афзал Таһиров һәм күп кенә башка әдипләр бу шәһәрдә гомер кичерә яисә яшәп ала. Өстәвенә 1920-1925 елларда Оренбург Казакъ («Кыргыз») автономияле җөмһүриятенең башкаласы да булып тора. (Аннан ул Кызыл Ордага, бераздан Алматыга күчерелә.) Анда татар зыялылары казакъның Сәкен Сәйфуллин (1894-1938), Әхмәт Байтурсынулы (1873-1938), Беимет Майлин (1896-1938) һәм башка әдипләре белән аралашып, бер казанда кайный. Әмма Сталин дәверендә Оренбург үзенең элеккеге татарлыгын җуя бара. Шулай да 30 нчы елларда биредә әле миллилек билгеле бер дәрәҗәдә саклана. Шакир аганың үзенең сөйләвенчә, Оренбург пединститутында аларны, үз мөгаллимнәреннән тыш, Казаннан Г.Нигъмәти, М.Майлин, В.Хангильдин, С.Байков, Л.Җәләй, Х.Бәдигый кебек күренекле галимнәр дә килеп укыта. Аның сабакташлары арасында Әсфәндияр Чинбай (Ишгай) (1908-1992) [3: 244-245], Хисам Мөхәммәтов кебек каләм тибрәтүчеләр дә була. Институтта уку елларында Ш.Абилов берара «Оренбург коммунисты» гәҗитендә дә эшләп ала, биредә үзенең шигырьләрен һәм «Габдулла Тукай һәм халык авыз иҗаты» дигән күләмле мәкаләсен дә бастыра; редакция каршындагы әдәби-иҗат түгәрәгендә актив катнаша; бер еллап өлкә радиосыннан татарча тапшырулар да алып бара.

Институтны уңышлы тәмамлаганнан соң, Ш.Абилов 1938-1940 елларда Актаныш урта мәктәбендә тел-әдәбият укытучысы булып эшли. Шушында ук ул, Агыйдел буе кызына өйләнеп, гаилә корып та җибәрә. Минем чын татар хатын-кызларына хас тыйнак табигатьле Наилә апаны берничә мәртәбә күргәнем булды. Дүрт балаларының берсе — кызлары безнең чорда Казан университетының урыс-татар бүлегендә укыды.

1940 елның сентябрендә Ш.Абилов хәрби хезмәткә алына. Политик курсларда да укый. Бөек Ватан сугышының беренче көннәреннән (25 июнендә) аны фронтка җибәрәләр. Днепр һәм Дон буйлары, Сталинград, Белоруссия, Варшау, Берлин — болар бар да Шакир ага үткән урыннар. Ул сугышчы һәм офицер, штаб һәм политидарә хезмәткәре дә, хәрби журналист та. Әүвәл «Красная Армия», 1944 елдан, Гадел Кутуй, Гариф Галиев, Ибраһим Гази белән берлектә, «Кызыл Армия» исемле фронт гәҗитләрендә эшли. Берничә мәртәбә яралана. Сугышта

күрсәткән батырлыклары өчен «Беренче дәрәҗә Бөек Ватан сугышы ордены», «Кызыл йолдыз» һәм дистәдән артык медаль белән бүләкләнә. Аңа 1967 елда «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем дә бирелә.

Алты ел хәрби хезмәттә булганнан соң, майор Ш.Абилов 1946 елда демобилизацияләнә һәм Урал якларына кайта. Каменец-Уральск каласындагы һөнәр училищесында 4 ел буе директор урынбасары булып эшли. 1951-1955 елларда туган төбәгендә урта мәктәп директоры, район мәгариф бүлеге мөдире вазифаларын башкара. Абруе, тормыш тәҗрибәсе бар. Район, өлкә күләмендә тагын да югарырак, җаваплырак эшләргә чакырып торалар. Әмма яшьли үк туган телен, әдәбиятын яраткан, азмы-күпме әдәби иҗат, гыйльми эш белән шөгыльләнгән Шакир аганы татарның мәркәзе Казан үзенә тартып тора. Ниһаять, дөньяның ачысын-төчесен күргән, дүрт балалы, 40 яшьлек бу зат 1955 елда Тел, әдәбият һәм тарих институтына аспирантурага килеп керә һәм 1958-1986 елларда биредә үк эшли дә. Торырга даими урыны, гаиләне карарга һәм туендырырга тиешле мөмкинлекләре булмауга да карамастан, бу фидакяр зат башыаягы белән әдәбият, фән дөньясына чума, күпләгән чыганакларны, язма истәлекләрне өйрәнеп, күренекле әдәбият галиме һәм тәнкыйтьче Гали Халит җитәкчелегендә Казан ханлыгы чоры шагыйре Мөхәммәдьяр хакында кандидатлык диссертациясен төгәлли һәм аны 1960 елда уңышлы гына яклап, 1961 елда филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә ала; оппонентлары — күренекле тюркологлар — Н.Баскаков, Җ.Киекбаев һәм башка чыгыш ясаучылар бу хезмәтне югары бәяли.

Шакир аганың гыйльми эшчәнлеге шактый бай һәм күпкырлы. Әмма аның үзәгендә, йөзек кашы кебек, Мөхәммәдьяр тора. Ул бу шагыйрьнең әдәби иҗатын киң мәдәни-тарихи яссылыкта, татар язмышы белән тыгыз мөнәсәбәттә, халыкара багланышлар контекстында карый, әдәби-сәнгати байлыгын ача; аның яңа кулъязмаларын таба, аларны текстологик яктан җентекләп, тәнкыйди өйрәнә, тиешле шәрех-аңлатмалар белән басмага әзерли.

Татар сүз сәнгате белән кызыксынучыларга, тел-әдәбият мөгаллимнәренә, аеруча югары уку йортларының татар бүлегендә укыганнарга 1963 елда дөнья күргән күләмле «Борынгы татар әдәбияты» китабы яхшы таныш. Бу «яшел тышлы» (аны еш кына шул исем белән йөртәләр), бай эчтәлекле басма шактый озак еллар буе студентларга урта гасыр әдәбиятыннан төп дәреслек-хрестоматия булып хезмәт итте. Хәзер дә әле аңа без еш мөрәҗәгать итеп торабыз. Мөхәммәдьяр бүлекләре мөхтәрәм Шакир ага тарафыннан әзерләнгән. Аларда бай, фактик материал тупланган, кызыклы, мөһим күзәтүләр бар. Әдәби әсәрләрдән үрнәкләр дә бирелгән. Ш.Абилов 1966 елда Мөхәммәдьярның ике әсәрен дә («Төхфәи мәрдан», «Нуры содур») туплаган тәүге җыентыгын, гәрчә әдәби текстларны бераз кыскартып булса да, бастыруга ирешә [3]. Ул кереш мәкалә, шәрех-аңлатмалар белән дә тәэмин ителгән.

Тынгысыз һәм эзләнүчән табигатьле галим Мөхәммәдьяр иҗатын өйрәнүне, тагын да тирәнрәк тикшерүне, шулай ук халыкка һәм фән галәменә җиткерү эшен алга таба да дәвам итте. Шуның күркәм бер нәтиҗәсе буларак, 1997 елда шагыйрь әсәрләренең тулы, гыйльми, бер үк вакытта үтемле, популяр да булган яңа бер басмасы дөнья күрде [4]. Биредә Мөхәммәдьяр әсәрләренең

(өчесенең дә) тәнкыйди тексты, хәзерге телгә әдәби тәрҗемәләре, гаять бай эчтәлекле кереш мәкалә (6-31 б.), «Аңлатмалар», шагыйрь турында «Библиография» (60 исемдә) урнаштырылган. Китапта шулай ук Миркасыйм Госмановның «Мөхәммәдьяр: бөеклек фаҗигасе» дип исемләнгән мәдәни-тарихи характердагы мәкаләсе дә бар. Җыентык без фәкыйрегезнең — махсус мөхәррирнең — «Бөекләребезнең берсе» дип исемләнгән мәкаләсе белән ачыла.

Мәгълүм ки, 1997 елның августында ЮНЕСКО карары белән Татарстанда гына түгел, гомумән татар дөньясында Мөхәммәдьярның тууына (якынча) 500 ел тулу киң күләмдә билгеләп үтелде, төрле чаралар үткәрелде. Шушы уңай белән Г.Камал исемендәге Татар дәүләт Академия театры бинасында тантаналы кичә булды. Анда Татарстан Президенты М.Шәймиев бай эчтәлекле доклад та сөйләде [5]. 1997 елда татар, урыс һәм инглиз телләрендә Мөхәммәдьяр турында бизәкле, иллюстратив басма да дөнья күрде [6]. Бөек шагыйрь юбилеен гыйльми әзерләүдә, иҗатын халыкка җиткерүдә башлап йөрүче һәм төп йөкне тартучы, фронтовик Шакир ага Абилов булды. Гомумән, ул гомеренең ахырына кадәр Мөхәммәдьярдан аерылмады. Урта гасыр татар әдәбиятының 1999 елда урысча нәшер ителгән басмасында, мәсәлән, аның бу шагыйрь турында бик саллы эчтәлекле мәкаләсе бар. Бу мөхтәрәм галимнең күпьеллык эзләнүләре нәтиҗәсендә Мөхәммәдьяр киң катламга яхшы таныш, рухи тормышыбызда үзенә лаеклы урынны алды, аның әсәрләре антологияләргә дәреслек-хрестоматияләргә кертелде. Шакир ага хезмәтләренә нигезләнеп, бу олуг шагыйрь хакында Әхмәт Рәшит, Мөсәгыйть Хәбибуллин, Батулла тарафыннан әдәби әсәрләр языла, галимнәребез үз тикшеренүләрен дәвам иттерә. Мәсәлән, Марсель Әхмәтҗанов дипломатик миссия белән Мәскәүгә җибәрелгән Мөхәммәдьярның 1549 елның җәендә Явыз Иван әмере белән Муром тирәсендә ерткычларча үтерелүен ачыклады.

***

Шакир ага, Казан ханлыгы чорының бөек шагыйрен һәм фикер иясен өйрәнү белән беррәттән, урта гасыр әдәбият тарихының башка бик күп мәсьәләләрен дә киң планда, системалы итеп тикшерү белән шөгыльләнде. Билгеле ки, әдәбият фәне үзен даими рәвештә яңадан-яңа чыганаклар, факт-мәгълүматлар белән баетып торганда гына тиешенчә үсә һәм үз вазифаларын үти ала. Шәхес культы чорында исә безнең күп кенә язма истәлекләребез юкка чыгарылды, аларны өйрәнүчеләрнең шактый өлеше репрессия корбаннары булды яисә миңгерәүләтелде. «Хрущев җепшеклеге» дип йөртелгән чор башлангач, элеккеге мираска караш билгеле бер дәрәҗәдә уңай якка үзгәрде (Мөхәммәдьярны өйрәнү дә шуның бер гәүдәләнеше иде). Шушы мөмкинлекләрдән файдаланып, гыйлем әһелләребез үткәндәге язма истәлекләрне, әдәби әсәрләрне, фольклор материалларын барлау, туплау, өйрәнү эшенә ныклап керештеләр. Шакир ага да бу игелекле эш-хәрәкәтнең үзәгендә торды. Ул, йә үзе генә яисә кайбер башка хезмәттәшләре белән берлектә, татарлар яшәгән төбәкләргә оештырылган күп санлы археографик экспедицияләрдә катнашты, йөзәрләгән кульязмалар, басма китаплар табып, үзе эшли торган институт китапханәсенә тапшырды, аларны тасвирлау-өйрәнүгә дә зур өлеш кертте. Өстәвенә, бу тынгысыз галим Мәскәү, Ленинград, Ташкент,

Баку, Дүшәнбе, Ашхабад, Ереван һәм кайбер башка калаларның архив-китапханәләре белән дә танышып, аларда теге яки бу дәрәҗәдә татарга, төрки сүз сәнгатенә мөнәсәбәтле материаллар тапты. Болар бар да аның гыйльми офыкларын киңәйтте, карашларын тирәнәйтте, хезмәтләрен мөһим һәм кызыклы факт-мәгълүматлар, яңа фикерләр, яңа исемнәр белән баетты. 1679 елда туып, ике гасыр аралыгында әдәби иҗат белән шөгыльләнгән, Мәүла Колый традицияләрен уңышлы дәвам иттергән Габди һәм аның әхлакый-инсани эчтәлекле шигъри парчалары хәзерге укучыларга шактый таныш. Ә бит бу авторны фәнгә тәүге танытучы, әсәрләрен гавамга җиткерүче зат — Шакир ага [7]. Шунысын да искәртик: гарәп, латин язулы чыганаклар белән иркен эш итүче бу мөхтәрәм галим фәнни эштә дәлиллелекне, хакыйкатькә тугрылыкны һәрчак үзенең юлдашы итте, элеккеге әдәби текстларны уку-аңлатуның, шәрехләүнең матур үрнәкләрен бирде, хезмәттәшләреннән дә шуларны таләп итте. Мин аның кечкенә генә детальләргә, факт-мәгълүматларга да гаять игътибарлы булуына соклана идем. Шакир аганың, галим буларак, янә бер сыйфатын күрсәтәсем килә. Ул үзенең тикшеренү нәтиҗәләре белән татар дөньясында гына түгел, киңрәк мәйданда — төрле шәһәрләрдә уздырылган халыкара, бөтенсоюз конференцияләрендә, урыс, үзбәк, төрек һәм кайбер башка телләрдәге журнал-җыентыкларда да чыгыш ясый иде. Мәсәлән, аның «Советская тюркология» журналында (1970. — №6. — 84-87 б.) басылган «Кутадгу билиг» в булгаро-татарской литературе» дип исемләнгән мәкаләсе киң фәнни җәмәгатьчелектә бер мөһим ачыш, вакыйга рәвешендә кабул ителде. Аңа хәзергә кадәр сылтамалар ясалып тора. Галимнең «Нәһҗел-фәрадис» һәм кайбер башка ядкярләр хакында да шундый характердагы мәкалә-чыгышлары бар [8; 9].

Шакир ага — халкыбызның болгар чорын, аның рухи тормышын, әдәбиятын да шактый җентекле өйрәнгән зат. Аның бу дәвергә, шулай ук «Кыйссаи Йосыф»ка мөнәсәбәтле язмалары да укучыларга билгеле.

Ш.Абилов, гәрчә кайвакыт болгарчылык идеясе белән мавыгыбрак китсә дә, Алтын Урда чоры татар тарихын һәм әдәбиятын өйрәнүгә җитди игътибар бирде. Аның Харәзми, Мәхмүд Болгари, Хисам Кятиб турында күптөрле чыганакларга нигезләнеп язылган тирән эчтәлекле мәкалә-хезмәтләре бар. Галим Мәүла Колый иҗатын, XVII йөзгә мөнәсәбәтле әдәби-тарихи әсәрләрне («Җәмигъ эт-тәварих», «Дәфтәре Чыңгызнамә»...) фәнни яктыртуга да үзеннән зур өлеш кертте.

Нигездә, XIX йөздә Ш.Мәрҗани, К.Насыйри, Р.Фәхреддиннәрдән башланган татар әдәбияты тарихын өйрәнү фәне бер гасыр вакыт эчендә, төрле киенлык-киртәләргә дә карамастан, шактый гына уңышларга иреште: дистәләгән җыйнама хезмәтләр (аеруча Г.Газиз, Г.Рәхим, Г.Сәгъди, М.Гайнуллин... китаплары), дәреслек-хрестоматияләр, күпләгән монографияләр дөнья күрде. Узган гасырның 70 нче елларында татар сүз сәнгатенең тууыннан алып хәзергәчә үткән юлын яктырткан күптомлык әдәбият тарихын язу бурычы көн тәртибенә куелды. Г.Ибраһимов исемендәге институтта аның беренче план-проспекты төзелде һәм ул 1972, 1973 елларда татар һәм урыс телләрендә басылып та чыкты. Киң фәнни, мәдәни, мәгърифәти җәмәгатьчелек катнашында кат-кат тикшерелгән план-проспект теге яки бу дәрәҗәдә үзгәртелде, тагын да камилләште. Дөрес, бу зур хезмәтне

язарга тотыну иртәрәк әле, аерым чорларны, әдипләрне, проблемаларны ныграк тикшерергә кирәк, диючеләр дә булды. Әмма аерым мәсьәләләрне махсус өйрәнү һәм әдәбият тарихын язу эшләрен үреп бару мәгъкуль күрелде. План-проспект нигезендә язылачак алты томның да эчтәлек-структурасы, чикләре билгеләнде. Том җитәкчеләре дә тәгаенләнде: I т. — Ш.Абилов, II т. — М. Гайнуллин, III т. — Г. Халит, IV т. — Н.Юзиев. V т. — Н.Гыйззәтуллин, VI т. — Ф.Мусин; хәзерлекле авторларны туплау буенча да күп эшләр башкарылды.

Шакир ага — күптомлылык татар әдәбияты тарихын язу идеясен күтәрүчеләрнең берсе. Үзенә тапшырылган томны, ягъни борынгы һәм урта гасыр чорын язуга ул шәхсән зур әзерлек, саллы мая белән кereште. Авторлар белән эшләүгә дә гаять җаваплы карады. (Без фәкыйрегез андагы бер бүлекне язуда катнашты.) Дистә еллап вакыт эчендә татар әдәбиятының борынгыдан алып XIX йөзгә кадәр чорны үз эченә алган күләмле (40 басма табак, 567 бит), факт-мәгълүматларга, мөһим күзәтү-тикшеренүләргә бай булган беренче том язылып, 1984 елда нәшер ителде. [10]. Аны язуда ике дистәгә якын галим катнашты. Әмма китаптагы 37 бүлекнең 18е, ягъни 241 бите Шакир ага тарафыннан язылган. Өстәвенә ул томның җитәкчесе һәм җаваплы мөхәррире дә. (Аны басмага әзерләүдә, редколлегия әгъзасы сыйфатында Н.Хисамов белән миңа да катнашырга туры килде.) Юкка гына бу китапны еш кына «Шакир Абилов томы» дип йөртмиләр. Бу басма — мөхтәрәм галим хезмәтләренең иң зурысы һәм иң җитдие. Беренче том басылып чыкканнан соңгы ике дистә ел эчендә дөньяда, илдә бик күп үзгәрешләр булды. Әмма бу китап, хосусый характердагы совет чорына хас аерым җитешсезлекләрне, бәхәсле якларны исәпкә алмаганда, борынгы һәм урта гасыр татар әдәбиятын чагыштырмача тулы, фәнни югарылыкта яктырткан җыйнама гыйльми хезмәт булып калуында дәвам итә. Без моның өчен иң беренче чиратта Шакир агага бурычлы һәм рәхмәтле. Беренче томның бераз кыскартылган, өлешчә үзгәртелгән урыс телендәге басмада да бар [11]. Анда да төп урынны бу олуг зат язмалары алып тора.

Билгеле булганча, Тукайгача чор татар сүз сәнгате шәрык (гарәп, фарсы, аеруча төрки) әдәбиятлары белән тыгыз бәйләнештә яши һәм үсә. Шул хакыйкатьне күздә тотып, Шакир ага да үз хезмәтләрендә әдәби бәйләнешләргә, аларның рухи тормыш тарихында тоткан урыннарына даими игътибар бирә. Галимнең Низами, Нәваи, Лотфый кебек күренекле Шәрык классиклары, аларның татар әдәбияты белән бәгланышлары турында бик эчтәлекле мәкаләләре бар [12; 13; 14]. Гомумән, Ш.Абиловны төрки дөньяда да яхшы беләләр. Үзбәк галимнәре Ширали Турдыев һәм Ләлә Мәгъсумова, казакъ әдәбиятчысы Бөркет Ыскаков, комык Солтанморад Акбиев һәм тугандаш төрки кавемнәрнең кайбер башка гыйлем әһелләре Шакир агага үзләренең остазлары кебек карый.

Мөхтәрәм галимебез Мөхәммәдьяр иҗатын, борынгы һәм урта гасыр әдәбиятын өйрәнү белән генә чикләнмәде. Аның XIX-XX гасыр әдәбиятына, җөмләдән Акмулла, Г.Тукай, Г.Кутуй кебек шагыйрьләр, мөһим фәнни-теоретик мәсьәләләр хакында да язмалары бар. Мәсәлән, бер мәкаләсендә ул Г.Тукайның «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» поэмасын чагыштырма-генетик планда тикшерә, элеккеге әдәби традицияләрнең бөек шагыйрь иҗатында ничек, ни рәвешле дәвам иттерелешен, файдаланылуын ачыклый [15]. Галимнең иҗат методы,

суфыйчылык турында язмалары да заманында зур кызыксыну белән кабул ителгән иде.

«Татар энциклопедиясе»ндәге шактый гына мәкаләләр Шакир ага тарафыннан язылган. Гомумән, ул бу энциклопедиягә үзенең киңәш-тәләкләре белән нык кына ярдәм итте. Үзара әңгәмә вакытларында ул 90 нчы елларда XX йөзгә кадәрге татар әдипләре, галимнәре турында биобиблиографик белешмә төзүен кат-кат телгә ала иде. Бу хезмәтнең язмышы ничек булгандыр, — анысын хәзергә белмим. Гомумән, бу галимнең мирасы, шәхси архивы, ул махсус, җентекле өйрәнүне көтә.

Ш. Абилов башка төрле гыйльми, иҗтимагый, мәдәни, мәгърифәти эшләрдә дә актив катнашты. Казан педагогия институтында 9 ел буена студентларга борынгы һәм урта гасыр татар әдәбиятыннан лекцияләр укыды. 17 ел дәвамында Тел, әдәбият һәм тарих институтында археографик комиссияне җитәкләде. Республика Милли музеенда гыйльми совет әгъзасы булып торды. Һәм гомумән башка бик күп төрле җәмәгать эшләрен башкарды.

Шакир ага Абилов, гәрчә формаль яктан фән кандидаты гына булса да, мөгаен, әдәбият фәненә, халкыбызның мәдәни-интеллектуаль үсешенә аерым доктор-профессор-академикларга караганда да күбрәк өлеш керткәндер. Аның хезмәтләре бүгенге тормышыбызда да яши, адәм балаларын инсани һәм әхлакый яктан баета, үстерә. Галимнең күп санлы шәкертләре, дәвамчылары бар. Мин шәхсән үземне дә шуларның берсе дип санаем. Күренекле археолог, тарихчы Альберт Борһанов та якташы Шакир аганы үзенең остазы, дип хисаплый. ■

Әдәбият

1. Шакир Абиловның тормышы, эшчәнлеге хакында аерым язмалар бар: а) Ильмира Кузәхмәтова. Бәрәкәтле гомер юлы // Мәгърифәт. 3.06.1995. Мәкаләнең авторы — IV курс студенткасы — бу язмасын минем җитәкчелектә әзерләде; б) Р.Исламов. Фәнгә багышланган гомер // Шәһри Казан. — 21.06.1995; в) Х.Миңнегулов. Һаман да сафта (әдәбиятчы галим Шакир ага Абиловка — 80 яшь) // Ватаным Татарстан. — 17.06.1995; г) Х. Миңнегулов. Әдәбият фәненең аксакалы (Ш. Абиловка 85 яшь тулу уңае белән) // Мәгърифәт. — 17.06.2000. Шул ук язма: Х.Миңнегулов. Гасырлар өнен тыңлап... — Казан: Мәгариф, 2003. — 232-236 б. Бу мәкаләләрне язганда мин Шакир аганың үзеннән дә турыдан-туры шактый мәгълүматлар алган идем. Биредә ул вакытта тупланган белешмә-материаллар да файдаланылды.
2. Хатыйп Миңнегулов. Чит илләрдәге татар әдәбияты. — Казан: Мәгариф, 2003. — 399 б.
3. Мөхәммәдьяр. Тәхфәи мәрдан. Нуры содур // Басмага әзерләүче Ш. Абилов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1966. — 150 б.
4. Мөхәммәдьяр. Нуры содур // Басмага әзерләүче Шакир Абилов. Махсус мөхәррире Хатыйп Миңнегулов. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1997. — 336 б.
5. М.Шәймиев. Урта гасырның бөек шагыйре һәм фикер иясе (Мөхәммәдьярның 500 еллык бәйрәм кичәсендә Татарстан Президенты сөйләгән доклад) // Мирас. — 1997. — №11. — 5-15 б.
6. Мөхәммәдьяр һәм аның чоры. Мухаммедьяр и его время. Mohammediar and his Time. — Казань: Изд.-во «Гасыр». Изд.-во «Рухият», 1997.
7.Абилов Ш. Поэзиябез тарихына яңа исем (Габди. — Х. М.) // Казан утлары. — 1978. — №10. — 141-147 б.
8. Абилов Ш. О новонайденных списках памятника XIV века «Нахдж ал-фарадис» // Советская тюркология. — 1977. — № 2. — С.69-73.
9. Абилов Ш., Максудова З. «Гөл вә Нәүруз» дастанының Казан кулъязмасы // Узбек теле ва адабиёти (Ташкент). — 1968. — №6.
10. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. I том. Урта гасырлар дәвере. — Казан: Татар. кит. нәшр., 1984. — 567 б.
11.Средневековая татарская литература VIII-XVIII вв. — Казань: Фэн, 1999. — 240 с.
12. Абилов Ш. Татар поэзиясендә Нәваи // Казан утлары. — 1966. — №6. — 107-109 б.
13. Абилов Ш. Низами һәм татар әдәбияты // Казан утлары. — 1983. — №3. — 166-171 б.
14. Абилов Ш., Максудова З. Лотфый Идел буйларында // Казан утлары. — 1968. — №6. — 138-142 б.
15. Абилов Ш. Ш. Литературные версии легенд о «Кисекбаше» и поэма Г.Тукая «Сенной базар, или Новый Кисекбаш» / В сборнике: Габдулла Тукай. — Казань: Таткнигоиздат, 1968. — с.169-171.

Кыз балаларга тәрбия бирү хакында

Тәэминә Биктимерова

Дөньяның акыл ияләре дә, төрле-төрле күрәзәчеләр дә XXI гасырны «Хатын-кыз гасыры» булыр, дип юраганнар иде. «Хатын-кызлар зыялы, тәрбияле булыр», дип өметләнгәннәр микән? Һәрхәлдә, Россиядә яшәүче хатын-кызлар күздә тотылмаган, диясе килә. Бүген бу юрауларга ышану кыен инде. Чөнки дөньябызның ни хәлдә булуын барыбыз да күреп, әрнеп-көенеп торабыз. Җирдә миһербанлылык, рәхим-шәфкать, мәхәббәт көннән-көн кими бара. Көн саен телевизор экраннарыннан теләсә нинди утлы корал белән кешеләргә төбәп атучы, җинаятьче хатын-кызлар күрсәтелә, мактала...

Шул ук вакытта хатын-кызларның хәлләре чиксез авырая бара. Алар моңарчы колак ишетмәгән, күз күрмәгән кыен хәлләргә юлыкты: эшсезлек, йорт-җирсез, туган илсез калу; наркомания, СПИД, көчләүләр арту һ.б...

Заманында югары белем алуга ирешкән хатын-кызлар бер мизгелдә совет хатын-кызларыннан «базар хатыннары»на әверелеп калды. Соңгы елларда күпме гаилә җимерелде. Әхлакый кануннарыбыз бик күпләр өчен кирәксезгә әйләнде, бик күпләр өчен артка чигенде. Сату-алу эшенә керешкән хатын-кызларның шактый өлеше кол дәрәҗәсенә төшерелде. Дөньяга кеше кадәр кеше тудыручы, кешелекнең гомер җебен дәвам иттерүче затның шушы хәлгә төшүе милләткә карата атом-төш коралы куллану белән бертигез түгелме?

Баланың яшәү рәвешен, телен, иманын «иң элек һәм гомерлеккә» дип әнкәсе сеңдерә. Пәйгамбәребез Мөхәммәд галәйһиссәлламнең: «Ана, Ана, тагын бер тапкыр Ана, бары шуннан соң гына Ата», — дигән гыйбрәтле сүзләре нәкъ менә шул хакыйкатьне аңлата бит инде. Әйе, милләтнең рухын саклау Ана булган бөек затка йөкләнгән. Татарның киләчәге дә иң әүвәл ана карынында, бишектә хәл ителә.

Татарстан парламенты делегациясе Финляндиядә булганда, аларны гаҗәпкә калдырган, шаккатырган нәрсә — бу ил Президентының да, парламент һәм шәһәр башлыгының да хатын-кыз булуы түгел, ә парламент бусагасын узуга, постаментка куелган йөкле хатын-кыз сыны белән очрашу булган. Бу бик гадәти булмаган сынны кую сәбәбен сорагач, Финляндия хакимияте башындагы хатын-кызлар: «Милләт язмышын хәл итүче булганга», — дип җавап биргән. Финляндия дәүләте һәр гаилә алдына кимендә өч бала тәрбияләп үстерү һәм дәүләтнең чын гражданнары итеп тәрбияләү бурычы куйган, аналарга зур күләмдә пособие билгеләгән.

Заманында үзен какшамас держава итеп күрсәтергә омтылучы Россиядә гаилә мәсьәләләрен өйрәнү, хәл итү юнәлешендә әллә ничә институт, департаментлар оешкан иде. Социологлары дөньяда күпме рус хатын-кызы барлыгын исәпкә алып, белеп, рус гаиләләренә

Ләбибә Хөсәения (уңда) гаиләсе белән. Казан, 1910 нчы еллар

багышланган һәм тулы анализ биргән җыентыклар да чыгарып барды. Башка илләрдә, башка милләтләр арасында калганнарының хәлләре хакында, андый гаиләләрне саклап калу юллары хакында тулы фәнни хезмәтләр язылды. Бу эш хәзер дә дәвам итә: телевидение аша бара торган төрле-төрле тапшырулар шуны күрсәтә.

Татар хатын-кызлары алдында да шул ук мәсьәләләр тора, тик боларны чишү юлында алар ялгыз калган диярлек. Исебезгә төшерик әле: гаилә, бала тәрбияләү мәсьәләләре белән бүген Татарстаныбызда ничә галим, социолог шөгыльләнә, кайсы хаким кызыксына икән?

Милләтне саклаучы аналар бүген үзләре тәрбиягә мохтаҗ. Әниләр бала тәрбияләүгә әзер түгел, диясем килә. Бер генә йөкле хатын да баланың психологиясен, тәрбия алымнарын өйрәнеп бала тудыру йортына керми, аны моңа өйрәтүче юк. Баласын тудыргач та, меңнәрчә аналар көн саен кибеткә, базарга чыгып, арзанрак бәягә ниндидер азык эзләргә мәҗбүр. Тәрбия кайгысы менә мондый аналарда күпме кала икән дә, мөмкинлекләре ни дәрәҗәдә икән?

1998 елда Мәскәүдә төрки халыклар хатын-кызларының зур форумы уздырылган иде. Корылтайда рәислек итүче казакъ хатыны, юридик фәннәр докторы Раушан ханым Канапьянова катнашучыларга мөрәҗәгать итеп: «Беренче сүзне бу мәртәбәле форумда татар хатын-кызлары әйтсен. Алар безнең олуг укытучыларыбыз булдылар», — дигән. Шуңа да иң әүвәлге сүзне Татарстан

Фатыйха Аитова (уртада) һәм мөгаллимнәр укучы кызлар арасында. Казан, 1915 ел

хатын-кызларына биргәннәр. Форумда татар халкына, татар хатын-кызларына тугандаш халыкларның мәгърифәтен, мәдәниятен үстерүгә керткән өлешләре өчен рәхмәт сүзләре күп әйтелгән. Бүген йөрәкне әрнеткәне шул: заманында башка халыкларның телен, мәдәниятен, аңын үстерүгә ярдәм иткән татар кешесе, татар хатын-кызы ник бу кадәр таланды, түбәнлеккә төште соң? Нигә башка милләтләр эчендә эреп, югалып барабыз?

Нигә соң XX гасыр башында милләтнең күренекле зыялылары татар мәгарифенә, кыз балаларны тәрбияләүгә шулкадәр игътибарлы булып, бүгенге мәгариф системасында бу проблема бөтенләй бер кирәксез эшкә әйләнеп кала икән?

Искә төшерик әле. 1905 елгы инкыйлабтан соң татарлар яшәгән һәр өлкәдә, һәр авылда татар милли кызлар мәктәбе бер-бер артлы ачылып торган. Ул мәктәпләр өчен татар рухи тормышының барлык таләпләренә җавап бирерлек итеп программалар да төзелгән, дин һәм заман өчен кирәк булган дөньяви фәннәр дә укытыла башлаган. Ул чорда да татар милли югары уку йортлары булмау сәбәпле, милли кызлар мәктәпләре өчен укытучылар әзерләү максатыннан, төрле төбәкләрдә мөгаллимәләр курсы ачылган һәм аларда заман таләпләренә җавап бирерлек киң мәгълүматлы, тирән белемле мөгаллимнәр әзерләнгән. Шул чорның иң күренекле дин әһелләре, татар зыялылары һәм татар байлары бу эшне изге гамәлгә санап, үз өлешләрен керткән. Аларның эшчәнлеге матбугатта яктыртылып барылган.

Ни кызганыч, бүген безнең арада Рәмиевләр, Хөсәеновлар, Үтәмешевләр, Айтугановлар да, Ләбибә Хөсәения, Фатыйха Аитова, Гайния Яушевалар да юк. Кыз балалар тәрбиясенә хәләл көчен дә, хәләл малын да кызганмаган изге затлар болар.

Унбиш еллап үзгәртеп кору дәвере эшләргә теләгән кешегә җитәрлек, озак вакыт иде. Мөстәкыйль, милли мәгарифебезне булдыру өстендә дә

җитәрлек эшли алмадык. Күпме мәктәп төзелеп, кайсын чын татар, милли мәктәп иттек? Бик мактала торган татар гимназияләрендә дә искитәрлек хәл: татар балалары русча сөйләшә, фәннәр русча укытыла.

«Яшьләребезгә милли тәрбия бирүгә игътибар җитәрлек», — дип кайсыбыз әйтә ала? Ә женси тәрбия ник күздән төште икән? Ә бит нәкъ менә женси тәрбиянең нәтиҗәсе кешенең, җәмгыятьнең, милләтнең рухи һәм физик сәламәтлегенә бәйле булуын кем инкяр итә ала?

«Без Россия стандартлары белән укытабыз», — дип мактана кайбер татар педагоглары. Россия стандарты, Россия телевидениесе тәрбияләгән 11 яшьлек кыз балалар өчен бүгенге көндә Петербург шәһәрендә махсус бала тудыру йорты ачылган. Менә женси тәрбия булмауның нәтиҗәсе.

Кызлар белән малайларның, егет һәм кызларның үзара мөнәсәбәте саф, керсез булганда гына яшәү бәхете, гаилә бәхете туа ала. Моның өчен кыз һәм ир балаларны аерым укытырга, аерым тәрбия бирергә кирәк. Бу чорда аларның үзара аралашулары да мөмкин кадәр чикле, олылар күз алдында булуы мөһим.

XX гасыр башында Мисыр башкаласы Каһирә университетында кыз балаларның табигатенә һәм аларның тәрбиясенә багышланган «Хатын-кыз дөньясы» дигән курслар оештырылган булган икән. Татарның чын зыялысы, күренекле җәмәгать эшлеклесе Йосыф Акчураның, Каһирәгә баргач, ул лекцияләрне тыңларга йөрүе мәгълүм. Бүгенге хөрмәтле затларыбыздан кемнең дә булса мондый хәлләр белән кызыксынганы бармы икән? Юктыр.

Шушы ук чорда Төркиянең Истанбул университеты каршында «Аналар мәктәбе» эшләп килгән. Татар кызларыннан ул мәктәптә Казанның күренекле мулласы Салихҗан хәзрәт Галиев-Барудиның кызы Әминә туташ та укыган икән. Өйрәнәсе иде шушы мәшһүр уку йортларының программаларын. Төркиягә ел саен барып, төрле корылтайларда катнашып йөргән хатын-кызларыбыз ник бу программалар белән танышуны кирәк санамый икән?

Әйтәсе килгән тагын бер фикер. Элек тәрбия белән әби-бабайлар (гаиләсендәге балаларны гына түгел), халык арасында абруйлы, затлы кешеләр бик теләп шөгыльләнә иде. Хәзер мондый олуг затларыбызның тәрбиясе гаиләләрдә дә тараеп бара. Аларның үзләренә хөрмәт тәрбияләү дә гаилә эше генә булып калды.

Ә менә хөкүмәт башында утырган җитәкчеләребезнең хәләл җефетләре кыз балаларны тәрбияләү эшенә катнашса, ифрат нәтиҗәле килеп чыгуы мөмкин. Ялагайланудан саналмасын, мин әүвәлге Президентыбыз Минтимер Шәймиев хатыны Сәкинә ханымны үзен матур итеп, затлы, зыялы итеп күрсәтә алганы өчен чын күңелемнән хөрмәт итәм. Дәүләт Советы җитәкчесе Фәрит Мөхәммәтшин хатыны Луиза ханым да шундый хөрмәтле, зыялы ханымнардан. Алар яшьләр тәрбиясе мәсьәләләрендә үз сүзләрен әйтеп, берәр җәмәгать оешмасын җитәкләүне дә үз кулларына алган булсалар, нинди күркәм, күңелле эш булыр иде.

1917 елның 1 маенда Мәскәүдә Әсәдуллаев йортында ачылган Бөтенроссия мөселманнары корылтаендагы чыгышында күренекле шәхес, галим, мөдәррис мулла Хәсәнгата Габәши: «Безнең кызларыбыз бүлмәләргә бикләнеп түгел, тәрбия белән сафлансыннар иде», — ди. Бүген татарның кыз балалары бүлмәләрдән чыкты, иркенлек артты. Әмма саф тәрбия бирү хакында барыбыз да бергәләп тотынмасак, уйлашмасак, милләт дип сөйләүләребезнең кирәк булмавы да мөмкин. ■

Шәех Хәбибулла кыйссасы

Таҗеддин Ялчыгол

Килдек үзебезнең максатыбызга. Кыйссаларда шулай әйтелә ки, һиҗрәтнең мең дә йөзенче елында (ягъни 1689 елда) Бохара халкы, иман вә гыйбадәткә ялкау булып, бидгать (ярамаган) эшләргә чумдылар. Кыскасы, болар, тугыз ел начар вә бидгать эшләр артыннан йөреп, диннең асылларын югалтуга якынайганнар иде. Бохарада бер углан Ристан дигән базарда кавын, карбыз сатып йөри иде. Ул углан мондый бер фикердә икән: бу данлыклы Бохара шәһәре шулкадәр бозыклык һәм азгынлык белән тулган ки, әүлиялар әләме юкка чыкты. «Йа Рабби, зинһар, бу бәндәңне газиз әйләп, боларга әмре-мәгъруф (үгет-нәсыйхәт, вәгазь) итәрлек кадәрле гыйлем бирсәң», – диде. Хак Тәгалә хәзрәтенә зар-зар елады.

Кыскасы, бер чәршәмбе көнне Хуҗа Бәһаведдин[1] әүлияның каберен зиярәт итте. Анда да Хак Тәгалә хәзрәтенә күп догалар кылды. Моннан соң йокы басты. Йокыга китте. Төшендә бу сыйфатта Хуҗа Бәһаведдинне күрде: урта буйлы, күк (зәңгәр) күзле, кызыл сакаллы. Диде ки: «Әй бәгърем, син Сәмәркандка бар, анда бер сыер көтүчесе булыр. Минем мөридләремнән. Син аннан белем ал. Соңыннан килеп, бу Бохараны яхшы эшкә дәгъвәт ит (өндә)», – диде.

Шулай итеп, бу углан, йокысыннан уянып, шунда ук Сәмәркандка юнәлде. Беркөн Сәмәркандка барып җитте. Сыер көтүчесен күрде. Исеме Әндәрҗан Суфый иде. Мөридләре күп иде. Бу углан Хәбибулла һәм Әндәрҗан хәзрәтләренә чын ихластан мөрид булды. Күп вакыт анда аң-белем алды.

Кыскасы, Шәех Әндәрҗан көннәрдән беркөн әйтте: «Кайсыгыз Бохарага барып гыйлем өйрәтәсез? Ул Бохара халкы азгын булды. Әүлиялар әләме юкка чыкты». Мөридләр һичберсе җавап бирмәде һәм шуннан соң шәех хәзрәтләре Хәбибуллага карап әйтте: «Бохарага син бар. Аларны мөрид әйлә. Мин сиңа рөхсәт бирдем», – диде.

Бу Хәбибулла ул вакытта егерме яшендә иде. Хәбибулла әйтте: «Йә шәех, әйе, синең сүзеңнән чыгу – көферлектер. Ләкин сез бер мәҗлестә шулай дигән идегез: «Шәех булган кешегә дүрт нәрсә кирәк: беренчесе – зирәклек, икенчесе – сөйләм оста-

[1] Хуҗа Бәһаведдин — Мөхәммәд Нәкышбәнди (1314—1389) — Урта Азиядә яшәгән атаклы суфый.



лыгы, өченчесе – тиешле яшь, дүртенчесе – мал кирәк...» Ләкин боларның һичберсе дә миндә юк», – диде. Зирәк булмыйча, мөридләр тәрбияләп булмас. Сөйли белмичә, гыйльме заһирга[2] җавап биреп булмас. Өлкән яшь шуның өчен кирәк: бик яшь булса, халык аны түбәнсетер. Мал халыктан сорамас өчен кирәк.

Һәм шәех, бу сүзне ишеткәч, уйга чумды. Бер сәгатьтән соң торып җавап бирде: «Әй углан, бар, юлда һәрберсе сиңа хасыйл булыр (табарсың)», – диде. Шуннан соң бу Хәбибулла, Аллаһу Тәгаләгә тапшырып, хәзрәте шәехне күңеленә алып китте. Бохарага җиткәндә, Аллаһу Тәгалә аны кырык яшьлек кеше кыяфәтенә әйләндерде, илаһият гыйлеме һәм гыйльме кимийа (могҗиза кылу, химия белеме) бирде. Халыкка һич ихтыяҗы калмады. Бохарага килеп керде, бер иске кибеткә кереп утырды. Кешеләрдә ярамаган эшләр күрсә, тиешле эшләрне эшләргә өндәү вә тыелган эшләрдән тыю белән шөгыльләнде һәм шул.

Кибет янындагы балаларга сабак-дәрес бирде. Базардагы сәүдәгәрләрнең күбесе мөрид булды. Бу вакыйга һәм аның гыйлеме Бохарада мәшһүр була башлады.

Кыскасы, Бохараның ханы, үзенең галимнәрен ашка чакырып, пәйгамбәр хәдисләрен укыдылар, күп гыйбрәтләр алдылар. Галимнәр арасыннан берсе әйтте: «Йә падишаһ, гомерең озын булсын! Безнең Бохарага бер ялганчы килеп, үзен олуг шәех санап, мөридләрне тәрбияли икән. Инде син, тагын бер мәҗлес җыйганда, аны да чакыр, безне дә чакыр. Без аннан дингә ышану мәсьәләләрен, Хак Тәгаләнең берлеге турында сорарбыз. Әгәр аның дини мәсьәләләрдән хәбәре булмаса, шәһәрдән куарбыз», – диделәр. Шулай итеп, болар, киңәшеп, бу фикергә килделәр, шаһ мәҗлесеннән чыгып киттеләр.

Кыскасы, көннәрдән беркөн шаһ мәҗлес җыйды. Галимнәрне чакырды һәм дамелла Хәбибулланы да шунда чакыртты. Бу Хәбибулланың бер һинди ишәге бар иде. Аңа менде, падишаһ мәҗлесенә барды. Кереп, галимнәр арасына утырды. Хәл-әхвал сораштылар. Аннан соң галимнәрдән берәү әйтте: «Йә дамелла Хәбибулла, Ходаны ничек танырсың? Һәм ничә сыйфат белән белерсең?» – диде. Шунда ук Хәбибулла җавап бирде: «Әгәр Ходаның сыйфатын вә берлеген белми торган булсагыз, әйтегез. Әгәр имтихан өчен сорый икәнсез, монафикълык (икейөзлелек) уртасында сез», – дигәч, галимнәр тындылар, һичберсе каршы сүз әйтмәде. Аннан соң дамел-

[2] Гыйльме заһир — тышкы, дөнья турындагы тәгълимат. Батыйн — эчке; күренми торган. «Гыйльме заһир», «гыйльме батыйн» төшенчәләре, иң беренче чиратта, суфыйчылык белән бәйләнешле. Бу тәгълимат нигезендә дөньяны, тирә-юньне, кешене эчке тою, интуиция белән аңлап, танып-белеп була.

ла Хәбибулла әйтте: «Мин Коръәндә сурәи Йосыфны таба алмыйм», – диде. Шулчак, галимнәр арасыннан берсе әйтте: «Мин хәзер сурәи Йосыфтан сабак өйрәттем, мин табармын», – диде. Инша Аллаһ Тәгалә димичә, «Коръән Шәриф»не кулына алды, кәгазьләрне актарды, тапмады. Аннан соң тагын берсе алды. Ул да тапмады. Болар барысы да аптырап калдылар. Ахыр чиктә бу дамелла Хәбибулла Коръәнне кулына алды. «Бисмилләһир-рахманир-рахим» дип ачты, сурәи Йосыфны күрсәтте. Бу эштән таң-гаҗәп калдылар. Шәех Хәбибулла, аннан чыгып, үз эшенә китте. Падишаһ калган галимнәргә әйтте: «Сез бу галимне дошман күрмәгез, чөнки сезгә кәрамәт (могҗиза) күрсәтте. Сез белдегезме?» – диде. Барчалары гаҗәпкә калдылар, аптырадылар. Мәҗлестән чыгып киттеләр.

Кыскасы, көннәрдән беркөн шаһ тагын мәҗлес корды, галимнәрне чакырды. Барысы да килделәр. Шәех Хәбибулла да шунда иде. Баягы ишәгенә менеп килгән иде. Утырдылар. Тәгамне (ризыкны) галимнәр алдына китерделәр. Падишаһ әйтте: «Авыз итегез, ашагыз!» – диде, һичберсе кул сузмады. «Син әүвәл кул суз, син беренче кул суз!» – дип, бер-берсенә әйтеп, бер сәгать чамасы тордылар. Әмма шаһ боларны күреп әйтте: «Йә галимнәр, ни өчен ризыкка кул сузмыйсыз, тәгам хәләлдер», – диде. Моннан соң араларыннан бер мелла – Нияз Чукмакый исемлесе «әфәнде, бисмиллаһ», диеп тәгамга кул сузды. Аның артыннан барча галимнәр кул суздылар. Бу шәех Хәбибулла кул сузмады, тик торды. Падишаһ әйтте: «Йә дамелла Хәбибулла, ни өчен кул сузмыйсың?» – диде. Хәбибулла әйтте: «Тәгамең хәрамдыр, галимнәрең фасикъլардыр (бозыклардыр)», – диде. – Төн-көн хәрам ашап, күңелләреннән хикмәт нуры качкан», – диде. Галимнәр җавап биреп әйттеләр: «Безгә шәригать тыштан карарга кушты. Без бу шаһның ризыгында хәрам нәрсә күрмәдек. Син күрмичә, ничек хәрам дип фәтва бирәсең?» – дип галимнәр арасында гауга, җәнҗал күп булды.

Хәтта Шәех Хәбибулланы якалый башладылар. Шәех Хәбибулла әйтте: «Сабыр әйләгез, чөнки падишаһның, су алып, аш пешерә торган коесына бер кәнизәк (хезмәтче хатын) тавык үтереп ташлаган. Өч көн булды. Шаһның кырыслыгыннан куркып әйтми, – диде. – Тәҗрибә өчен шул коеның суын алып, минем ишәгемә китерсеннәр – эчмәс, – диде. – Әгәр гайре (башка) коедан алып китерсәгез, эчеп туймас», – диде. Аннан соң шулай иттеләр. Шул коедан алып китерделәр, ишәк алдына куйдылар. Пошкырып эчмәс булды, аягы белән суны тибеп түкте. Башка коедан китереп, ишәк алдына куйдылар, туйганчы эчте. Шәех Хәбибулла әйтте: «Минем ишәгем бу галимнәрдән галимрәк икән», – диде. Падишаһ һәм галимнәр барчалары хәйран калдылар. Моннан соң шаһы хәзрәт хезмәтче кыздан сорады: «Коега тавык үтереп ташладыңмы?» – дигәч, «Әйе, бардыр», – диде. Шуннан соң коедан тавыкны чыгардылар һәм шәех Хәбибулла могҗизасын таныдылар, чын әүлия дип мөридлеккә керделәр. Әүвәл шаһ керде, аннан соң барча галимнәр керделәр.

Бохарада никадәр бидгать (бозык) эшләр булса, барчасы тыелды, бетерелде. Бохара халкының төн-көн тәүфыйклары артты, күп кеше аңа иярделәр, шөһрәте илдән-илгә таралды.

Текстны басмага
***Хатыйп Миңнегулов** әзерләде.* ■

Болгар ислам академиясен төзи башлау тантанасында катнашучыларның КИЛӘЧӘК БУЫННАРГА МӨРӘҖӘГАТЕ

Бисмиллаһи-рахманир-рахим!

Әссәламегаләйкем вә рахмәтуллаһи вә бәрәкатүһү!

Бүген, 2016 елның 21 май көнендә (1437 һиҗри елның 14 нче шәгъбан көнендә), Идел буе Болгар дәүләте 922 елда ислам динен рәсми төстә кабул иткән истәлекле көндә, борынгы Болгар җирендә, алдынгы фән-белем һәм дин-мәгърифәт мөселман үзәге булачак Болгар ислам академиясе нигезенә беренче таш салына.

Россия мөселман руханиларының һәм Татарстан Республикасы җитәкчелегенең Болгар ислам академиясе төзү турындагы тәкъдимен Россия Федерациясе Президенты В.В.Путин хуплады, бу изге ният дин тотучыларның илнең рухи яңарышына омтылуын чагылдыра.

Дини җирлектә халыкара киеренкелек һәм конфликтлар көчәю шартларында ата-бабаларыбыз традицияләренә таянып, мөселман өммәтенең бердәмлеген, күпмилләтле һәм күпконфессияле илебездә тынычлыкны һәм татулыкны саклау, ата-бабаларыбыздан калган дини тәгълиматның бай мирасын торгызу бик мөһим.

Болгар иң төньяк мөселман дәүләте булып кына калмаган, ул күренекле галимнәрне һәрдаим үзенә тартып торган, андагы халыкара мәшһүр хәнәфи мәзһәбе алдынгы фикер һәм хокук үсеше белән дан казанган. Бирегә Багдадтан һәм Хәрәсәннән, ул чор мөселман фикеренең танылган үзәкләре булган илләрдән һәм шәһәрләрдән гыйлем эстәүчеләр килгән.

Габдрахман Утыз Имәни, Габденнасыйр Курсави, Каюм Насыйри, Шиһабетдин Мәрҗани, Галимҗан Баруди, Муса Бигиев, Исмәгыйль Гаспринский, Ризаэтдин Фәхретдин, Садри Максуди, Йосыф Акчура, Һади Атласи, Зәйнулла Рәсулев, Гаяз Исхакый кебек татар мәгърифәтчеләре һәм дин эшлеклеләре борынгы традицияләрне дәвам иткән.

Безнең дин белгечләребезнең хезмәтләре бөтен мөселман өммәтенең казанышы булып тора. Күпмилләтлелек, күпконфессиялелек, тормышның төрле рәвеше – болар барысы да хәнәфи мәзһәбе үсешендә уңай эз калдырган.

Болгар ислам академиясе, күренекле татар дин галимнәре нигез салган данлы традицияләрне лаеклы дәвам итеп, ислам мәдәнияте үсешенә зур өлеш кертсен өчен без бар көчебезне куярбыз. Аның уңай эшчәнлеге ислам диненең игелек һәм тынычлык, милләтара һәм динара мөнәсәбәтләрне җайлау дине дип кабул ителүенә ярдәм итәчәк, мөселман өммәтендә ватанпәрвәрлек һәм Ватанга мәхәббәт хисләре таратачак.

Без киләчәк буыннарга мөрәҗәгать итәбез – ата-бабалар мирасын кадерләп саклагыз, гуманлык, әхлак һәм мәгърифәт тантанасына юлны дәвам итегез.

Болгар ислам академиясе бердәмлек, игелек, тынычлык һәм татулык принципларын тотып, алдынгы бөтендөнья мөселман белем үзәкләре арасында лаеклы урын алыр дигән ихлас ышанычыбызга һәм изге омтылышыбызга Аллаһ Тәгаләдән фатиха сорыйбыз.

Беренче таш салу тантанасында катнаштылар:

Татарстан Республикасы Президенты **Р.Н.Миңнеханов,**

Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе **М.Ш.Шәймиев,**

Россия Федерациясенең үзәкләштерелгән мөселман дини оешмалары рәисләре,

Дәүләт органнары вәкилләре, руханилар, эшмәкәрлек бергәлекләре, фән һәм җәмәгатьчелек, якын һәм ерак чит илләр вәкилләре.

Әсәр филология фәннәре докторы, профессор РИФКАТЬ ӘХМӘТҖАНОВның шигъри тәрҗемәсендә бирелә.

КУТАДГУ БИЛИК

(Котайткыч белем)

Йосыф Баласагуни
(Йосыф Хасс-Хаҗиб)

Илаһ әйтеп биргән олуглык юлын
Һәм төрле гөнаһтан кисәткән колын.

Кирәк иде колга үзе коллыгын
Төгәл үтәп Хакка тугры булуың.

Һәм тәуфыйклы булса Алланың колы,
Һәр изгелеккә дә ачыла юлы.

Димәк ки, гыйбадәт кылынган чакта
Һәрбер изгелеккә ачыла капка.

Менә шулар инде минем белмешем,
Сиңа сөйләгәнем, и, изге кешем.

Сезгә миннән бары фатиха кирәк,
Үземнән дә бигрәк, сүземдер – терәк.

Ахирәт теләсәң, сүзем менә шул,
Дөньяны теләсәң — үзең беләсең.

Дөнья яши биргән — килә биргән кот,
Булыр теләгәнең — гамәл кыл һәм көт.

Миннән соң ни файда, догадан үзгә,
Догам кабул булса, и, туган, сезгә.

Куя бирсен илбик мине үземә,
Догачы булыйм мин аңар — изгегә.

Гыйлем кирәк булса, белгәннәремне
Әйттем, аңар сөйләп бир инде.

Минемчә эш итең, сүз тыңласагыз.
Җәрен үкенерсез, ышанмасагыз,

Ни шәп әйткән берәү — гыйлеме диңгез
(Бу сүзне тотсагыз балкыр йөзегез):

«Бүген сезгә сүзем төш кебек кенә,
Җәрен алар туш һәм юш булып килә.
Гафил булма, тырыш, сүзләремне тот,
Әгәр тотмасагыз, гуя, булыр йот».

Гозеремне генә сора илбиктән,
Чарасын тап инде шунда ничек тә,

Ары-бире итеп күп михнәт күрдең,
Ходай бирсен кояш кебек әҗерен.

Сүзләремне, кардәш, авырга алма,
Якынлык хисләрен читкә ташлама.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавапта Үгделмеш тибрәтте телен:
— Мин инде аңладым тугрылык юлын.

Ишеттем сүзеңне һәм үгетеңне,
Кару сүзем юк һәм хуплыйм сүзеңне.

Әйттең дөрес сүзләр, хакыйкать шул ул,
Әйткәнеңнән үзгә бары — кәкре юл.

Синең сүзең – чыннан, минеке — уен,
Уен бетте, чынга сонам буй-муен.

**Дөнья яши биргән — килә биргән кот,
Булыр теләгәнең — гамәл кыл һәм көт.**

* Дәвамы. 2013 елның 10 нчы санынннан басылып килә.

Китим инде, кардәш, сау һәм исән кал,
Һәр ике дөньяда сиңа иге фал.

Ходай тәүфыйк бирсен, көч бирсен, туган,
Догадан калдырма, үпкәчел булма.

Ходайдан сорый бир шуны ки, мине
Гөнаһтан сакласын, ак булсын күңлем.

Сүзен кисте, купты һәм үрә торды,
Саубуллашты, өйгә таба йөз борды.

Атын менде, кайта өенә килеп,
Төште аттан, керде, тынып-шым булып.

Ашап-эчте, озын хыялга батты,
Ишеткән сүзләрен уйда кайнатты.

Кара чадра киде йөзенә кояш,
Җиргә кара бөркәү капланды тоташ.

Руми кыз төшерде җиргә толымын —
Кара чәч төсе бар дөньяга тулды.

Зәңги йөзе кебек күк кучкыл булды,
Учар[1] тынды, кеше йөрү шил булды.

Һәм Үгделмеш тынды, ясту[2] укыды,
Түшәк сорап ятты, уйда оеды.

**Ходай тәүфыйк бирсен, көч бирсен, туган,
Догадан калдырма, үпкәчел булма.**

Бераз йоклап алды, тагын уянды,
Караса — авышкан ал Бакыр йолдыз[3].

Өлкәрнең бер чите дә бераз ауган.
Шәрыктә югары үрмәли Чаян[4].

Янә ятты, ләкин йокы алмады,
Кизү[5] кеше кебек күзен йоммады.

Йокысыз ятты ул бераз берүзе,
Гади ак төсенә керде күк йөзе.

Гамбәр җәелгәндәй күк томанланды,
Күк читендә мәрҗән нурланып янды.

Көн астан күтәрде байрагын, тотып,
Моны күреп, җирдә җанланыш купты.

---

[1] Учар — базар мәйданы, бүтәнчә урам чаты (татар сөйләшләрендә дә очрый).
[2] Ясту — кичке (ахшамнан соң укыла торган) намаз.
[3] Бакыр йолдыз — Марс.
[4] Өлкәр — Иләк йолдызлыгы, Чаян – йолдызлык атамасы.
[5] Кизү — дежур, часовой.

Корулыдыр һәрчак заман җәясе,
Тия кайчак зыян, кайчак — файдасы.

Торып юынды, күр, безнең Үгделмеш,
Намазын укыды белгәнчә бериш.

Җир читендә алтын калкан күренде,
Үгделмеш тә Сарай алдына килде.

Ишетте илбик һәм шундук чакырды.
Бу керде, кулларын кушырып торды.

Илбик утырырга аңа ымлады
Һәм Үгделмеш түрдә бер урын алды.

Бераз тынып торгач, сүз кушты илбик:
— Ни хәбәр бар, сөйлә, и, дустым-иплем.

Кардәшең ни сөйли, нәтиҗә нинди,
Синең теләгеңчә, киләме инде?

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Җавап биреп, сөйләп бирде Үгделмеш,
Нинди сүзләр булган, барсын дөп-дөрес.

Үзара икәүләп сөйләшкәннәрне
Илбиккә барчасын да хәбәрләде:

Тынып торды илбик хыялга батып,
Күңеле йомшарып яшьләре акты.

Һәм әйтте: – Кардәшең сөйли дөресен,
Ул сөйләгән сиңа нәкъ туп-турысын.

Без үз-үзебезне генә көчлибез
Һәм аңарга тагы, гүя, үчлебез.

Мәңге түгел дөнья, үтә гомерләр
Һәм билгесез безгә багышлы көннәр.

Киләчәк, һичшиксез, тәмуг йә оҗмах,
Рәхәт-михнәт монда сузылмас озак.

Мәңгелек нигъмәткә ирешсәк иде.
Изге затның барыр урыны – изге.

Кардәшең уянган кешедер рухан.
Аны чакыру да хәзер бик мөхаль.

Без үзебез инде һәвәскә тоткын.
Зая үтте ничә еллар, көн-бә-көн.

Ни ди, инде ишет, ул күңле тере,
Сиңа яхшы сөйләп нәсыйхәт бирер.

Һәвәс, нәфес-дошман әгәр алса көч,
Бу икәү үзеңдә һәм үзеңә үч.

Бу икәү көчәйсә — жаныңа үлем,
Җаның үлсә, тагать онтыла, углым.

Безнең күңел күптән әсиргә калган
Һәвәс, нәфес үскән, көчәйгән яман.

Олуглык, бөеклек, хакимлек чоры
Озакка бармас ул, и, күңле тугры.

Рәхәте күп түгел, күптер җәфасы,
Баш катыру, каргыш-сүгешләр, ярсу.

Ни шәп әйткән бер бик белемле кеше
(Дөньяны сынаган, акылы пеше):

«Олуглыклар белән бер дә мавыкма,
Олуг булдың исә башың авырта.

Сөенече кайда — казасы шунда,
Рәхәт белән бергә мең имгәк туа».

ИЛБИКНЕҢ ҮГДЕЛМЕШКӘ СОРАВЫ

Янә әйтте илбик: — И, Үгделмешем,
Тагын шуны синнән сорап белешим.

Әгәр мин аныңча изгелек итсәм,
Үлгән җаным — күңлем терелер микән?

Карышты, өнәми монда килергә,
Дус-иш кардәшләрнең йөзен күрергә.

Ул әйткән сүзләрнең барчасы дөрес
Һәм аны көчләүдән чыкмастыр бер эш.

Мәшәкатьләндең син арада йөреп,
Телеңне талдырып, арып, йөгереп.

Көтик, күрик тагын, и күңле юмарт,
Хәл үзгәреп безгә чыгармы форсат?

Кайчагында хәлләр, гүя, кара төн
Һәм кинәт яктырта бер эш, каньатым[6].

Корулыдыр һәрчак заман җәясе,
Тия кайчак зыян, кайчак — файдасы.

Аллага тапшыр, дус, барча эшләрне,
Көт, вакыты җитәр, бар да эшләнер.

Эш эшләнеп беткәч, булыр шатлыгы,
Үз җаена куйыйк хәлне, акыллым.

Бу дөнья кануны шул: кусаң, кача,
Үзе юл ача ул, барсаң уртача.

Күзәтик берара, карыйк әхвәлне,
Ничек итеп вакыт чишәр бу хәлне.

Аның үзе безне теләве мөмкин,
Уйлар да бераз, дин төзәтер холкын.

Шулай диде илбик һәм сүзен кисте,
Үгделмеш хушлашты һәм чыгып китте.

Бу сүздән соң шактый көн үтә бирде,
Илбик уйланып бер чыкты, бер керде.

КӨНТУГДЫ ИЛБИКНЕҢ ҮГДЕЛМЕШНЕ ӨЧЕНЧЕ ТАПКЫР ӨНДӘРГӘ ҖИБӘРҮЕ

Чакырды илбик бер көн Үгделмешне,
Әйтте: — Сиңа йөклим тагын бер эшне.

Чакырдым — килмәде кардәшең миңа,
Теләгем үтәлми, борчылам шуңа.

Мин инде «нәкъ шулай булсынчы», димим,
Теләгем үзәге бүтәнчә инде.

Бүгенге теләгем бары шул гына:
Йөзен күрим — торсын минем алдымда.

> **Бу дөнья кануны шул: кусаң, кача,**
> **Үзе юл ача ул, барсаң уртача.**

Аңар мин барыйммы, үзе килсенме —
Күрешү-зыяфәт кенә булсын бер.

Мине күреп, бирсен тик нәсыйхәтен,
Китсен, үз шөгылен сөйсә шулхәтле.

Миңа тия файда, аңар зыян юк,
Сөзелсен үземнән барча болганык.

ҮГДЕЛМЕШНЕҢ ҖАВАБЫ

Һәм Үгделмеш әйтте: — И, котлы дустым,
Сүзең дөрес кебек, хуш, шулай булсын.

Теләсәгез, илбик, килер ул монда,
Үтенеп чакырыйм әле тагын да.

Барыйм, сөйләп карыйм сүзеңнең серен,
Барып йөрмәс илбик, үзем китерим.

Рәхим итеп илбик язсын хат кына,
Укысын, ышанып килсен каршыңа.

Илбик әйтте: — Нигә бер хат кабаттан?
Син ышанычлырак һәрнинди хаттан.

Илче ышанычсыз булса, хат кирәк,
Сиңа мин ышанам үземнән бигрәк.

Ни ди, яхшы ишет, ягмалар[7] бие
(Һәр әхвәлләргә дә җитешкән ие):

«Яхшы ялавачка бетек ник кирәк?
Якты янган утка төтен ник кирәк?
Сүзеңне телдән әйт, авыздан ишет,
Тагын бер бетек, и, егет, ник кирәк?»

Ә бу бигрәк кыен, авыр эш түгел,
Һәм аннан кыеклау да тиеш түгел.

Дәвамы бар ■

[6] Каньатым (каниатым) — хәрби дустым, күчерелмә мәгънәдә «иң якын дустым» (мишәрләр сөйләшендә).
[7] Ягма – борынгы төрки кабилә.

Шагыйрә Газизә Бәһаветдин кызы Сәмидова

Җәвад Алмаз

Кульъязмаларның шул чорга караган бер битендә:

«Һәркемнең бәгъре гыйшыктан башлау... баш-яра, башлу-яралы, күзе йашлау (яшьле), йөрәге атәшлүдер (утлы)» – дигән чәчмә юл бар. Газизә моны ниндидер бик борынгы әсәрдән күчереп алган. Ләкин ул Газизәнең мәхәббәткә карашын ачык чагылдыра һәм мәгънә ягыннан А.Пушкинның «Мәхәббәткә һәркем буйсына: яше дә, карты да», дигән сүзләренә тиң килә.

Ләкин язмыш Газизәгә елмаймый. Иреннән аерылганда ул инде 32 яшендә һәм 5 баланың (өчесе үлә) анасы була. Гомере аны яшьлектән картлыкка таба якынлаштыра бара. Көннәр һаман үтә дә үтә... Максатына тулысынча ирешә алмавы исә Газизәнең йөрәгендәге төзәлеп бетмәгән тирән яраларны тагын ача:

Яшдин йөрәгемне яндырдың,
Ахры ят кулыңда калдырдың!
Бәнем аткынаем күк ала,
Кече яшьләреңдән сәвешсә дә,
Бәхетсезләр кауышмый кала...

...Газизәнең бу чордагы җырлары шигырьләренә бернәрсә характерлы: шагыйрә элекке кебек Аллага сыгыну, аңа ялынып-ялварып «мәдәт (ярдәм)» сораудан туктый. Ул үз бәхетсезлегенең сәбәбен эзли башлый һәм аны башта ата-анасыннан күрә:

Әнкәй, мине ник таптың?
Әтием, ник асрадың?
Үсеп буем җитәр-җитмәс,
Ят кулына ник саттың?

...Әйе, яшьлек үткән. Аны кайтарып та, кабатлап та булмый. Тик бернәрсә аяныч – гомер зая үткән. Ләкин Газизә моңа да чыдарга, җыламаска тырыша:

Түзәмен авыр булса да,
Җыламыймын күңелем тулса да... –

дип тәмамлый ул бу темага башланган бер шигырен.

Ахыры. Башы журналның 3 нче санында.

Татарстан язучылары Газизә Сәмидова кабере янында. Әстерхан өлкәсе, Ташлыяр авылы. 1992 ел

Россиядәге феодализмның коллык богаулары өзелеп, капитализм башланган чорда дөньяга килгән Газизә аның үскәнен, күтәрелгәнен, ниһаять, 1917 елда егылганын күрә. Октябрьда көчле җиңү маршы белән капитализм урынын алган социализмны да аңлый алмый, алардан читтә кала. Гомеренең бушка үтүенә әрнү Газизә шигырьләрендә элеккечә төп урын ала:

Аһ дәрига! Гомерем зая
үтте-китте.
Уйласам да, еласам да файда итми.
Узган гомер миңа тагәт
кылмас инде.
Ялнып, кил, дип чакырсам да,
килмәс кире...

Моннан соңгы шигырьләрендә ул оныкларына, бер-берләре белән яхшы яшәргә, ярдәмле булырга өндәп, васыятьләр яза. Кайбер шигырьләрендә якынлашып килә торган үлем куркынычы турында кайгыру чагылып китә:

Ничә китапларның арасында
Сәвеп укыганым «Бакырган».
Дөньядан китәм, дип хәсрәтләнеп,
Чыгып барам камил авылдан.

Шул ук вакытта якты дөньяда яшәргә теләү хисе шагыйрәдә никадәр көчле булганын күрсәтә бу юллар.

Алмагачлар тулы алмалы,
Ничек ботаклары талмады?
Фани дөнья безне алдады,
Башта акыллар да калмады, –

дип зарланса да, шагыйрәнең камил акылы, соңрак булса да, күп нәрсәләрне аңлый башлый. Тормыш тәҗрибәсе арткан саен Газизә акрынлап үз бәхетсезлегенең чын сәбәбе – кешеләр аңын богаулап яткан искелек калдыклары һәм алар исеме белән эш йөртүчеләр икәнен төшенә бара...

Шуңа карамастан, шагыйрә аңындагы үзгәреш яңа адым ясый алмый. Иске тормыш яшәү хисе белән ян-

ган шагыйрәнең канатларын төзәлмәслек сындырган була. Шуңа күрә Октябрьдән соңгы шартларда ул инде кабат яза алмый. Газаплы тормыш аны хәлдән тайдырган була, өстәвенә, картлык та баса:

Алтмыш алты еллар гомер иттем,
Бәнем аякларым талды инде.
Михнәт күреп, рәхәтне күрмәгәч,
Бәнем хәтерләрем калды инде, –

дип, шагыйрә бөтен нәрсәдән хәтере калган килеш, искелек корбаны буларак, дөньядан үтә.

Югарыда китерелгән юллар 1927 елда язылган. Кульязмада моннан соңгы шигырьләрнең кайчан язылганын аныклап булмый. Газизәнең үлгән елы да хәзергәчә төгәл билгеле түгел. Болар әле киләчәк эше.

ГАЗИЗӘ ШИГЫРЬЛӘРЕНЕҢ ЧЫГАНАГЫ

Газизә шигырьләренең ике чыганагы бар. Беренчесе халык җырлары. Газизә алардан бик үзенчәлекле файдалана. Шигырьнең беренче юлын яки беренче ике юлын ул халык җырларыннан ала. Куплеттагы аңа рифмадаш булып килә торган соңгы юллар Газизәнең үз сүзләре белән бирелә. Ләкин Газизә халык җырларыннан рифмадаш юллар гына эзләми, бәлки үзе әйткән фикергә мәгънәдәш юлларны сайлап ала.

Мәсәлән, халык җырларыннан алынган:

«Кара урманнарда кар тирән,
Атлап булмыйдыр ат белән...» –

дигән юллар

«Ничек кенә көлеп сүләсәң дә,
Серләр килешмидер ят белән», –

икелегенә рифмадаш кына түгел, мәгънәдәш тә. Шагыйрә бу икелекләрдә тирән карда ат белән барып булмаган кебек, яратмаган кеше белән дә тормыш көтеп булмый, дип табигать факты белән җәмгыять фактын уңышлы чагыштыра. Газизә бу поэтик чараны бик еш куллана. «Яшдин йөрәгемне яндырдың», дип башланган шигырьдә бу чара ике урында кулланыла.

Газизә шигырьләренең күпчелеге *а-а* формасында рифмалаша. Икенче юл белән дүртенче юл яки беренче, икенче һәм дүртенче юллар рифмалашуы да очрый. Шигырьләр гадәттә икелек белән бетә. Бу икелектә исә шигырьдәге фикернең бөтен каймагы бирелә...

...Газизә үз шигырьләрен бастырыр өчен язмаган. Ул ахирәт дуслары белән үзенең шигырь дәфтәренә генә ышанган һәм башкалардан яшереп саклаган. Алар эчендә ике вариантта язылганнары яки төзәтелгәннәре бөтенләй очрамый. Шагыйрә үз шигырьләренең теле турында да, үлчәве, рифмалары турында да гүя уйлап тормый, алар ничектер, үз-үзеннән калыплашалар шикелле. Шагыйрәнең бөтен игътибары шигырьнең эчтәлегенә юнәлә. Йөрәктәге хис исә шигырьнең формасы турында уйларга һичнинди көч түкминитми, үзлегеннән кәгазь битенә түгелә. Шуңа күрә бу шигырьләр табигать ничек яраткан булса, шул килеш алынып, җепкә тезелгән асылташларга охшый.

Борыла-борыла очар карлыгач,
Кайда кунар икән арыгач?
Сез, туганнарымны сагынгач,
Бал-май ашасам да, карыным ач.

Бары-югы дүрт юлдан торган бу шигырь үзенең гадилеге, фикернең ачык һәм төгәллеге, уңышлы рифмаларының табигыйлеге белән югарыда әйтелгән фикергә мисал була ала.

Революциягә кадәр булган хатын-

кызларның авыр язмышы – Газизә шигырьләренең төп темасы. Ләкин аның башка темага язган шигырьләре дә бар. Мәсәлән, «Гыйлемнең кирәклеге» дигән шигырендә ул яшьләрне белем алырга, бер минут вакытны да бушка җибәрмәскә өнди...

Газизә бәетләр дә яза. Яратмаган кешесенә бармас өчен туй көнне Иделгә ташланып үлгән бичара Хәбибҗамал бәете Газизәнең үз хәленә дә аваздаш. Шуңа күрә ул бәет аеруча көчле хис белән язылган. Бәетнең соңгы юлы Хәбибҗамалның ата-аналарына: «Аның кече сеңлесен сәүгәненә бирегез», дигән киңәш белән бетә.

Икенче бәеттә утыз кеше белән бергә Себер җибәрелгән 18 яшьлек кыз Вәзыйфа тасвирлана. Вәзыйфа бәете 1870 елгы вакыйгага багышланган, ләкин язылуы соңрак булырга тиеш.

«Касымский Ибрай» бәете аерата дикъкатьне үзенә җәлеп итә. Аның хәзергә кадәр кем язганы билгеле түгел. Газизә кулъязмасындагы текст басмадагылардан күп аерылмый. Ләкин Газизә бу бәетнең башына үзенең башка шигырьләрендәге кебек аңа гына хас икелек язып куя:

Бай бай булып гомер иткән,
Күп эчеп, исереп, бөлеп беткән...

Бу икелек «Касыймский Ибрай» бәетенең авторы Газизә булырга кирәк, дигән фикерне тудыра. Бәетнең кулъязмалар эчендә булуы очраклы түгелдер, әлбәттә.

Газизә кулъязмаларында кайбер мәкальләрне дә теркәп бара. Мәсәлән: «Ялган оят китерер, дөреслек куәт китерер»; «Әйткән – юлда, биргән – кулда»; «Киңәшле эш – пешкән аш»; «Хәлле хәленчә булыр»; «Дустың бирсә ком, аны да учыңа йом»; «Ни нәрсәне карар, ул нәрсә аңа ярар»; «Авыздан чыккан сүз, һавага җәелә түз»; «Ат булганчы, тайга менә тор»; «Күңел алгана да бер сүз, күңел калган да бер сүз»; «Яхшы дусыңа барма, яман йортыңа бар» һ.б.

Болар эчендә «һавага җәелә түз», дип беткән мәкаль аерата кыйммәтле. Анда *тузан* сүзе урынына *туз* формасы кулланылган. Бу бик борынгы форма һәм ул Кыйссаи Йосыф дастанында бары бер генә җирдә очрый. Һәм аның татар мәкалендә сакланып калуы – бу дастанның борынгы татар телендә язылганын күрсәтүче дәлилләрдән берсе.

Газизә шигырьләренең икенче чыганагы – борынгы татар язма әдәбияты. Газизә аны бик яхшы белгән.

Газизә татар милли әдәби теленең формалашкан чорында яза башлый. Шуңа күрә ул бу чорның рухы һәм таләбе белән, бер яктан, җанлы халык теле – халык иҗатына таянса, икенче яктан, татар әдәбиятының бик борынгыдан килә торган әдәби тел традицияләренә нигезләнә...

Татар поэзиясе тарихында Кандалыйдан Тукайгача булган дәвер буш иде. Газизә шигырьләре әнә шул буш урынны тутыра һәм борынгы төрки әдәби телдән милли әдәби телгә күчү процессын бик ачык чагылдыра. Шуның белән бергә татар әдәби тел тарихында әлегәчә бәхәсле булган күп кенә фәнни мәсьәләләрне чишәргә мөмкинлек бирә.

Сүз ахырында шагыйрәнең мирасы саклануга сәбәп булган Ленинградлы иптәшләргә рәхмәт белдерәсе, безнең үзебездә дә (ягъни Татарстанда) кабатлануы мөмкин булмый торган мәдәни байлыгыбыз – борынгы кулъязмаларны җыю һәм аларны саклау чаралары күрелсен иде, диясе килә. ■

ҮТЕРҮЧЕ

З.Ишаев

(Хикәя)

Ярминкә башланды. Купеслар товарларын урынлаштырып, кибетләр ачтылар.

Ярминкәдә халыкның очы-кырые да юк. Күбесе авыл халкы. Ягъкубның шулкадәр күп халыкка исе китсә дә, үз эшен дә онытмады. Ул һәммәсен дә җентекләп күзли, кем товар алырга килә, кем болай гына товарның яхшылыгын карарга, кем усал ният белән йөри? Барысын да кичерә иде. Әгәр килүчеләрдән берәрсе шөбһәле күренсә, андый-мондый нәрсә эләктерерлек булса, андыйларны куып җибәрә иде. Каюм исә бернәрсә тугрысында да кайгырмый һәм аның кайгырырга вакыты да юк иде. Һәрвакыт, кибеттә халык күп булды исә, әллә кайдан чегәннәр килеп чыгалар да, Каюм янына баралар. Каюм алар белән читкә борылып, әллә нәрсә тугрысында пышылдап сөйли иде. Ягъкуб кайчагында Каюмнан: «Алар нинди кешеләр? Ни өчен киләләр?» – диеп сораштыргалый. Каюм җавап урынына йөзен чытып, ачулы тавыш белән: «Нигә син алай кешене күзлисең, үз эшеңне бел! Мин бит сине күзләмим, син дә миңа кагылма! Алар бар да минем танышларым, алар белән бер шәһәрдә эшләгән идем», – ди иде. Ягъкуб аңа каршы: «Аларга тагы эшләргә? Күрмисеңмени, алар бар да сәләмә... Аларга карарга да чирканыч!» – ди торган иде.

Бервакыт кибет янына бер чегән хатыны килде һәм үтеп барган булып Каюмга баш селкеде. Каюм аның янына барып, нәрсә хакындадыр акрын гына сөйләшергә башлады. Ягъкуб бу эшләрнең барысын күрде һәм аның йөрәге нindидер бер усал эш барлыгын сизеп алды. Чегән хатыны киткәч, Каюм Ягъкуб янына килеп:

– Эх, иптәш! Син ач һәм ялангач! Шулай була торып та үзеңә үзең ярдәм итә белмисең! Син үз башыңа бәла булып кына йөрисең! Син хуҗа вәгъдә иткәнгә ышанма, ихтимал, бернәрсә дә ала алмассың.

Ягъкуб:

– Соң ничек артык эшләмәкче буласың? Эш бит авыр түгел, ә хак яхшы? Шуннан артык бернәрсә дә юк бит инде?

Каюм:

– Бар!..

Ягъкуб:

– Нәрсә? Әйт!

Каюм:

– Сиңа ышансаң!.. Дөрестен генә әйт әле Ягъкуб! Син хуҗага тугры хезмәт итәсеңме?

Ягъкуб:

– Тугры булмагач, ул нинди хезмәт? Ялландың – сатылдың. Миңа хуҗаның бер тузаны да кирәк түгел. Мин әгәр үз туганымның да хуҗа малына хыянәт иткәнен күрсәм, аны да әйтер идем.

Каюм:

– Рәхмәт сиңа, Ягъкуб! Һәрвакыт шулай кирәк: баерсың.

Шул сүзләрне әйткәч, Каюм Ягъкуб яныннан китте һәм үзе авыз эченнән генә көлеп куйды. Ягъкуб аның көлгәнен күреп: «Бу Каюмда ни булса да бернәрсә бар. Ул хәзер авылдагыча түгел, үзгәргән», – диде. Ягъкуб шул

Ахыры. Башы журналның 5 санында.

З.Ишаев. Үтерүче. Хикәя (русчадан үзгәртелде). Нашире: Г.Гобәйдулла. – Казань: Электро-Тип. «МААРИФЪ», 1914. – 36 б.

хакта тирән уйга батты. Бу вакыт чегән хатыны тагы килде. Каюм аның янына барып: «Тиле! Аңа сөйләп торуы да әрәм. Аңардан башка да эшне булдыра алырмыз», – диде. Ягъкуб бу сүзләрнең барысын да ишетте.

***

Кояш баеп караңгы төшә башлады. Приказчиклар да кибетләрне ябып, төрлесе төрле җиргә: кайсы театрга, кайсы мунчага, кайсы кая җитте, шунда тарала башладылар.

Ягъкубның хуҗасы да, гадәте буенча, Каюмга кибетне бикләргә һәм ачкычны бирергә кушты. Каюм йозакны божраларга элеп уңга борды, сулга борды, көче җитмәгән булып көчәнде, ыңгырашты, ахырысында йозакларны бикләп, ачкычларын хуҗага тоттырды. Хуҗа кайтып китте. Аның артыннан Каюм да каядыр китте. Каюм киткәч тә, Ягъкуб йозакларны яңадан барып карады. Ни күрсен: йозаклар бикләнмәгән, һәммәсе дә ачык, бары эленеп кенә торалар. Каюм шулкадәр тырышып, ыңгырашып бикләгән булып маташса да, бары хуҗаны алдар өчен генә эшләгән икән.

Ягъкуб йозакларны карап бу тугрыда бер фикергә килергә өлгермәде, ул арада Каюм да каяндыр килеп чыгып:

– Бар, иптәш, фатирга! Миңа аш китер! Аннан соң йокларга ятарсың. Йә болай итик: анда фатирда эссе, мин анда йоклый алмыйм, син үз чиратыңа килмә, синең өчен мин каравылларымын, – диде.

Ягъкуб шундук: «Менә ул ничек икән! Тукта әле!..» – диеп уйлады да, фатирга таба китте һәм Каюмның күзеннән күмелгәч тә бар көче белән чаба башлады. Тиз арада хуҗасының фатирына килде. Бәхеткә каршы, хуҗа өйдә иде. Ягъкуб бар белгәнен, Каюмның ничек әзерләгәнен, аның әллә нинди шөбһәле кешеләр белән сөйләшкәнен, аның ничек йозакларны бикләгәнен, ахырысында аны өйгә кайтарып җибәргәнен, һәммәсен берәм-берәм сөйләде. Мондый сүзләрне ишетеп, хуҗа ап-ак булды. Бераз башына килгәч, Ягъкубка тугрылыгы, саф күңеллелеге өчен рәхмәт укып, ачкычларны алды да, ямщик яллап, кибеткә чапты. Кибеткә килеп йозакларны карады, берсе дә бикләнмәгән. Каюмны чакыра башлады. Ләкин Каюмның эзе дә күренми, ул инде әллә кайчан иптәшләре янына сызган иде. Хуҗа кибетләрне ачып эчкә керде. Товарның барысы да төгәл, сәламәт икәнен күреп, Ходага мең-мең шөкер кылды, күрәсең, угрылар әле товарны алып өлгермәгәннәр, җайлырак вакыт, төн җиткәнен көткәннәр.

Хәзер инде хуҗа кибетне үз кулы белән бикләп, аның өстенә ике каравылчы яллап куйды. Ягъкубны исә, шундый хезмәте өчен тәмам олуглап, аңа рәхмәтләр укып: «Бу көннән алып сиңа көненә илле тиен урынына берәр сум бирермен. Киткәндә тагы наград бирермен. Моннан соң да шулай кара, аз гына берәр шөбһәле нәрсә сиздең исә хәзер миңа хәбәр бир! Инде син кибет янында торма. Теге усал Каюм эшне сизсә, сине тере калдырмас», – диде.

***

Икенче көнне «ярминкәдә өч кибетне берьюлы талаганнар», дигән хәбәр таралды. Хуҗа бу хәбәрне ишеткәч һәм ул таланган кибетләрнең үз кибете белән янәшә кибетләр икәнен белгәч, Ягъкубны нишләтергә белмәде. «Минем дә кибетем шулай таланган булыр иде бит. Бу таланган кибетләрдән гәрчә күп мал алсалар да, аның суммасы күп түгел, ә минем кибеттән аз гына мал алсалар да, ун меңләпне эләктергән булырлар иде», – диеп, Ягъкубка күп рәхмәтләр укыды.

Бервакыт Ягъкуб кибет алдында утырып тора иде. Шулвакыт кибет янында ристаннарны алып китеп баралар, аларның алдында да, артларында да мылтыклы һәм кылычларын ялангач тоткан солдатлар каравыллап баралар

иде. Ягъкуб ристаннар арасында Каюмны да күреп, аны ифрат кызганды. Аның янына йөгереп барды да, кесәсеннән күпме булса да акча алып бирде. Каюм ачулы күзе белән Ягъкубка карады. Аның төсе тәмам үзгәргән, күзләре уттай яна иде. Ул акчаларны кире Ягъкубка ыргытып бәрде дә: «Синең минем бу хәлдә икәнемне күргәнче, җир астына кергәнең артыграк булыр иде», – диеп, алга таба китте.

Ягъкуб кич үзенең Каюмны күргәнлеген хуҗасына сөйләде.

Хуҗа:

– Кибетне талаган угрыларның һәммәсен дә тотканнар. Шулар эченә безнең Каюм да эләккән. Аның минем кибетне таларга әзерләнгәнен сөйлиләр дә, ул барсыннан да баш тарта, икърар итәргә теләми икән.

Ярминкәләр бетте, хуҗа хезмәткәрләрнең һәммәсен дә хисап биреп җибәрде. Ягъкубка көненә берәр сум жалуниядан башка йөз сум наград биреп: «Ал, энем Ягъкуб. Мин сиңа мәңге бурычлымын. Син минем ничә мең сумны коткардың. Рәхмәт инде сиңа!» – диеп, кайтарып җибәрде.

Ягъкуб ифрат шатланды. Шатланмаслык та түгел шул! Ул бит хәзер өенә бер капчык акча алып кайта. Андый сумманы ул төшендә дә күргәне юк иде. Алтын акчалар биргәнгә хуҗага рәхмәтләр укыды, чөнки алтынны берәүгә дә сизмәслек итеп яшерергә мөмкин. Юл ерак бит, әллә ниләр очравы ихтимал.

Ягъкуб алтын акчаларны санап алды да, итек кунычына беркетте. Калган көмеш вә башка акчаларны чикмәненең эчке ягына тегеп куйды.

Хәзер аның акчасы барлыгын берәү дә белерлек төсле түгел иде. Ягъкуб шәһәрдә озак тормады. Юлга әзерләнеп, тугры авылына кайтып китте. «Нигә миңа башка урыннарда бер әмат булып йөрергә! Ходага шөкер, эшләдем, акча таптым. Бу акча мәңгегә дә җитәр. Башлап үземә бер бүрек алам, аннан соң арба, ат сатып алам. Ул вакыт эш бөтенләй башка булыр. Хатыныма җитен алып бирергә кирәк, кыш көне тик җерләп утырсын. Анама да бар кирәкне алып бирәм, ул да карт көнендә рәхәтләнсен. Балаларымны өр-яңадан киендерәм. Кыш буена җитәрлек утын алсам, аннан соң миннән бай кеше дә булмас», – диеп уйлап, алга таба юнәлде.

Ягъкуб һаман алга таба бара, тизрәк өенә кайтырга ашыга. Алла бәхетне биргәч, нигә ашыкмаска? Менә инде авылга илле чакрым чамасы гына калды. Ләкин бу вакыт кинәт кенә аның артыннан бер кеше куып җитте. Ягъкуб әйләнеп карады, ни күрсен, килгән кеше Каюм! Аны күргәч, Ягъкубның эче жу-у итеп китте. Күңеле әллә нинди бер һәлакәт булуын сизгән төсле булды. Нишләргә? Каюмнан аерылырга бер дә мөмкин түгел. Чөнки юллары бер. Аны җиткермәс өчен шәбрәк барыр иде, авылга җитеп бер-ике көн торыр да иде, мөмкин түгел. Чөнки шулкадәр күп җир килеп Ягъкуб тәмам арыган, никадәр ашыкса да, Каюм аны барыбер куып җитәчәк, Каюм аңа караганда күп таза һәм йөрергә дә өйрәнгән. Нишләсәң дә Каюмнан котылырга әмәл юк. Ягъкуб, бар эшне Аллага тапшырып, аның хөкеменә буйсынырга, Каюм куып җитсә дә, аның белән янәшә бармаска, бер читтәрәк барырга карар бирде.

Артыннан Каюм килеп җитте һәм Ягъкубның кулбашына сугып:

– Нихәл, иптәш, исәнме? Миннән кача алмадыңмыни?

Ягъкуб:

– Исәнме әле, иптәш? Кайдан сине болай җил ташлады?

Каюм:

– Ха-ха-ха... Син Каюмны начар кешеләр арасына эләгеп каторгага китте, диеп уйлагансыңдыр? Шул минем эләккәнне авылга кайтып сөйләр өчен ашыга торгансыңдыр әле?

Ягъкуб:

– Ул ни дигән сүз, Каюм? Ми-

нем синдә ни эшем бар? Синең шул хәлдәлегеңне күргәч, үзем дә кызгандым.

Каюм:

– Кызгандың? Синме?

Ягъкуб:

– Ихлас кызгандым. Син миңа бер начарлык та эшләмәдең, мин дә сиңа шулай ук. Шулай булгач, нигә безгә дошманлашырга? Син минә миңа дөрестен генә әйт: ничек син төрмәдән котылдың?

Бу сүздән соң Каюм Ягъкубка шулкадәр ачу белән карады ки, Ягъкубның бөтен тамырлары чымырдап китте.

Каюм:

– Ничек котылмыйм? Мине бит нахак яптылар. Андый эш булмыймыни?

Ягъкуб:

– Нигә булмасын? Син, ул угрылар арасына кермәдем, дигән сүзең белән мине бөтенләй шатландырдың.

Каюм:

– Мин берәр явыз бәндәмени? Әйт хәзер, явызмы?

Ягъкуб:

– Сине явыз дип кем әйтә соң әле? Ходадан үзең курык!

Юлчылар беразга туктадылар. Ахырда Каюм ачулы тавыш белән сүз башлап:

– Син мине теге йозаклар аркасында харап булдым, диеп уйлагансыңдыр инде?

Ягъкуб:

– Нинди ул йозаклар?

Каюм:

– Нинди булсын, син мине бернәрсә дә белми, диеп уйлый торгансыңдыр. Беләм, барысын да беләм!

Ягъкуб:

– Нинди ул йозаклар? Мин алар турысында кешедән генә ишеткән идем, хәзер инде оныттым.

Каюм:

– Оныттың? Онытырсың син!

Ике юлчы шушы тарика сөйләшеп юлларын дәвам иттеләр. Аларга бер кичкенә генә авыл аша үтәргә тугры килде. Ягъкубның бу авылда бер танышы бар иде. Ул шунда кермәкче булса да, Каюм: «Юк, анда керергә кирәкми», – диде. Ягъкуб та, йомшак күңелле булганга, үзеннән көчле Каюмнан куркып, аңа буйсынды. «Аны ачуландырырга ярамый, буйсынырга кирәк. Тик үз авылымызга җиткәнче кыланып барсын, авылга кайткач, аңардан аерылып булыр әле», – диеп уйлады.

Авылны узгач, Каюм, юлдан бер урманга таба борылып, Ягъкубны да үз артыннан алып китте. Урманга кергәч, бер агач төбенә күләгәгә утырып:

– Монда хәл җыярмыз. Китер, ашардай нәрсәң бар? Бераз көч җыйыйк!

Ягъкуб:

– Миндә ни булсын, (капчыктан чыгарып) менә арыш икмәге дә бераз кыяр.

Каюм итек кунычыннан зур бер бөкләүле пычак чыгарды. Бу пычакны күреп, Ягъкуб ни эшләргә белми курыкты. Каюм, капчыкны алып, үзе теләгәнчә эшен йөртә башлады. Башта икмәкне алып, зур бер кисәкне үзенә кисеп, Ягъкубка кечкенә генә бер кисәк бирде. Кыярның да яхшыракларын үзенә сайлап, калган аламаларын Ягъкубка ыргытты. Ягъкуб куркуыннан куян шикелле калтырый һәм үзе: «И, Ходаем, авылга чаклы гына исән кайтарсаң, синең хакыңа садака бирер идем», – диеп, Ходага ялвара иде.

Каюм:

– Беләсеңме, Ягъкуб? Без көндез бармыйк. Күрәсең бит, көн нинди эссе. Көндез ял итик, кичне барыйк. Шулай булганда без шәбрәк тә барырмыз, ике көннән өйгә дә кайтып җитәрмез. Хәзер ят, хәл җый!

Яттылар һәм йоклап та киттеләр. Таң алдыннан торып, кулда булган бар ризыкны ашап тагы юлга юнәлделәр.

Ягъкуб:

– Синең ахрысы, Каюм, юлга азыгың да юк?

Каюм:

– Мин аны каян алыйм? Кәсеп итеп тапкан акчам бар иде дә, аларның бары-

сы да шул каһәр төшкән төрмәдә калды. Аның өстенә күбрәк кәсеп итәргә син ирек бирмәдең. Анда сиңа да өлеш чыккан булыр иде. Мәңге рәхәтләнер идең.

Ягъкуб:

– Син кызык кеше, Каюм! Авылда чакта син болай түгел идең. Син мондый уйларны төрле шәһәрләрдә йөреп тапкансың.

Каюм:

– Ичмасам тик тор инде! Анда синең эшең юк! Менә нәрсә, иптәш: син инде кайтсаң, кайткач та иң элек хатыныңа, аннан старшинага, аннан соң бөтен авылга сөйләп йөрерсең: менә Каюм фәлән җирдә бер кибетне таламакчы булган иде, мин аны хуҗага барып әйттем дә, талый алмады, аннан икенче көнне аны солдатлар белән төрмәгә алып киттеләр, диярсең?

Ягъкуб:

– Юк, Каюм, син мине белмисең бит, кеше гайбәтен сатып йөрүнең алама эш икәнлеген үзең дә беләсең. Монда минем эш түгел, Ходай эше. Ул теләсә нишләр. Син тәүбә итсәң, ярлыкар. Абынгансың икән, торырга мөмкин!..

Каюм:

– Билгеле инде, тәүбә итәм. Менә шушы көннән алып намаз укый башлыйм. Мәсҗедкә йөри башлыйм, ләкин шунысы начар – акча юк. Син генә изгелек итеп бирмәсәң... Карале, Ягъкуб! Дөрестен генә әйт әле! Сиңа теге ниләр... йозаклар өчен хуҗа күп бирдеме?

Ягъкуб:

– Бу тугрыда мин гаепле түгел. Йозакларны мин әйтмәдем, үзе белде.

Каюм:

– Сөйлә инде юкны... Шулай да, бераз алгансыңдыр әле?

Ягъкуб:

– Әлбәттә, алдым, анысын яшереп булмый инде. Киткән чакта бер-ике сум чәйлек бирде шул.

Каюм:

– Аның өстенә эшләп алганың, барысы күпме акча алып кайтасың?

Ягъкуб:

– Кем белә аны? Тугрысын әйткәндә, мин санамадым да. Күпме биргән, шуларны алдым да киттем.

Бу сүзләрне сөйләгәндә Ягъкуб дердер калтырый, йөрәге тибә иде. Төн булганга, аның өстенә алар икәү генә булып, Каюм да аңа караганда күп көчле булганга, андый-мондый нәрсә булыр, диеп йөрәге ярылырга җиткән иде.

Каюм:

– Күптер, күрәсең? Шуңа күрә санап та өлгерә алмагансың. Соң нишлимез, уртак бүлмибезме?

Ягъкуб:

– Ничек ул уртак?..

Каюм:

– Ничек булсын? Бик ансат. Уртак ничек бүләләр, шулай бүләмез! Ихтимал барысын да биреп куярсың? Әгәр барысын да бирсәң, менә мин сине иптәш, чын иптәш, дияр идем!

Каюм шундый сүзләрне сөйли, үзе бу сүзләрнең Ягъкубка ничек тәэсир иткәнлеген тикшерә, аның куркуы белән кәефләнә, аның болай Ягъкубны куркытуы мәченең тычкан белән уйнавына охшый иде.

Ягъкуб:

– Син ни сөйлисең, Каюм?

Ягъкуб бу сүзләрне чак-чак ишетелерлек итеп кенә әйтте. Аның тавышыннан бертөрле ялыну да, үпкәләү дә ишетелә иде.

Каюм:

– Йә, тагы синең акчаларың белән... күрәсең, ул бик күптер, юкса бу кадәр каушамас идең, әнә шул усак яфрагы шикелле калтырамас идең. Син бәлки кайткач: «Каюм юлда мине талый язды», – диеп сөйләп йөрерсең?

Ягъкуб:

– Алла сакласын! Син юкны уйлыйсың. Мин бит сине бер кешегә дә сөйләмәм, диеп әйттем инде. Менә ант итәм, бер кешегә дә сөйләмәм.

Каюм:

– Ант ит!

Ягъкуб ант итәргә кереште. Аның бу вакыттагы килеше шулкадәр үзгәргән иде ки, аны карап кызганмаслык түгел иде.

Каюм бер уч туфрак алып Ягъкубка бирде дә:

– Йә, ант ит! Менә бу туфракны барысын да йот, шулвакыт ышанам.

Ягъкуб ант итте. Туфракны алып, аз-аз гына кабып бөтенләй ашап бетерде.

Моны күргәч, Каюм, җиңеләеп киткән кеби озын сулыш алып:

– Менә шулай, иптәш! Хәзер инде мин дә сиңа ышанам!

Шуннан соң алар тагын бераз алга таба киттеләр. Кояш чыкты. Алар баруларыннан тукталмадылар. Кояш гәрчә бик югары күтәрелмәсә дә, бик нык кыздыра иде. Шуңа күрә юлчылар ахырда юлдан урманга борылып хәл җыярга яттылар.

Төшкә табан эсселек чыдарлык дәрәҗәдән дә үтте. Җилнең әсәре дә юк иде. Бар нәрсә тынды. Тын алырга да кыен була башлады.

Каюм белән Ягъкуб, гәрчә арыганга, бераз йокласалар да, кояш артык пешерә башлагач, тәмам тиргә батып, торырга мәҗбүр булдылар. Алар башта урман алдында гына ятканнар иде. Анда тагын да бөркү булды. Өстә кояш, аста тынлык, җил исми, тәмам яккан мич кеби иде. Бер җирдә эзләп су да таптылар. Эчә-эчә корсаклары ярыла язды. Ахырысында, түзәргә әмәл калмагач, баз казып, шунда кереп яттылар. Базда җир җылынганчы суык булса да, ул да тиз җылынды, анда да эссе булды. Кич җиткәнче алар тәмам хәлдән тайдылар.

Кичкә таба чак-чак кына аякларын кузгатып, тагы юлга чыктылар. Көн бераз сүрәнләнде, юлчылар урманнан чыгып иркен һавада азрак сулыш алып, алга таба юнәлделәр.

Ягъкуб:

– Ялкауланмасак, таң белән өйдә дә булырмыз, бу җирдән авылга кадәр бары егерме генә чакрым.

Каюм:

– Иншалла, булырга кирәк иде. Син миннән генә калма! Шәбрәк атла!

Алар җиде чакрым чамасы да китеп өлгермәделәр, тегендә офыкта (җир читендә) бер кара болыт күренде. Бара-бара бу болыттан кояш нурына кызарган икенче болытлар аерылып тарала башладылар. Төркем-төркем болытлар бер аерылалар, бер кушылалар, төркемләп йөриләр иде. Кояш бөтенләй югалды. Кошлар, бер көтүгә җыелып, әллә кая качтылар. Ата кошлар ана кошларны ашыгыч-ашыгыч чакыралар, кайсылары балалары янына ашыгалар, балалары булмаганы әллә нинди куркыныч сизгән кеби, кая булса да ышыкланырга тырышалар иде. Бераздан соң бөтен дөнья тынды. Бер үлән булсын селкенми, бер кош та кычкырмый иде. Бер зур куркынычны көткән төсле, һәрнәрсә тәмам тынды, посты, үлде.

Тагы бераз торгач, әллә каяндыр ерактан дөбердәү ишетелде. Гүя әллә кая еракта зур диңгез дулкыннары ташларга бәрелә, гүя каршы килгән нәрсәләр белән көрәшәләр төсле иде. Яшеннәр бертуктаусыз кап-караңгы күкне яралар. Тирә-якны берәр мизгелгә ялт иттереп китәләр иде. Күптән түгел генә кыздырган кояшның әсәре дә юк, аны бу кара болыт үз артына әллә кая, алмаслык җиргә яшергән иде.

Каюм:

– Ни эшлимез, иптәш? Алга ничек барамыз? Тиздән дөм караңгы булыр. Күзгә төртсәң дә күренмәс. Юлсыз баруы куркыныч бит?

Ягъкуб:

– Әнә, анда кечкенә генә урман күренә, әйдә шуңа барыйк!

Каюм:

– Кая анда урман? Мин ул урманны түгел, сине дә чак-чак кына күрәм!

Ягъкуб:

– Менә күтеп тор әле, яшен яшьнәр, син карап тор! Шулвакыт юлның уң ягында урман күренер. Әйдә, тизрәк! Һаман караңгылана.

Алар, ашыгып-ашыгып, урманга таба киттеләр. Кара стена тәмам якынлашты. Тирә-як дөм караңгы булды. Яшен яшьнәмәсә, юлчылар берен-берсе күрә алмыйлар иде. Кара стена якынлашып тарала башлады. Бер минут эчендә бөтен дөньяны – кояш чыгышыннан алып кояш батышына кадәр – болыт каплады. Шул болытның һәр җиреннән диярлек чатырдап-чатырдап күк күкри, күзне сукырайтыр дәрәҗәдә яшен ялтырый башлады. Күк күкрәү тәмам дәһшәткә әйләнде. Нәкъ түбә тугрысында нечкә генә чатырдау башлый да, тирә-якка таралып, әллә кая еракта җуанга әйләнеп туктый иде. Кемнеңдер дөнья зурлыгы, кулы салават күпере шикелле күпердән зур-зур ташлар тегермәне төсле иде. Ул бетми, тагы икенче җирдән ялт итеп яшен яшьни һәм аның соңында күк күкрәү ишетелеп, бөтен дөнья тоташ бер тавышка әйләнә иде. Күк күкрәү туктаган арада әллә нәрсәнең ерактан гөжләп килгәне дә ишетелә иде. Аның өстенә яшен дә кушылып, тәмам куркынычлыга, каты вакытындагы пожарга әйләнгән сымак булган иде.

Каюм:

– Ягъкуб! Кая син? Мине кулдан тот! Юкса мин егылам. Аяклар тыңламый башладылар. Тәмам хәлдән тайдым.

Каюмның тәмам коты очкан, аяклары куллары калтырый иде.

Ягъкуб:

– Кил, миңа тотын, ерак түгел инде. Әнә, яшен яшьнәгәндә күренеп тора.

Каюм:

– Ягъкуб, иптәшкәй! Зинһар, минем яннан китмә инде! Мин бу яшеннән бик куркам. Эх, тизрәк урманга җитәргә иде! Күрәсең, нинди куркыныч! Менә яңгыр да төшкәли башлады. Әйдә, әйдә, тизрәк! Йөгерик!

Каюм бар көче белән Ягъкубның кулына асылынды. Ягъкуб үзе дә көчсез булганга, Каюмны чак-чак кына сүрәп алып бара иде. Көч-хәл белән куе агачлык арасына барып керделәр. Каюм шундук агач төбенә егылды. Ягъкуб та хәлсезлектән ятты. Шул минутта урман өстеннән бик каты җил үтеп китте. Давыл бар көче белән өрә, сызгыра, урмандагы агачларны урталай бөгә, ботаклар сынып-сынып төшәләр иде. Якын гына җирдә әллә нәрсә шаулап бөтен урманны яңгыратты. Әллә нәрсә шатырдап җиргә егылды, бөтен җир селкенеп китте. Анда күк яңадан күкрәп бөтен дөньяны дерелдәтә, тегендә давыл иркенлек белән дуылдап, җуан-җуан имән агачларын каерып ташлый иде. Бераздан соң яңгыр чиләкләп түгә башлады. Бөтен урман су астына калып, тау сыман җирләрдән елгалар ташыган шикелле булып ага башладылар. Күк күкрәү, яшен, давыл, ташкын – бары бергә кушылып шулкадәр куәтле тавыш купты ки, зилзилә вакытында да андый тавыш булмас төсле иде. Бертуктаусыз ялтырый торган яшеннән, чиләкләп түгә торган яңгырдан, гөжләп торган давылдан урманның иң куе җиренә качып та котылырга мөмкин түгел иде.

Каюм бер җирдә ята да, тора да, утыра да алмады. Ул бер урыннан икенче урынга күчә, йөгерә, кычкыра, кулларын уа, тәмам шашкан иде.

– Ягъкуб, Ягъкуб, син кая? Йокламыйсыңмы? Бернәрсәдән дә курыкмыйсыңмы?

Ягъкуб:

– Юк, йокламыйм да һәм бернәрсәдән дә курыкмыйм да!

Каюм:

– Яшен сукса?

Ягъкуб:

– Ходаның язмышы! Шуңа күрә мин аңа ялварам да...

Каюм:

– Аңа ялварсаң ул ярлыкыймыни? Ах, карале анда ничек шартлый!

Ягъкуб:

– Ярлыкый, бары тәүбә генә ит!

Каюм:

– Миндәй гөнаһлы кешегә ничек тәүбә итәргә, мине ничек Алла ярлыкасын.

Ягъкуб:

– Нигә? Син тик чын күңелдән генә тәүбә ит! Синең гөнаһларың Алла каршында бик кечкенәләр. Син гөнаһлы булсаң, башка кешеләр дә гөнаһлы бит... И Ходаем, гафу ит! Бу ни бу!

Шул сүздән соң алар икесе дә җиргә яттылар. Уттан ясалган ук, бер секунд эчендә бөтен һаваны кисеп, Каюм яңа гына яныннан киткән бер агачны бәреп сукты. Агач бик зур һәм ботаклы иде. Яшен аны башыннан алып тамырына кадәр йомычкага әйләндерде. Ботаклар бер якка очтылар. Агачтан эз дә калмады.

Каюм көч-хәл белән генә күтәрелде. Бу эш күп булса, алардан ун сажин җирдә генә булган иде. Каюм бераз гакылын җыеп, Ягъкубны кулыннан тотты да, ялына башлады:

– Әйдә, Ягъкуб, киттек, качыйк бу җирдән! Мине харап итмә! Бу җирдә мине Хода сугар!

Ягъкуб:

– Кая соң качарга?

Каюм:

– Күрәсең бит, әнә, агач яна, аны яшен сукты, инде бөтен урманга ут кабар. Без кайда торырмыз, кая китәрмез? Ах, куркыныч, коточкыч! Әнә, күрәсеңме, әллә нәрсә, әллә кем куак артында тора, ике күзен миңа текәгән?..

Ягъкуб:

– Нишлисең син? Анда бит берәү дә юк. Ходага ялвар! Дога укы, бернәрсә дә булмас!

Каюм:

– Мине инде Хода ярлыкамый! Син мине кем диеп беләсең? Ах, битем яна!

Ягъкуб:

– Алла гафур, тәүбә генә ит!

Каюм:

– Юк-юк, миңа ярлыкану юк инде! Мин явыз! Эштән чыккан явыз кеше! Авылымызда бөтен угырларны эшләүче, сезнең малларыңызны алып китүче – мин, барысын да мин эшләдем. Миңа башка кешеләр өйрәттеләр. Кибетне талаучы да мин. Мине тотып төрмәгә яптылар, аннан да качтым. Сине дә үтермәкче булган идем... Аһ, иптәш, зинһар, коткар! Әнә теге куак эчендәге нәрсә миңа карый, миннән көлә, тотарга тели. Сакла, зинһар, сакла!

Каюм, тәмам гакылыннан шашып, йодрыклары белән күкрәгенә сугып, киемнәрен җыртып, шулай ялына иде. Кинәт кенә аларның башы очында шытырдап күк күкрәде. Алар икесе дә һушсыз булып җиргә егылдылар. Суга чыланып күшегеп беткән Ягъкуб, исенә килгәч, тирә-ягына каранды. Бу вакыт Каюм тирәләп әйләнеп йөри, нәрсәгәдер йөгерә, үзе: «Мин карак кына түгел, мин кеше үтерүче! Бер хәерчене үтердем, аның акчасын алырга теләдем, кулымны канга болгадым, яныннан бары өч кенә тиен акчасы чыкты. Әнә шул хәерче хәзер мине, мине... минем артымнан йөри. Әй, Ходаем, коткар! Гафу ит!», – диеп сөйләнә, нәрсәдәндер агачлар арасына качарга тырыша иде.

Ягъкуб көч-хәл белән торды да, Каюмны тотып, исенә китермәкче булды.

Каюм:

– Юк, мине Хода җәзалар, яшен белән сугар. Әнә агачны суккан шикелле мине дә яшен сугар! Мин разбойник, мин юри кеше күзенә яхшы күренергә тырыштым, бар гаепне кеше өстенә аударырга тырыштым. Сине суярга теләдем. Сине өйгә кайтып сөйләмәсен, дидем. Хәзер инде сөйлә! Инде минем актык минутым җитте. Барысына да минем нинди кеше икәнлегемне белдер!

Ягъкуб:

– Тукта әле, Каюм, тынычлан. Сиңа ни булды? Миңа ышанма, Ходага ышан! Мин үз антымны бозмам инде. Антымда торачакмын һәм синең тугрыда бернәрсә дә сөйләячәк түгелмен!

Шулай итеп, Ягъкуб Каюмны тынычландырырга тырышты. Анда күк күкрәү үз эшен эшли, яшен дә туктаусыз ялтырап тора иде.

Күк күкрәп, яшен яшьнәде исә, әллә

кая әллә нәрсә шартлады исә, Каюм тагын торып чабарга, куркыныч нәрсәләр сөйләргә керешә, үзен кеше суючы, вор диеп атый иде. Аның күзенә әллә нинди хәерчеләр күренеп, аңа бармак белән янаган төсле була иде. Ул бертуктаусыз ничек хәерчене үтергәнлеген Ягъкубка сөйли һәм аңарга бу эшне башка кешеләргә дә сөйләргә куша иде.

Күк күкрәде, яшен яшьнәде, яңгыр да яуды. Бераздан бар да акрын гына азая башлады. Бары яшен генә яшьнәвеннән туктамый иде. Бара-бара яшен дә сирәгрәк ялтырый башлады. Бераздан соң болыт тәмам үтеп, күк күкрәве әллә кая еракта гына ишетелә башлады. Ягъкуб тирә-якка карады, яктыра башлаган иде.

Ягъкуб:

– Әйдә, Каюм, китәмез! Хәзер инде авыл ерак түгел, шәбрәк барыйк!

Каюм:

– Иптәшкәй, куркам! Кузгалырга куркам! Миңа һаман күк күкрәү ишетелә, һаман яшен яшьни, һаман шул хәерче мине күзли! Иптәш, бул яхшы, берсенә дә сөйләмә инде!

Ягъкуб тагын сөйләмәм, диеп ант итәргә кареште. Каюм бераз тынычлангач, алга таба киттеләр. Яңгырдан соң көн салкынчага әйләнгән иде. Юлчылар ашыга-ашыга алга киттеләр. Каюм бик озак тик торды. Тик бераздан соң гына:

– Их, йә нигә мине яшен сукмады!

Ягъкуб:

– Нишлисең? Сиңа ни булды, – диеп Каюмга карады. Бу вакыт Каюмның күзләре уттай янганнар, төсе агарган иде. Ягъкуб тәмам шүрләде. Шулай да Каюмны тынычландырырга тырышып:

– Әйдә, тизрәк! Менә безнең басу инде, бары биш кенә чакрым калды!

Каюм:

– Биш? Бары биш кенә чакрым? Менә инде берәрсе очраса, син барысын да сөйләрсең?

Шул сүзләрдән соң, котырган бүре шикелле Ягъкубка ябышып, тиз арада ул Ягъкуб өстенә менеп утырды.

Ягъкуб:

– Нишлисең син? Җибәр, иптәш! Җибәр! Мәңге догачың булырмын. Вә Алла, берсенә дә сөйләмәм, мә, ал бар акчамны! Бары мине генә һәлак итмә. Балаларны ятим калдырма! Хатынны тереләй кабергә салма! Минем карчык анамны кемгә калдырырсың? Гомер буена сине туганым, атам диеп йөрермен, тик коткар гына! Ичмасам, актык минутта дога кылырга ирек бир!

Каюм:

– Теге дөньяда дога кылырга өлгерерсең әле! Анда теләгәнчә гыйбадәт кылырсың!

Каюм шулай диеп, бер кулы белән Ягъкубның кулларын тотып, тезе белән күкрәгенә басып, икенче кулы белән итек кунычыннан пычак чыгарды.

Ягъкуб һаман күз яше белән ялвара иде. Ләкин пычакны күргәч, актык өметен өзеп, озын сулыш алды да:

– И, Ходаем! Гадел Хаким! Бу эшкә бер шаһит та җибәрмисең бит! Минем гаепсез үлгәнемне берәү дә күрми кала! Ичмасам, ахирәттә миңа шул газабым бәрабәренә яхшы урын бир!

Бу вакыт җил аның янына бер кисәк өермә үләнен тәгәрәтеп китерде. Ягъкуб шул үләнне тотты да, Каюмга карап:

– Җир йөзендә менә бу өермә үләне синең мине нахак үтергәнеңә шаһит булсын!

Каюм:

– Тик шаһит булсын! Теләгәнчә карасын! Тапкан шаһит, шәп шаһит! – диеп, теше белән пычакны ача башлады. Бу пычак юл буена икмәк кисәргә яраган иде, хәзер инде Ягъкуб шул пычак белән шәһит булачак булды.

Ягъкуб:

– И Ходаем, ал җанымны, кабул ит! Балаларымны, хат.., – диеп әйтеп тә бетерә алмады, Каюм, бар көче белән селтәнеп, пычакны Ягъкубның бугазына кадап, әллә ни әйтеп көлмәкче булган иде дә, ләкин бугаздан кан чиртеп, аның тамагын каплады. Хода монда да

шаһит булган кешедән көләргә ирек бирмәде.

«Т» авылының ике көтүчесе авылга йөгереп кайталар да, фәлән җирдә суелган бер кеше ята, кем икәнен белмимез, курыктык, диеп хәбәр тараталар. Шул хәбәрне ишетеп, бөтен авыл аякка баса. Тиз генә старшинага җибәрәләр. Озакламый старшина да килеп җитә. Старшина үлекне карый һәм берничә ышанычлы кеше сайлап үлекне сакларга, аның янына үзләре дә бармаска һәм кешене дә җибәрмәскә куша. Кем дә кем үлек янына көчләп барырга тырышса, аны хәзер үк кулга алып каравылга ябарга яисә гаепле кеше диеп волостька илтергә куша. Шул көнне үк фәлән җирдә бер суелган кеше ята, исеме, атасының исеме хәзергә билгеле түгел, диеп исправникка да хәбәр җибәрәләр.

Авыл халкы һәммәсе дә диярлек кәсепкә киткәнгә, күбесе өйдә юк иде. Хатыннар өйдә булса да, аларның ул үлектә артык эшләре юк, берәр шунда үтеп баручы урыс әчкәндер дә, үлгәндер, диләр иде.

Бары Ягъкубның анасы һәм хатыны гына бу хәбәрне ишеткәч тә, беравыздан: «Бу, әлбәттә, безнең Ягъкубтыр, башка кеше булмас», – диеп, алдан ук җыларга тотындылар. Аларның йөрәкләре бәхетсезлекне алдан ук сизеп торган иде. Алар старшинадан үлекне карарга рөхсәт итүен сорадылар. Әгәр Ягъкуб булса, аны өйләренә алып кайтып, мөселманны күмгән шикелле күммәкче иделәр. Алар законны белмәгәнгә, үзләренчә хөкем кылалар иде. Ләкин старшина аларның сүзен илтифатка да алмады, суд килгәнче бер кеше дә җибәрмәскә кушты.

Ике көннән соң Каюм да кайтып җитте. Ул тәмам үзгәргән, баштанаяк купшыланган иде. Ул, гаять шат булып, һәркем белән уйный, көлә иде. Халыкның мир җыенына җыелганын ишеткәч, ул да шунда китте. Мир җыенында аңа бар булганны сөйләп бирделәр. Каюм шунда түзә алмады:

– Соң аның хатыны, анасы нишлиләр? Бик җылый торганнардыр? – диде.

Халык:

– Кемнең хатыны?

Старшина:

– Кемнең ул хатыны?

Каюм:

– Соң, сез бит... Кем соң әле шунда суелган кеше Ягъкуб диде?

Старшина:

– Хәзергә аның кем икәнлеге билгеле түгел әле. Авылдан кәсепкә киткән кеше азмыни? Ихтимал, бөтенләй башка кеше булып чыгар.

Каюм:

– Кем булса да булсын, тикшергәнгә кадәр тик ятсын! Кем үтергәнен шаһитлар әйтер.

Шунда булганнарның кайсылары көлделәр: «Ну соң бу Каюм! Ни булса да бер сүз таба. Ничек соң япа-яланда шаһитлар табылсын! Ни булса да, бер кешегә бер кеше булгандыр», – диделәр.

Бервакыт кыңгырау тавышы ишетелде. Берничә минуттан соң волостьтан земский тройкасы да килеп җитте. Исправник арбадан төшкәч тә:

– Кая үлек?

Старшина:

– Урынында, ваше благородие!

Исправник:

– Писер! Понятойлар сайла да, аларны ант иттереп, үлек яткан урынга алып бар! Мин дә хәзер шунда булырмын. Старшина, әйдә минем арттан!

Өйгә кергәч, исправник, ишекне яптырып, картлардан:

– Берәр кешедән шикләнмисезме, берәү-берәү андый-мондый сүз сөйләмәдеме?

Старшина, Каюмны авылда иң ышанычлы кешеләрдән диеп белгәнгә, аның бая ычкындырган сүзләрен исправникка әйтмәде.

Озак та тормый доктор да килеп җитте. Понятойлар да килде. Алар эчендә Каюм да бар иде. Исправник Каюмны күреп:

– Нигә шундый яшь кешене понятойга сайладыңыз? Монда картлар, ышанычлы кешеләр кирәк!

Старшина акрын гына исправник колагына:

– Ул, ваше благородие, яшь булса да, бу авылда беренче кеше. Картлар арасында да андый гакыллы кешене табуы читен. Ул, тикшерә башласа, тәмам дөрестен сөйли дә бирә.

Старшина шул сүзләрне сөйли, үзе ара-тирә Каюмга карый иде. Каюм боларның барысын да күреп тора иде. Исправник, старшинаның сүзләрен тыңлап бетергәч тә, Каюмга карап:

– Яхшы, китерегез аны монда! – диде.

Каюм бу сүзләрне ишетеп ап-ак булды. Исправник аның агарганын күрсә дә, күрмәгәнгә салышты. Барысы да үлек янына киттеләр. Үлек янына килгәч, исправник:

– Понятойлар, караңыз! Үлектә берәр көчләү галәмәте юкмы?

Каюм:

– Юк, кая монда булсын! Монда эш берьюлы булган, пычак белән бугазга берне кадаганнар да, вәссәлам!

Исправник Каюмның бу сүзен дә сизеп алды.

Үлекнең чикмәне ертылган иде. Актара башлагач итек эченнән ун тиенлек көмеш акча чыкты. Үлекнең итекләрен салдырдылар, итек эченнән йөз сум алтын акча килеп чыкты. Моны күрү белән Каюм чыдый алмады: «Йөз сум, диген! Әмма усал икән, әйтмәде бит!», – диеп кычкырды. Ләкин тиз генә, ялгыш ычкындырганын сизеп, тирә-ягына каранды. Исправник туп-туры аңа карап тора иде. Каюм ни эшләргә белмәде. Агарды, күгәрде һәм җәһәт кенә халык арасына качты. Исправник бер сүз дә әйтмичә тик торды.

Менә бервакыт Ягъкубның анасы һәм хатыны килеп җиттеләр. Алар артыннан Ягъкубның баласы да килгән иде. Анасы һәм хатыны Ягъкубның гәүдәсе янына килеп җитмәс борын ук, аны танып, үкереп елый башладылар. Икесе дә үлек өстенә егылып, аяныч сурәттә үксергә керештеләр. Малай да атасы янына килеп, атасын чакыра иде.

Исправник башта Ягъкубның анасын һәм хатынын үлек яныннан алып китәргә кушмакчы булган иде, ләкин соңыннан уен алыштырды:

– Тик алар еласыннар, без үз эшемезне эшләргә өлгерермез әле, – диде.

Ана белән хатын озак еладылар. Малай, үлгән вакытында Ягъкуб тоткан өермә үләненә күрсәтеп:

– Әни, әни! Кара әле, бу нәрсә? – диде.

Исправник бу эшләрнең барысын да күреп, Каюмга карап:

– Кара әле, анда нәрсә бар? Миңа күрсәт!

Каюм, теләр-теләмәс кенә үлек янына килеп, калтыраган кулы белән өермә үләнен алды. Аннан соң, агарып, үләнне учында уды да, читкә ташлады.

Исправник:

– Нигә аны ташлыйсың? Нәрсә ул? Китер монда!

Каюм, калтырап, акрын гына тавыш белән:

– Юк, ваша благородия, бу бернәрсә дә түгел! Ул тегеләй генә... алабута үләне...

Исправник:

– Нинди алабута ул, күрсәт!

Каюм:

– Алабута булгач, алабута инде! Шунда бер үлән. Күрәсең, үлгән чакта бер үләнне эләктергән дә, шулай итеп аның кулында калган!

Исправник:

– Нинди соң ул үлән? Ничек диеп атыйлар? Чын исеме ничек?

Исправник Каюмның һич сәбәпсез каушаганын, аның аптырап калганын сизгән, шуңа күрә дә аңардан җентекләп сорый иде.

Каюм:

– Ул болай гына! Бу-у... өермә... өермә үләне...

Малай:

– Абый, карале, менә тагы бу нәрсә? Алар монда бик күп! Аларның барысы да күргән, – диде. Үзе бер өем өермә үләнен Каюм янына китерде.

Каюм:

– Алдыйсың! – диде дә, малайны читкә төртеп җибәрде.

Исправник:

– Җитәр! Эш ачылды инде. Хәзер син берсен дә алдамыйча әйт инде! Син үлекнең кыйналмаганын алдан ук белдең. Анда акча табылгач, исең китте һәм аның әйтмәгәненә үкендең! Хәзер инде менә бу өермә үләне алдында калтырыйсың. Әйт, нигә син ул үләннән куркасың? Икърар ит! Эш ничек булды?

Каюм башта алдамакчы булган иде дә, ләкин бар да бушка чыкты. Исправник аны һәрбер сүзендә тотты. Аңа өермә үләнен күрсәткәч, Каюмның төсе тагы агарды. Шуңа күрә Каюм артык яшерә алмады, барысын да икърар итте.

Ягъкубны ни өчен үтергәнлеге вә ничек үтергәнне, ничек Ягъкуб үлгән вакытта өермә үләнен тотып: «Менә бу үлән актык минутымда минем нахак үлгәнемә шаһит булсын», – диеп, ничек аның аягына ябышканын, Ягъкубны үтергәч кая барганын, каннарны юып яңа киемнәр кигәнен – һәммәсен берәмберәм сөйләп бирде.

Исправник:

– Менә ул нинди явыз кеше икән! Старшина! Ничек син аны понятойга сайларга батырчылык итә алдың?

Старшина һәм халык:

– Нишлик, Ваша благородия? Ул безнең арада бик ышанычлы кеше, һичвакыт начарлык эшләгәне юк иде. Барымыз да шуның кеби булсак, Ходага шөкерана кылыр идек!

Исправник:

– Ә соң авылыңызда моннан элек берәр үтереш яисә урлау булмадымы?

Халык:

– Үтереш булмады. Урлаулар булса да, анда Каюм гаепле түгел, чөнки йортларны тентегән вакытта ул үзе югалган әйберләрне барысын да тапты. Аның йортыннан бернәрсә дә чыкмады.

Исправник, Каюмга карап, ачулы тавыш белән:

– Әйт, дөрестен, болар бар да синең эшеңме?

Каюм барысында да үзен гаепле, диеп икърар итте һәм хәерчене үтергәнен дә сөйләп бирде. Боларның барысын да халык тыңлап торды һәм бөтенләй исләре китте. Бәгъзеләре: «Кем соң аңа ышанмый иде! Без аңардан да гакыллы, аңардан да тугры кеше юк, диеп уйлый идек. Менә ул нинди икән! Беренче карак, явыз бер бәндә, кеше суючы икән», – диделәр.

Исправник Каюмга:

– Кешеләрне алдарга мөмкин, ләкин Хода күзеннән һичвакыт кача алмассың! – диде, һәм шундук Каюмны кулга алырга һәм каты каравыл астында шәһәргә җибәрергә кушты.

Исправник:

– Менә, җәмәгать, сезнең ышанган кешеңез! Ул сезне моңарчы алдап кына йөргән! Бик оста булганга, ни эшләсә дә сезгә сиздермәгән. Әмма, дөрестән дә, ул араңызда иң начар кеше булып чыкты. Моннан соң да аң булыңыз! Нинди начарлык эшләсәң дә, никадәр шул начарлыкны яшерергә тырышсаң да, бервакыт сизелмичә калмый. Без капчыкта ятмый, диләр бит, безгә яшерен булса да, Хода каршында билгеле, шуңа күрә ул залимнәрне бервакыт халыкка белдереп, тиешле җәзасын бирдерә. Хәзер Каюмга да тиешле җәзасы биреләчәк.

Каюмга хөкемне озак көтәргә туры килмәде, тиз арада аңа суд булып, аны каторгага хөкем иттеләр. Каюм, богаулар киеп, Себергә мәңге каторгага китте.

Текстны басмага
***Рәисә Шәрәфиева** әзерләде.* ■

Хатирәләр кайта яңарып...

Бала чагым.
Шәфәкъ елгасыннан
Кызыл атлар сузылып су эчә!..

Роберт Әхмәтҗанов

«...Бүген мин авылыбызга кайттым. Иң элек, авылга керә-керешкә, калкулыкта озак тукталып, авылым авазларын, аның сулышын тыңлап, күңелгә тирән сеңгән авылымның таныш та, инде гүя таныш та түгел, вакыт буйлап шактый ерагая төшкән кадерле манзараны күзәтәм...»

Әлеге юллар шагыйрь, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Роберт Вәли улы Әхмәтҗановның «Мәгариф» нәшриятында басылып чыккан «Каләм җиле» китабындагы «Иске нигездә уйлану» дигән истәлек-хатирәсеннән алынды.

Әдипнең балачагы Татарстанның Балык Бистәсе районы Иске Арыш авылында, шагыйрь үзе язганча, Шәфәкъ елгасыннан атларның су эчкәнен, «Тургай канаты астына сыйган туган ягын»да талпынып үткән. Балачагыннан ук әдәби иҗатка тартылып үскән Роберт Әхмәтҗановның «Беренче яз» исемле тәүге шигырь җыентыгы 1958 елда дөнья күрә. Аның шигъри теле искиткеч матур чагыштыруларга бай һәм алар укучының күңел кылларын тибрәтеп көй сорап тора сыман. Шуңадыр да авторның шактый шигырьләре композиторлар тарафыннан көйгә салынган.

Роберт Әхмәтҗановның үзе исән чакта ике дистәдән артык китабы дөнья күрде. Арада балалар һәм яшь буын укучыларга багышланганнары да бар: «Сабыйлар хоры», «Таң җиле» кебек китаплар шундыйлардан.

«Каләм җиле» китабы – авторның үзе исән чакта басылган соңгы басмасы. Бу китапка авторның тормыш-яшәеш тәҗрибәсенә таянып иҗат ителгән истәлек-хатирәләре, тәнкыйди һәм публицистик язмалары, әдәби портретлар, памфлетлар тупланган.

...Иске китапларны актарганда,
кипкән гөл яфрагы булып,
очып төште минем яшьлегем!.. – дип ачылып китә аның беренче бите.

Шушы китапны кулыма алгач, аны соңгы битенә кадәр бер тын эчендә укып чыктым. Анда язылган истәлек-хатирәләрне күңелдән кабат-кабат искә төшереп, берничә көн үземне дә шул халәттә тоеп яшәдем бугай. Аннан, Роберт абый белән элемтәгә кереп, шушы басма хакында берникадәр мәгълүмат җиткерүен үтендем. Ул «Татарстан» радиосына килеп әлеге китапның язылуы һәм басылып чыгуы турында ихлас әңгәмә биргән иде. Радиоязма эфирда 2008 елның 25 мартында яңгырады. Бу безнең Роберт абый белән аның вафатына ике ай калгач язылган соңгы язма булды. Мин аны берникадәр кыскартып сезнең игътибарга тәкъдим итәм.

Дания:

– Роберт абый, гомерегез буе шагыйрь дигән изге миссияне йөрткән иҗатчы буларак, публицистикага алынуыгыз бераз уйландыра. Күңелгә сезнең шигъри юлларыгыз сеңеп калган:

Язмасам шигырь, уйлама,
Сүнгән дип тылсым көче.
Язмавым, дөньяда бераз
Сүзгә ял булсын өчен, – дип язган идегез бер шигырегездә.

Сез шушы публицистик китапны язганда, мөгаен, шигырьләрдән бераз ял итеп алгансыздыр. «Каләм җиле» китабының язылу тарихын бераз искә төшереп үтик әле.

Роберт абый:

– Моның тарихы кечкенә дә түгел шикелле, шул ук вакытта зур да. Каләм әһеле үзенең тормыш юлы, иҗатка килүе турында язарга тиештер, дип уйлыйм. Ул язучының эчке таләбеннән киләдер. Мин ике публицистик тупланма эшләгән идем. Аның беренчесе сәясәткә күбрәк корылган. Ләкин сәясәт, аккан су кебек, көн дә үзгәрә тора. Һәм аны тотып та булмый, аның кирәге дә шулкадәр генә. Аннан өр-яңа тупланма, әйтик, әлеге «Каләм җиле»н тупладым. Публицистика дигәч тә, ул глобаль формада түгел, ә бәлки безнең язучының көндәлек мәшәкатьләренә нигезләнеп язылган, күбрәк минем шигърияткә багышланган мәкаләләрдән тора.

Дания:

– Чыннан да, монда сезнең сабыйлык еллары, шул чорның тормыш-көнкүреше генә түгел, иҗатка анализ да бар.

Роберт абый:

– Бу китап, дөресен генә әйткәндә, бик озак әзерләнде. Ул вак иләктән иләнде, дисәң дә була. Чөнки беренчедән, аның кемнәргә аталган булуы җаваплылыкны арттырган булса, икенчедән, укучылар даирәсен чикли кебек. Чөнки ул укытучы китапханәсенә адресланып, укытучылар, педагогия көллиятләре һәм югары уку

йортлары студентлары өчен кулланма рәвешендә тәкъдим ителә. Шуның белән бергә публицистика дип әйтү бик зур җаваплылык йөкли. Чөнки хәзерге заман публицистикасы – ул глобаль киңлеккә әйләнде. Бүген публицист дөньяны айкап чыккан булырга мөмкин. Хәзер бит заман шундый, заманнан калышырга ярамый. Тәрәзәдән карап кына публицистиканы язып булмый. Ул нинди дә булса көндәлек алып бара торган амбар кенәгәсе дә түгел. Анда фикер кирәк һәм шул ук вакытта киңлек тә кирәк, тормыш киңлеге. Менә бу китап проза жанрына керсә дә, анда бөтен юнәлеш, төп проблемалар шигърият хакында. Монда күбрәк шигырь тәнкыйтенә тукталам. Китапның шулай ук исемен дә озак уйларга туры килде. Чөнки мин китап исеменә бик мәсъүл карыйм. Шагыйрьнең китап исемнәре фәлсәфи фикергә ия булырга тиеш, дип уйлыйм. Күпләргә ошаган бу исем. «Каләм җиле» дигән сүз мине шулай ук уйландырып җибәрде. Аның аз булса да җиле чыга кебек тоелды. Күбәләк канатының да җиле бар бит. Аның укучыларга тәэсире күпме җилле булгандыр, анысын алар әйтер.

Дания:

– Чыннан да, тәэсире җилле, мине сезнең белән очрашып сөйләшергә, тапшыру эшләргә нәкъ шушы «Каләм җиле» сәбәпче булды.

Роберт абый:

– Рәхмәт, рәхмәт. Әле башта, дөресен генә әйткәндә, скептик рәвештәрәк караган идем, чөнки сәясәт хәзер бик үзгәрә, шуңа күрә кульязманың яртысы киселде. Бу китаптан нәрсә калды дисәм, ни гаҗәп, бу китапны каян табып була, дип сораучылар күбәйде. Китап кибетенә керсәм дә, кая синең «Каләм җиле»ң, дип сорыйлар. Әйе, бу яхшы фал. Болай булса, яңадан чыгарырга да мөмкин, дим.

Дания:

– Менә шундый яратып укый торган китаплар кирәк, уйландыра торган...

Роберт абый:

– Әйе, китап – укучы укырлык булсын. Мин шуңа күрә тырышкан идем инде. Анда укучы өчен җитәрлек җим бар, дип уйлыйм. Китапка кергән мәкаләләрнең күбесе шигырь проблемасы турында. Хәзерге заман шигърияте турында, шигырь тәнкыйте хакында. Мин, мәсәлән, моңа кадәр дә күзәтеп киләм, чагыштырулар бар бит инде бездә, аналогия, дибез бит инде. Рус поэзиясенең тәнкыйтен карыйбыз, бүтән шигърият тәнкыйтен күзәтәбез. Хәзер инде замана да үзгәргәч, мин күбрәк интеллектуаль тәнкыйтьне, интеллектуаль юнәлешне уздырмакчы булдым бу китапта. Ул бәлки кайбер тәнкыйтьчеләр өчен ошап та бетмәс, ләкин, биредә үземчә хаклык та бар. Үзеңне-үзең якламый хәлең юк. Шуның өстенә, ничектер, замана үзгәрүгә карамый кешеләрнең үзара мөгамәләсе элеккечә кала бирә. Кайбер прозаиклар поэзияне тормыш арбасына тагылган нindидер дегет чиләге кебек күрә шикелле. Аларга ул нindидер буферный жанр сыман. Мин моңа һәрчак теш-тырнагым белән каршы чыктым. Чынлыкта поэзия – югары матдә! Прозаикларның күбесе, роман язганнары аеруча, мин дә иҗатымны шигырь язудан башладым, дип сөйләргә ярата. Шигырьнең бәясен кечерәйтәләр. Чөнки шигырьнең атрибутларын ритм, рифма дип кенә уйлый алар. Ләкин хәзерге вакытта шигъриятнең дәрәҗәсе артты. Чөнки шигърият заман белән бергә атлый. Шигырьне кимсетеп әйткән фикерләргә каршы заманында Хәсән ага Туфан болай язган иде:

Без – шагыйрьләр азгын кешеләр түгел,
Прозаиклар безнең азганнар.
Бездә әле проза язганнар юк,
Мирсәй, Хөсни, Гобәй һәм Минский
Аздылар һәм шигырь яздылар...

Монда ташның кем бакчасына төшкәне ачык күренә. Ә бит уйлап карасаң, шигырь элеккеге заман-

нардан бирле, – борынгы грек, рим шагыйрьләрен алыйк, – анда кайсын гына алма, аларның югары поэзиясе һәрвакыт җитәкче ролен үтәгән. Гомумән, ул дөнья әдәбиятында да шулай. Аннан соң шундый нәрсә бар әдәбиятта, әйтик, шагыйрь үзенең юлын тапкач, прозага күчә һәм прозада да билгеле күләмдә уңышка ирешә, роман яза. Һәм бераздан ул драматургиягә дә күчәргә мөмкин. Менә шундый каләм әһелләрен бездә, гадәттә, киң колачлы, киң пландагы язучы итеп күрсәтәләр. Ул шулайдыр да. Ләкин минем үземә бу үрнәк, дип әйтә алмыйм. Чөнки поэзия булгач, ул поэзия булсын һәм чын мәгънәсендә шагыйрьнең бөтен иҗаты, бөтен энергиясе дип әйтимме, барысы да поэзия юнәлешендә булырга тиеш, дип уйлыйм. Сүз җегәре ягыннан шигърият, әлбәттә, беренче урында.

Дания:

– Әгәр дә сез үткән юлыгызны кабаттан башласагыз, шушы юлдан, иҗат юлыннан китәр идегезме?

Роберт абый:

– Әлбәттә, бер дә икеләнмичә әйтә алам, бу мәҗүсилеккә якын халәт. Мин гомер-гомергә әрекмән, алабутага күмелеп, табигатьнең куенына сыенып үскән кеше.

Дания:

– Роберт абый, сез яшьләр иҗатына битараф түгел. Яшүсмерләр иҗатын тикшергәндә, һәрвакыт анда катнашып, үз фикерегезне әйтәсез. Күп кенә конкурсларда аларның тыйнак иҗатына бәяләмә биргәнегез бар. Сез аларны нинди күзлектән чыгып эш итәсез?

Роберт абый:

– Балалар әдәбиятында минем аз булса да өлешем бар, дип уйлыйм. Бер китап чыгардым, «Сабыйлар хоры» дип атала ул. Һәм язылa да тора бит әле. Хәзерге балалар вундеркинд бит алар.

Безнең замандагы балаларга охшамаганнар. Алар безгә караганда күбрәк беләләр. Ул вундеркиндлар киләчәкнең зур иҗатчылары, дип карыйм һәм шулай кабул итәм.

Дания:

– Татар поэзиясе саекмасмы икән, җебе өзелмәсме икән, сез ничек уйлыйсыз?

Роберт абый:

– Безнең заманда әле ул алай сизелми иде кебек. Хәзер, минемчә, яңарышка бара. Поэзияне күзәтеп барам, бигрәк тә кызлар бик тиз үсә башлады. Университет күп бирә аларны. Заманында, мәсәлән, безнең педагогия институтында көчле иде бу. Аннан иҗат әһелләре күп чыга иде. Хәзер университетның «Әллүки» берләшмәсе бар. Сокланам аларның шулай иҗатка килүләренә. Хәтта алардан көнләшеп тә куям. Әмма ләкин бернәрсә бар, без телне әйбәт белә идек. Әлбәттә, шул әремнәр, әрекмәннәр иленнән килгән тел байлыгы инде ул безнең төп байлыгыбыз.

Дания:

– Роберт абый, менә без сезнең белән «Каләм җиле» дигән китабыгызны кулыбызга алып куандык. Шигырьләр читтә калмадымы, алар языламы?

Робер абый:

– Аллага шөкер, языла. Мин төп эш итеп шигырьне саныйм. Әле мин әйтәм, Аллага шөкер, әлегә мичкәдә дары бар. Шуңа куанып йөрим.

Дания:

– Рәхмәт, Роберт абый, сезгә иҗат уңышлары теләп калам.

Бу интервью «Татарстан» радиосында 2008 елның 25 мартында «Татарстан дулкынында» тапшыруында яңгыраган иде. Күренекле шагыйрь Роберт ага Әхмәтҗанов шул ук елның 13 маенда бакыйлыкка күчте. Әлеге язма аның рухына дога булып ирешсен иде.

Язманы ***Дания Гайнетдинова*** *әзерләде.* ■

Гомерлек иман

Ләбиб Лерон

...Тукай йолдызына карап бардым, –
Гомер буена бер иман.
Гамил Афзал

Без бәләкәй чакларда авыл клубында концерт-тамашалар еш була торган иде. Актаныштан да, ут-күршебез Башкортстаннан да, тирә-юньдәге авыллардан да, хәтта Казанның үзеннән дә килә иде артист халкы. Әлфия Авзалова, Гөлшат Зәйнашева һәм Зиннур Гыйбадуллинның безнең өйдә чәй эчеп утырган чакларын да хәтерлим әле мин.

Шунысы аеруча истә калган: Гамил Афзал дигән шагыйрь абыйның һәр концертта диярлек нинди дә булса кызык-мызык шигыре, мәзәге-фәләне, сүзләре аныкы булган җырулары яңгырамый калмый иде: «Әсмабикә җаным, ахирәт», «Ир бала яхшымы, кыз баламы», «Юкка-барга», «Кызыл балчык» промартелендә», «Матриархат чорында», «Гөлмәрьям», «Өф-өф итеп...», «Дөнья матур, дөнья киң», «Татарстан таңнары» (Соңгы дүртесе – көйләрен Илһам Шакиров, Ренат Еникеев, Сара Садыйкова, Марс Макаров иҗат иткән җырлар)... Болар – исемдә калганнарның кайберләре генә.

Шушы концертларның да тәэсире зур булгандыр инде: иң беренче укыган китапларым Гамил Афзалныкылар иде. Театр артисты, репрессия корбаны Мохтар Мутин, җырчылар Әлфия Авзалова белән Хәнәви Шәйдуллин, скульптор Васил Маликов, драматург Риза Ишморат, фронтовик-шагыйрь Нур Баян, рәссам Әсгать Сәфәргалин кебек күренекле якташларым арасыннан беренче итеп, университетта укыганда чакта ук Гамил Афзал турында «Тукай буласым килә...» дигән мәкалә язуым да, аны районның «Игенче даны» газетасында (№30 (5130), 11 март, 1982 ел) бастыруым да, димәк, тикмәгә түгелдер.

Ни кызганыч, Гамил ага Афзал белән күрешеп-очрашып яшәргә туры килмәде. Әмма эш-вазифам (1986-1988 елларда СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры булган чагымны күздә тотуым) могтәбәр шагыйребез белән хат аша булса да хәбәрләштереп, аралаштырып торды, дия алам. 1988 елның 22 апрелендә көндәлек дәфтәренә мондый сүзләр язып куйганмын: *«Әлмәттән, Гамил абый Афзалдан хат алдым: «Хөрмәтле Ләбиб Лерон иптәш! Сезгә бер больничный лист җибәргән идем, 7 февральдән 10 нчы мартка чаклы. Менә соңгысы, 10 марттан 9 апрельгә чаклысы. Бәйрәмгә чаклы акчасын җибәрсәгез, яхшы булыр иде. Гамил Афзал. 9 апрель, 1988 ел»*.

Шул ук елның июлендә көндәлеккә теркәлгән икенче язу-хәбәр исә болайрак: *«Яшь ленинчы»ның хатлар бүлегеннән (Илгизәр апа Сәмигуллинадан) әдәбият-сәнгать бүлегенә (минем шунда кабат эшли башлаган гына чагым) хат килеп керде. Әлмәттән. Гамил Афзалдан. Нишләптер, язучы Солтан Шәмсигә адресланган:*

«Мөхтәрәм Солтан Шәмси!

«Яшь ленинчы»да катнашырга чакырасыз, балалар өчен яхшы китаплар язу – бик кирәкле, бик изге эш, ләкин ул эш бик күпләрнең кулыннан килми, дөньяга бала күзе белән карап, шаккатып, әсәрләнеп булмый, агайне.

Тырышып карарга кирәк. Менә берничә шигырь җибәрәм, шуларны бастырып чыгарсагыз, тагын да тырышырмын, боерган булса.

Сезгә сәлам вә ихтирам белән, Гамил Афзал. 10 июнь, 1988 ел. Әлмәт».

Гамил абыйның әлеге шигырьләрен газетада бастырганыбыз әле дә истә.

«Ул әдәбиятка үзеннән шактый алда кергән кайбер өлкән буын шагыйрьләренә караганда да үзенең укучыларын тизрәк тапты. Сәбәбе: шагыйрьнең талантлы булуында», – дип язган иде заманында шагыйрь иҗатына беренчеләрдән булып игътибар иткән остаз-әдип Сибгат ага Хәким «Мин чәчәкләр җыям» дип исемләнгән мәкаләсендә. Соңрак язган «Шагыйрь юлы» дигән язмасында исә ул таланты ташып торган шәкертенә һәм аның иҗатына мондыйрак бәяләмә бирә: *«Гамил Афзал башта ук, беренче шигырьләреннән үк, җиргә ябышты. Икенче ныклап ябышкан объект – Тукай. Тукайчылык Гамил Афзал иҗатының рухында. Рухы аның бөтен шигырьләренә сибелгән. Тукайдан күчкән иң әйбәт сыйфат – дөреслек, турылык, иман».*

Остаз янә дәвам итеп болай ди: *«Гамил Афзал һәм лирик, һәм сатирик. Бер җан, бер йөрәк, бер иҗат. Икесе бергә кушылганда, шагыйрь җаны бөтен почмаклары, бөтен үткен кырлары белән ачыла».*

Әйе, Гамил Афзал – халыкның моңаһәңнәрен үз йөрәге аша үткәреп, барлык кайнар хис-фикерләрен, мәгънәле сүзләрен гади, үтә халыкчан итеп әйтә белгән шагыйрьләребездән берсе. Аның күпчелек шигырьләре гади кешене олылаудан, җир кешесенең бәхетенә, шатлыгына дан җырлаудан гыйбарәт:

Кеше – даһи тереклекнең тәрәге ул,
Мәңгелекнең иң кадерле бүләге ул.
Табигатьнең миллион еллар
сайлап-сайлап
Чарлый торган
нәфис сәнгать үрнәге ул.

Шулай да, лирикасыннан битәр, миңа Гамил аганың сатирасы, юморы аеруча якын. Шушы өслүптә язуына ишарәләп, иҗатының шушы ягына аеруча басым ясап, егерме биш яшьлек мин бахырыгызның, «Гамил Афзалга», дип эпиграмма язуы да (1986), уйлап караганда, юкка түгелдер сыман:

«Кәгазь кортлары»н да тетә Афзал,
Түрәкратларны да тетә Афзал.
Читтә калмый хәтта
куштаннары...
Әллә аңа өстән кушканнармы?

Чын юмористларның, сатирикларның күбесе, гадәттә, үзенә кагылган җиңелчә генә «чеметтеризм»нарны да күтәрә алмый. Бу уңайдан миңа карата Гамил Афзалдан ул-бу сизелмәде, әдип үпкәләгән икән, дигән хәбәр ялгыш та минем тарафка килеп ирешмәде.

Юмор-сатираны югары кимәлдә язуы өстенә, аның үзенә кагылганын кабул да итә белүе – бу үзе үк шәхеснең үтә талантлы икәнлегенә, шул талантның никадәр зур булуына бер ишарә-дәлил түгелме икән әле?!

Үзенә нисбәтле түбәндәге пародияне дә Гамил ага бик җиңел кабул иткәндер, дип уйлыйм. Бер шигыреннән «Архимедлар утыра күңелдә» дигән юллары эпиграф итеп китерелгән ул пародия «Урындык» (1996) дип атала:

Күңелемне куйган идем бикләп,
Ачкач – шаклар каттым үзем дә:
Аякларын җайлап кына бөкләп,
Архимедлар утыра күңелдә!

Сократ йөри кулын артка куеп,
Яланаяк килеш йөренә...
Аристотель ята изрәп-оеп,
Күңелемнең җылы түрендә!

Маркс үзенең «Капитал»ын укый,
Ньютоннар сагыз чәйниләр...
Беркем дә юк монда букый-сукый,
Барсы – даһи, барсы – генийлар...

Минем күңел әйтерсең лә вокзал:
Ыгы-зыгы... Тавыш... Урын юк...
...Пәйда булды шулчак Гамил Афзал
Һәм сузды ул миңа урындык.

Заманында Гамил ага Афзалның тәүге шигыре басылуы турындагы бер истәлеге күз яшьләре аша көлеп язылган булуы белән минем күңелемне бик нык тетрәндергән иде:

«Яшь вакытта салкын баракларда торуларның нәтиҗәсе буларак, минем тез буыннары, бот буыннары авырта башлады. Педтехникумның беренче курсын бетереп, икенче курска күчкәч, мин Магнитогорскига кайтып, озак кына больницада яттым. Ревматизм, диләр. Шуннан бирле партага утырып сабак укулар насыйп булмады. Магнитогорскиның металлургия комбинатында кара эшче булып, такелажчы булып эшли башладым. Шаярмагыз минем белән, мин хәзер – эшче класс!

1939 елның җәендә бәхет миңа да бер елмайды. «Азат хатын» журналында бер шигырем басылып чыкты тәки. «Гамил Афзал», дип язып куйганнар. «Амур буенда» исемле. Винтовканы кулга бик нык кысып, илне самурайлардан саклап торам, керфек тә какмыйм, имеш. Матбугатта үз исемеңне бер күрү дә кешене канатландырып җибәрә икән. Мин дәртләнеп киттем. Инде Тукайга җитәргә дә күп калмады кебек. Катыргы белән тышлап, беренче битенә фотокарточкамны ябыштырып, бик матурлап, бизәп язган шигырь китапларым дүртәү булды.

«Сугыш башланган» дигән афәтле хәбәрне ишетүгә минем исем китмәде. «Башланса ни, – дип уйладым мин, – без аларны, фашистларны, «урра» кычкырып кына кирәкләрен бирербез әле, алар акылга утырып кайтып китәрләр, харап икән...» Халык бик шомланды, фронттан күңелсез хәбәрләр килеп тора. Эш тә эш, мин миңгерәүләнеп, берни аңламас булдым. Нигә «урра», дип кенә, ялтыр кылычларны айкап-чайкап куып җибәрмиләр икән аларны?

Көненә уникешәр сәгать эшлибез, артыграк та туры килә, ял көне дигән сүз онытылды. Ял итәр вакыт түгел. Көн саен ике эшелон корыч китә, ә сугышның очы-кырые күренми әле. Карандаш буе нечкә снарядтан башлап, эченә кеше кереп ятарлык бомба кабыкларын көне-төне чүкибез – Чапаев кайда да, Тукай кайда! Без усалландык, җитдиләндек, безгә ирләр акылы кирә башлады. Дөнья кыйнап та өйрәтә икән ул...»

Әйе, алда әйтелгән әлеге өзектән дә бик ачык чамаларга мөмкин: шулчакта ук Гамил Афзалның кыйбласы Тукай булган.

Тукай – Гамил Афзалның гомерлек иманы:

Илдә туган ил улы син,
илдә яндың нур булып,
Ил күгендә яз идең син,
илдә калдың җыр булып.

Илне яклап яуга чыктың,
ил телендә изге син,
Аңлы иттең, җанлы иттең,
данлы иттең безне син.

Ил йөзендә күз идең син,
ил уенда аң булып,
Кичләрендә моң буласың,
көннәрендә таң булып.

1966 елда Тукайга багышлап язылган әлеге шигъри юллар татар халык шагыйре Гамил Афзалның үзенә дә бик туры килә.

24 гыйнвар, 2016 ел ■

Тетрәндереп киткән алиһә!

Рәдиф Сәгъди

Дамирә Кузаева – үткән гасырның алтмышынчы елларында театр сәхнәсендә пәйда булган олуг талантларыбызның берсе. Әлмәт дәүләт театрына ул 1964 елда, мәктәпне тәмамламаган килеш килеп керә, унынчы классны читтән торып укый. Театр белән саташкан кызда тыелгысыз дәрт ташый. Аны сәхнә кысаларына кертү кыен булачагын аңлап алган баш режиссёр Габдулла Йосыпов бераүгә дә, шул исәптән яшьләргә дә, буразнадан чыгарга, эленке-салынкы йөрергә мөмкинлек бирми.

Сәхнә эшенә тугры калып, җигелеп иҗат итәргә өйрәтә, хәтта мәҗбүр итә. Чөнки актёр эше зур тәрбиялелек, бирелеп эшләүне таләп иткән, нык тәртип сорый торган четерекле һөнәр – иләс-миләс йөрүне, кайбер үзешчән сәнгатьтәге кебек эленке-салынкы карашны, иҗатка җитди карамауны күтәрә алмый. Профессиональ театрның кануннары бик кырыс һәм ул һәрбер актёрдан эшләгән иҗатына тулысынча буйсынуны сорый. Габдулла Йосыпов та, соңрак килеп эшләгән Гали Хөсәенов та бу мәсьәләгә килгәндә чын профессионаллар, бик таләпчән сәнгатькярләр иде. Яшьләрне дә йөкне төптән тартып баручы, чын фидакярьләргә янәшә куеп, мичәүгә җигә торган булалар, Дамирәгә дә, театрга килгән мәлдә үк, ул чакта әйдәп баручы «Ләлә апаң Садыйкованы ял иттерергә кирәк», диеп, «Кияүләр» спектакленә, сынау йөзеннән, аның урынына Софья роленә китереп кертәләр. Сирәк-мирәк кенә уйнарга туры килсә дә, бу рольдә кыз үзенең табигый сәләтен күрсәтеп өлгерә, ышаныч казана, тиздән аңа аерым образлар иҗат итү мөмкинлеге тудыралар. Шул рәвешле, «Ак калфак»тагы Гафия, «Көзге ачы җилләрдә»ге Рәҗәп, «Зәңгәр шәл»дәге Малай рольләре аның профессиональ иҗатындагы тәүге эшләре була. Ул, тора-бара, театр сәнгатен әле төбеннән аңлап бетермәвен, сәхнә кануннарына тулысынча төшенмәвен дә сизеп ала. Актёрлык осталыгын, сөйләм культурасын күтәрер өчен укырга кирәклеген аңлап алган кыз Казан театр училищесына белемен күтәрергә китеп бара. 1966 елда биредә Рифкать Бикчәнтәев, Марсель Сәлимҗанов кебек режиссёрларда дәрес ала башлый. Дамирә Кузаева театр училищесына шактый гына актёрлык осталыгы туплаган шәкерт буларак килеп керә. Күпчелек очракта кайдадыр, ниндидер өйрәнү алган абитуриентларны: «Төзәтеп булмый, йә булмаса үзгәртергә кыен булачак», дип укырга алмыйлар иде.

Дамирә Кузаева (сулда) сыйныфташы белән. Төнгүк авылы. 1960 нчы еллар

Ә Дамирәне театр сәнгатенең даһие Марсель Сәлимҗанов сыгылмалы зифа гәүдәсенә, тибрәнебрәк чыккан тембрына, татарның классик йөзен чагылдырган төс-битенә сокланыптыр инде, укырга чакыргандыр, күрәмсең.

«Уку йортына Дамирә инде әзер актриса буларак килеп керде. Чөнки ул Әлмәт дәүләт театрында эшләп, ул чактагы баш режиссёр Гали Йосыпов ачкан студиядә дә белем алырга өлгергән икән. Уку чоры башланып, этюдлар эшләргә тотындык. Дамирә, үзенең әзерлеген күрсәтеп, безне шаккатырды. Кулына утын пүләннәре күтәргән ханым, ишектән килеп керә дә, аягы белән генә этеп аны яба, күтәрелеп караса, югалган ире кайткан икән! Кулындагы пүләннәре идәнгә коела, ике бите буйлап күз яшьләре ага, безгә бу этюд нык тәэсир итте, тетрәнү кичердек, әле бит беренче курста гына укый идек», – дип искә ала соңыннан Фирдәвес Хәйруллина, үзенең ахирәтен сагынып.

1970 елның яз көннәрендә укуын тәмамлаган Дамирәнең талантына зур бәя биреп, М.Сәлимҗанов аны Г. Камал театрына эшкә калырга чакыра. Әмма Д.Кузаева, аны Әлмәт театры ышанып укырга җибәргән икән, аларның өметләрен акларга тиешмен дип, кире Әлмәткә кайтып китә. Әллә язмыш, әллә ялгыш!.. Мин белгән Дамирә Нәҗмиҗан кызы да намуслы, үз сүзен тота белүче шәхес буларак күңелгә кереп калды.

Дамирә Нәҗмиҗан кызы Пермь өлкәсенең Барда районы, Төнгүк авылында 1948 елның 16 маенда дөньяга килә. Табигать яшелгә төренгән, алмагачлар чәчәк аткан чорда туа ул. Аның сәхнә иҗаты да ямьгә төренгән табигать, ап-ак чәчәккә күмелгән алма бакчасы кебек иде. Актрисаның иҗаты искитмәле, киңкырлы! Театр училищесын бетереп кайтуга яшь кызга тиз арада җаваплы рольләр тапшыралар, эшли башлавының беренче көннәрендә

үк Ибраһим Абдуллинның «Их, Уфа кызлары»нда төп рольне – Майя (Маһитап) ролен тапшыралар. Шуннан башлап Дамирә Кузаеваның исеме туксанынчы елларга кадәр тамашачы теленнән төшми. «Әни килде»дә – Гөлчирә, «Тальян моңы»нда – Тәнзилә, «Трибунал»да – Надя, «Минем җинаятем»дә – Илүсә, «Кайда күрдем мин сине»дә – Нила Снежко, «Тылсымлы кыз»да Мирандолина, «Антигона»да – Антигона кебек төрле характердагы төп рольләр тезелеп китә аның иҗат биографиясендә. Дамирәнең уенында образга кереп китү, русчалатып әйтсәк, «воплощение» шундый тирән була иде ки, замандашлары бу турыда: «Чыңгыз Айтматовның «Анам кыры»нда Дамирә үзен каһарманы Алиман итеп сизә башлый, әсәр буенча каһарманы үлеп кала. Дамирә дә сәхнәдә һушсыз егыла, хезмәттәшләре аны көч-хәл белән аңына китерәләр. Шул хәлдән соң, байтак еллар үткәч тә, Алиман турында сүз чыкса, аның йөзендә сәер үзгәрешләр барлыкка килә торган була. Алиман ролен ул искиткеч итеп башкара ки, аны инде бу дәрәҗәдә бүтән беркем дә кабатлый алмый. Вәләкин актрисага тәмам танылуны шушы спектакльдәге Тулганай образы алып килә. Анысын инде җиде елдан соң яңадан 1977 елда куелгач уйный. Дамирә башкарган Тулганайның яшьлек дәртендә, олы җаваплылык хисен дә, ачы хәсрәтен дә үз йөрәге аша тамашачыга җиткерә, караучыларны әсир итә. Артистканың тугрылыклыгы, хезмәтенә зур ихтирам белән каравы Дамирәгә дан, шөһрәт алып килә. 1976 елда ук Кузаева яшь талантларның Республика конкурсында зур уңышка ирешә – беренче урынны ала. Шуннан соң озак та үтми, аңа «Татарстанның атказанган артисты» дигән исем бирелә. Тагы бер елдан яшь талант иясе яшь артистларның Бөтенсоюз конкурсында да җиңү яулый. 1979 ел исә аның өчен аеруча истәлекле – Туфан Миңнуллинның «Ай булмаса, йолдыз бар» спектаклендә – Мәдинә образы өчен ул Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек була. Ә тагын биш елдан исә аңа «Татарстанның халык артисткасы» дигән зур исем бирелә. Болар барысы да Дамирә Кузаеваның чын талант иясе икәнлеген рәсми тану булып тора. Кыскасы, Дамирә Нәҗмиҗан кызы Әлмәт дәүләт театры сәхнәсендә күп еллар буена якты йолдыз булып яна. Ләкин аның иҗаты рольләр уйнау белән генә чикләнмәде. Без эшләгән чорда актриса Гали ага Хөсәенов җитәкчелегендә режиссёрлык белән шөгыльләнә башлаган иде инде. Аның бу һөнәренең дә киләчәге бик зур, өметле иде. 1980 елда Мар Бәйрәмовның «Кияү белән кәләш» пьесасын сәхнәләштерә. Рөстәм Мингалимовның «Өченче бүлмәдә эт яши» драмасын безнең күз алдында куеп, уңай бәя алды. Төрле юллар, мәкерләр белән, баш режиссер булган бер адәм чорында аңа рәтле-башлы рольләр дә бирелмәде, читкә кагылды, спектакльләр дә куйдыртмадылар. Хәлбуки, баш режиссер эшеннән алынып, бөтенләй киткәч кенә, иҗат итү мөмкинлекләре аңа кабат тудырылды. Җитәкчесез калган Әлмәт театры... Ташкент каласында яшәп, сугышта алган яраларына дәва булган сихәтле көньяк һавасын сулап яткан Гали ага Хөсәеновны яңадан эшкә чакыра. Гомер бакый театр белән хыялланып яшәгән күренекле режиссер, Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, өлкән яшьтә булуына да карамастан, коллективын сагынып яңадан театрына кайта һәм җиң сызганып эшкә керешә. Туздырылган театр йорты, әкрен генә җайга салына башлый. 1990 елда эшкә кайткан бөек режиссер бер-бер артлы яңа

әсәрләр куя башласа, яшь һәм урта буын вәкилләренә дә режиссерлыкта үзләрен сынап карау мөмкинлекләрен тудыра. Шул исәптән театрның алиһәсе Дамирә Кузаева М.Байҗиевның 1991 елда «Назлап юатыр идем» драмасын, 1992 елны Данил Салиховның «Алла каргаган йорт»ын сәхнәгә чыгара. Әлмәт татар дәүләт драма театры 80 нче елларның урталарында кичергән авыр кризистан соң, көндәлек матбугатта: «Әлмәт театры бетте, ул үлеп бара», «Анда адәм рәтле режиссёр да, артистлар да юк», дигән авыр тәнкыйтьләр Гали Хөсәенов, Дамирә Кузаева, Камил Вәлиев, Луиза Солтанова, Роза Салихова, Фоат Зариповлар кабат җиң сызганып иҗат итә башлагач, үзеннән-үзе юкка чыга. Затлы әсәрләрне сәхнәләштерү өчен бөтен мөмкинлекләр дә ачыла. Язмыш күренекле актриса белән шәхсән үземне 1981 елның март аенда беренче тапкыр күрештерде. Без дигәнебез, ул яңа гына театр училищесын тәмамлап, бөек режиссёрыбыз Гали Хөсәеновта эшләп алырга хыялланган, шул сәбәпле Казаннан провинциягә китеп барган – Николай Юкачев, Раушания Хафизова, Рәис Галиев, мин һәм тагын өч-дүрт кеше иде. Исәбебез – зур остаздан белем, практик тәҗрибә алып калу. Шулай итеп, безне бәхет басты. Гали ага бөтен белгән белемен, дистә еллар буена туплаган тәҗрибәсен, ару-талуны белмичә, безгә тапшыра башлады. Ул чагында инде Луиза Солтанова, Камил Вәлиев, Дамирә Кузаевалар театр сәхнәсендә азу тешләрен ярган, дан казанган актёрлар иде. «Менә кайда икән бит чын иҗат, театраль лаборатория. Нишләп безгә театр училищесында ук бирмәделәр икән бу белемнәрне?», диеп, аптырап калдык. Баш режиссёр көнгә ике генә сәгать репетиция ясый. Шуңа карамастан, унбиш-егерме көн эчендә гаҗәеп югары дәрәҗәдәге әсәрләр чыгара. Могҗиза түгелме соң бу?! Гали ага үзе дә: «Актёрның баш мие мәгълүматны ике-өч сәгать кенә кабул итә ала, янә дә ялыктырсаң, булганын да югалтырга мөмкин», – дия иде. Тик репетиция моның белән генә бетми әле – Әлмәт театрының традицияләре буенча, ял итеп алгач, яшь, тәҗрибәсез актёрлар тагын бер-ике сәгать остазлар белән дә сәхнәдә эшләргә тиеш. Шул сәбәпле барыбызга да «наставник»лар билгеләп чыктылар. Приказга күз салсам, минем остазым Дамирә Кузаева үзе булып чыкты. Куркуга калдым! Танылган, әле яңа гына Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе алган актриса мине сәхнәдә өйрәтәчәк?! Таләпчән, максатчан, өстәвенә бала-чагасы да булмаган япь-яшь ханым (әле аңа ул чакта 33 кенә яшь иде), үтерәчәк икән мине сәхнәдә тинтерәтеп, дип уйлыйм. Театр һәм тулай торак бер түшәм астында булу сәбәпле, өстәмә репетициягә өченче каттан беренчесенә генә төшәсе. Минем хәлне күреп, якын дусларым Гөлүсә Җамалиева белән Символ Гайнетдиновлар (ир белән хатын): «Әй җүләр, шатлан, аның кул астында эшләсәң, соңыннан рәхмәтләр әйтеп туймассың әле», – дип мине тынычландыралар. Шулай итеп, Әлмәт театрының алиһәсендә өстәмә тәҗрибә ала башладым. Остазларым Г. Хөсәенов һәм Д. Кузаевалар миңа ике ел эчендә зур театр мәктәбен тәмамлаттылар. Куркуларым да юкка гына булган икән: Дамирә ханым, таләпчән булса да, кирәк-кирәкмәгәнгә интектерми торган иде. «Рәдиф, репетициядән соң бар, ял итеп ал, ашап-эч тә, кичке дүрттә сәхнәдә көтәрмен мин сине», – дип, эшкә чакыра торды. Аннан: «Озак газапламам, әле кызлар янына да барасың бардыр», – дип, җайлап кына елмаеп, өстәп куяр иде.

Беренче репетицияләрдә кыенрак булса да, тора-бара остазымның ни теләгәненә тиз төшенә башла-

«Их, Уфа кызлары» (И.Абдуллин)

дым, эшләр уңайга китте. Тик мактау сүзләре генә ишеткәнем юк, димәк, мөгаллимәмне минем уен канәгатьләндерми?!

Көннәрнең берендә җан дустым Символ Гайнетдинов: «Акчасы да күп, фатир да вәгъдә итәләр», – дип, театр администрациясенә «шок» ясап, милициягә эшкә китте. Аяз Гыйләҗевнең «Өткәй җылый да, җырлый да» дигән әсәрендәге агроном Сөнгать ролен миңа тапшырдылар. Аны инде, Символдан кала, тагын ике-өч кеше уйнап караган булган икән. Кузаева бу спектакльдә дә – төп сәхнәдәшем, үзе белән репетицияләр үткәрде дә, гастрольгә алып чыгып китте. Әлки, Аксубай, Чистай якларын әйләндек. Сәфәрдән кайткач, ахирәте Гөлүсә Җамалиевага: «Сөнгатьне Рәдифтән дә яхшырак уйнаучы кеше булмады», – дигән. Әлбәттә, яңа гына эшли башлаган 21 яшьлек артист өчен зур бәхет тә, зур бәя дә иде бу! Дамирә апа үзе шулай дисен әле! Ләкин безнең бәхетле иҗат чоры озакка сузылмады. Гали ага өстеннән элегрәк искәртеп киткәнемчә, әләк Әлмәт администрациясенә, Казанга – обкомга, министрлыкка агылып торган икән. Шундый яла язылган хатларның берсенә кул куйдырырга дип, ул адәм минем бүлмәгә дә кичкырын килеп керде. Сандугач булып сайрады... «Театрны үзгәртергә кирәк, ул яшьләр кулына калырга тиеш, менә монда барысы да язылган», – дип шактый гына озын «донос» хаты чыгарды. Казан-Әлмәт түрәләренә юллама икән. Укып карасам, сискәнеп киттем, анда Гали Кәримович өстеннән дөреслеккә гомумән туры килмәгән төрле гайбәт сүз, яла язылган иде. Мин нәфрәт белән бу мәкерле бәндәне куалап чыгардым. Ләкин кул куючылар барыбер табылган икән, күпчелеге – ялагайлар һәм осталыклары чамалы булган бәндәләр иде. Бу мәкерле җан иясе белде микән соң аның җитәкчелегендәге труппа ике-өч елда түбәнгә тәгәрәячәген, яхшы артистларның, шул исәптән Дамирә Кузаеваның да, рольләрсез калдырылып, хәлбуки төп рольләрне уйнауны үзенең хәләл җефетенә тапшырып, адәм мәсхәрәләренә калачагын, соңрак Әлмәт театрыннан куылача-

«Анам кыры» (Ч.Айтматов) – Тулганай

гын?! Белмәде, әлбәттә. Белгән булса, көчле шәхес артына ябышып, әле дә кеше булган булып йөргән булыр иде, ярый әле әлеге мөртәт бәндә ул елларда Татарстан җирлегендә үзенә эш табалмагач, чит өлкәгә чыгып качты...

Ни өчен бу күңелсез, фаҗигаи хәлләрне сезгә дә җиткерәм соң? Чөнки Дамирә Кузаеваны фаҗигагә китерәчәк вакыйгаларның башы иде бу. Шулчагында иҗатта каешланган, исемнәр алган кайбер актёрларның битарафлыгы хөрәсән адәмнәрне театр җитәкчелегенә китерде.

***

...Инде барысы да җайга салынды, дигәндә генә, күпме рәнҗетелүләр күргән, ятьмәгә эләккән сайрар кош кебек чәбәләнгән Дамирә Кузаева 1993 елның декабрендә үз-үзенә кул салган дигән хәбәр, татар җәмәгатьчелегенә аяз көнне яшен суккан кебек тәэсир итте. Үз-үзенә кул салырлык сәбәпләре юк иде инде аның бу чорда. Ул әлегә хәтле ачылып бетмәгән, рәтле-башлы тикшерелмәгән сәбәпләр белән, якты дөньядан китеп тә барды. Колактан-колакка, телдән-телгә күчеп, имеш-мимешләр генә йөреп алды. Аллаһы Тәгалә үзе хөкемдар безгә, җир җимертеп эшләп йөргән Дамирәбез һәммәбезне тетрәндереп, гомерен чикләде. Ул елларда Төнтек мәктәбендә директор булып эшләгән абыйсы, артык тикшерү эшләренә кысылмыйча, Әлмәт дәүләт театрының «алиһәсе» Дамирә Нәҗмиҗан кызын кендек каны тамган туган җиренә алып кайтып җирләде, иң фаҗигале юлларның берсен үткән сәнгать даһие, әти-әнисе яткан җирдә тынычлык тапты. Ләкин аны якыннан белгән кешеләрне, шулай ук Әлмәт театры коллективын да бүгенге көнгә хәтле ул эшләгән калада, үзенең туган төбәге Бардада берәр урамга аның исеме бирелмәве нык борчый. Әле, Рәшит Ягъфәров исән чагында ук, Пермь якларына кайткан саен, бу мәсьәләне күтәрә килдек. Бүгенге җитәкчелеккә дә үтенечебез бер генә: Дамирә Кузаеваның иҗади мирасы, зур иҗаты мәңгеләштерелергә тиеш! ■

НУРИХАН ФӘТТАХ

(1928-2004)

«Безнең мирас» журналының 2016 елгы беренче санында Рүзәл Мөхәммәтшаның «Кояш кына күктә мәңге йөзәр» дип аталган мәкаләсе басылды. Шул ук санда Һади Такташның соңгы көннәре турында истәлекләр һәм шагыйрьнең фотосы урын алган. Автор тарафыннан «Үлем белән дә күренеклеләребез дөрес яшәү өлгесен күрсәтергә теләгән түгелме соң?» дигән сорау куела һәм «Безнең мирас» журналы яңа сәхифә башлап карарга ниятле, дип тә өсти.

Мин, журналның даими укучысы буларак, мондый сәхифә ачылуга сөендем. Онытылмасын татарның чын татары, журналның исеме үк «Безнең мирас» – үзебезнең тарих бит! Мәкалә авторы: «Безгә, исәннәргә, аларның үлеменнән дә сабак алырга кирәкми микән?» – дигән сорау куя. Мин үзем: кирәк, дигән фикердә торам. Дөресен әйткәндә, бу сәхифәне моннан 12 ел элек башлап та җибәргәнмен икән инде. Нурихан Фәттах вафатыннан соң 40 көн узгач, «Татрстан яшьләре» газетасы үтенечен канәгатьләндереп, «Нурихан исән» дип аталган зур гына мәкалә язган идем («Татарстан яшьләре», 16 март, 2004 ел).

Нурихан Фәттах

Якын кешеңнең соңгы көннәре, соңгы сүзләре, ничә ел үтүгә карамастан, күңелгә уелып кала, онытылмый. Бу язмамда газетага әзерләгән мәкаләгә керми калган кайбер детальләрне генә яктыртасым килә.

Язучы Н.Фәттах белән 43 елга якын гомер иткән кеше буларак, аның

гадәтләрен, холкын миннән дә яхшырак белүче юктыр, дип уйлыйм. Соңгы айларда, авырый башлагач, аның яшәү рәвеше үзгәрдеме, үзгәрсә, ни-нәрсәдә күренде ул?

2003 елның 19 апрелендә Нуриханның бүсере кысылды. Моңа кадәр дә булгалый иде бүсер чыгулар, тик ул аны ипләп кенә үзе җайлап урынына кертә торган иде. Бу юлы әллә ничә сәгать вакыт узды, юк, булмый. «Ашыгыч ярдәм» чакырттым. Үзе киреләнеп маташса да, ныклап аңлаткач һәм авыртуга түземе беткәч, операциягә ризалыгын бирде. Бер атнадан хастаханәдән чыкты. Ләкин шул көннән башлап мантымады ул тазалыкка: ябыкканнан ябыга барды, хәлсезләнде. Димәк, 10 ай буена кеше авыру, ләкин бер генә көн дә урын өстендә ятмады, зарланмады. Бу вакыт арасында иң күзгә чалынганы – бик җитди, ашыга, бөтенләй диярлек сөйләшми, юк-бар хәбәргә битараф. Телефонга чакырсалар, трубканы мин алам. Эшсезлектән аптыраган фәлән кеше булса, төрлечә хәйләләп, өйдә юк иде шул әле, кебек сүзләр белән трубканы куям. Кем шылтыратуы белән кызыксынмый да. Соңгы елларда, инде бераз дан килгәч, бигрәк тә Тукай премиясе комиссиясендә икәнен белгәннәр еш шылтырата, эшеннән бүлә иде. Күренекле генә кешеләр аңа үзләренең «ихтирам»нарын белдерергә тырыштылар. Исемнәр атап торуның кирәге юк, үткән эшкә – салават... «Комачаулама, вакытым аз калды», дигән сүзләрне соңлабрак аңладым шул. Хәер, нишли ала идем соң? Хатыны буларак аны караучы, табиб буларак дәвалаучы ролен дә җиренә җиткереп үтәдем, дип юаныргa гына кала. Дөрес, участок табибы әледән-әле өйгә килеп, хәлен белеп торды.

Табиб белән үзен тыныч тотты Нурихан, елмаеп сөйләште, зарланмады. «Бер җирем дә авыртмый, хәлем генә юк», – диде. 2004 елның 15 гыйнварендә бик авыраеп калды. Иреннәре көйде, тиресе бик юкарды. Мунчада бәби юган кебек йомшак чүпрәк белән генә юа идем. Шул көнне нотариус чакырырга кушты. Мин аптырап калдым, чөнки инде 5-6 ел элек үк бөтен булган акча, йорт-җирне минем исемгә күчергән иде. Нигә кирәк нотариус, дип сорамадым. Теләген үтәргә кирәклеген генә аңладым. Нишләргә? Балалар эштә (алар болай да аерым яшиләр иде), бу килеш авыруны ташлап чыгып китеп тә булмый. Машиналы күршеләр берсе дә өйдә юк. Тоттым да Лима Кустабаеваның эшенә шылтыраттым. Зирекне сорадым. (Ул елларны Лиманың ире Зирек Йосыпов та «Сәйдәш» культура сараенда эшли иде.) Хәлне аңлаттым. Берничә минут узуга, уллары Тимур килеп тә җитте, нотариусны алып килде, эше беткәнче көтеп торып, илтеп тә куйды. Мондый изгелекне ничек онытасың?! Нотариус Нуриханга авторлык хокукы турында минем исемгә васыять язарга кирәк, дигән булган икән. Җай чыгудан файдаланып, ТРның халык артисты, тыйнак якташыбыз Нәфкать Нигъмәтуллинга да олы рәхмәтемне җиткерәсем килә. Инде нык хәлсезләнгән, авыру Нурихан абыйсын 75 еллык юбилей кичәсенә үзенең җылы машинасында җил-яңгыр тидермичә Нәфкать йөртмәсә, бара алыр иде микән Нурихан ул соңгы тантанага?

17 февраль көнне көндезге сәгать өчләрдә безгә Президент Аппаратыннан Нурия туташ Һашимова килде. Көн бик салкын иде. Сеңелкәшнең битләре кызарган, үзе бик чибәр. Өс-башын чишенеп, Нурихан яткан бүлмәгә керде, хәлен сорашты, матди ярдәм – акча алып килгәнлеген әйтте. Мин икенче бүлмәдән Нуриханның бу кызга комплимент әйткәнен ишеттем. Нурия туташны озатып җибәргәч, Нуриханнан сорадым:

Н.Фәттахның соңгы фотосурәтләреннән берсе. Язучының хатыны Р.Фәттахова җырчы Гөлзадә Сафиуллинага үз куллары белән әлеге сурәтнең артына болай дип язып биргән: «Хөрмәтле яраткан Җырчыбыз Гөлзадәгә Нурихан Фәттахның 75 яше тулу уңаеннан үткәрелгән иҗат кичәсенең бер истәлеге. Кичәдә катнашуыгыз өчен, авыру авторны шатландыруыгыз, әлеге җырыгыздан башка да җылы сүзләр әйткәнегез өчен мең-мең рәхмәтләр Сезгә, Гөлзадә ханым! Чиксез ихтирам хисе белән – Руфина Фәттахова. 17 ноябрь, 2003 ел. К.Тинчурин театры».

– Син юньләп күрдеңме соң ул кызны, күңеле булсын өчен генә мактадыңмы? – дип сорадым.

– Матур хатын-кызны күрерлек кенә хәлем бар әле, – диде ул, елмаеп.

Шуннан ярты чынаяк чамасы шулпа эчте, гомер эчмәгән кофе сорап эчте. Бик озак сөйләштек, дөресрәге, сәгатьтән артык ул сөйләде. Балалык елларын, күршедә генә яшәгән Урта бабай турында яратып, сагынып, сагышланып сөйләде. Йокыга китте. Бүтән көннәрне дә көндез берничә мәртәбә черем итеп ала иде, мин аның бүтән уянмаячагын башыма да китермәдем...

Җылы өйдә, үз кулымда җан бирде. Шулвакыт, «ярый әле ирексезләп хастаханәгә салмаганмын», дигән уй килде.

Язманы ***Руфина Фәттахова*** *әзерләде.* ■

Әтине бер күрдем... төшемдә...

Әнвәр Шәрипов

Без – кырык беренче ел балалары. Минем әтине бер тапкыр да күргәнем юк. 1941 елның июль башында ул сугышка киткәндә мин әле тумаган булганмын. Ул китеп өч ай үткәч туганмын. Шул китүдән әти кайтмаган. Әнинең сөйләве буенча, аны башта Суслонгерга җибәргәннәр. Аннан аның ике хаты килгән (әмма ул хатлар сакланмаган). 1942 елда язган соңгы хатында ул: «Безне фронтка җибәрәләр», дип язган булган. Миңа шулай сөйләделәр: эшелон белән Сталинград фронтына барганда, Саратов тирәсендә булса кирәк, әтиләр утырган поездны һавадан бомбага тоталар. Шулвакытта әти һәлак булган булса кирәк, әнигә бары «Хәбәрсез югалды» дигән хат кына килгән. Соңыннан эзләтеп тә карадык, ләкин әтинең язмышы төгәл генә ачыкланмады әлегә.

Без, сугыш чоры балалары, сугыштан соңгы ач-ялангач еллардагы «Лаеш шулпасы»н артыгы белән эчтек, сыгылып төшмәдек, кәлҗемәләр ашап булса да, исән калдык. Шуннан соң күп еллар үтте. Без үсеп җиттек. Мин инде, өйләнеп, үзем әти булдым. Яшем ярты гасырдан да узып китте. Һәм менә бервакыт, 2002 еллар тирәсендә мин төш күрәм. Аннан соң да инде күпме вакыт узды, ә ул төш һаман хәтердә. Хәзер мин сезгә шуны сөйлим.

Мин Чаллыда яшим икән. Бервакыт иртән Яңа шәһәрдәге Тынычлык проспекты буенча ГЭС бистәсенә таба барам. Вахитов проспекты белән кисешкән күпергә җиттем. Карасам, Вахитов урамын тутырып, капма-каршы ике якка да халык агыла. Халык шулкадәр күп, бер-берсенә тыгызланып баралар. Бөтен машина юлын тутырганнар. Минем Санкт-Петербургта булганым бар иде: анда Нева проспектында Публичный китапханә янындагы җир астыннан чыгу юлында һәрвакыт халык ташкыны була. Вахитов урамындагы халыкның күплеге миңа шул күренешне хәтерләтте. Күпергә килеп кердем, күпернең ике ягыннан агылган халыкны карый-карый барам. Шулвакыт кинәт каяндыр һавадан, өстән гадәттән тыш калын, кырыс тавыш ишетелде: «Әти-и килә-ә!» Бу гади тавыш кына түгел, ә күк күкрәве кебек дәһшәтле, куркыныч тавыш иде. Мин аска карыйм: халык агыла да агыла. Бөтен шәһәрне яңгыратып, тагын шул тавыш ишетелде: «Әти-и килә-ә!». Карасам, КамАЗ заводлары ягыннан, халык арасында, аркасына юл биштәре аскан, өстенә начаррак кына кием кигән, урта буйлы бер кеше килә. Ул әле күренә, әле халык ташкынында югалып ала. Менә ул халык белән бергә мин басып торган күпергә килеп җитте, күпер астында бераз югалып торды да, халык белән бергә күпернең икенче ягыннан килеп чыкты. Мин ныклап күрергә дә өлгерә алмадым – әти, халык арасында бер күренеп, бер югалып, Кама елгасына таба китеп тә барды. Шулай итеп, мин әтине күпергә кадәр бер тапкыр, күпердән чыккач тагын бер тапкыр күреп, танып калдым.

Бу төш мине шактый уйландырды. Ул чыннан да минем әти иде бит! Әмма ни мин аңа, ни ул миңа бер сүз дә әйтешмәдек. Ул мине күрмәде дә кебек. Аның юл биштәре аскан, бераз бөкрәя төшкән гәүдәсе әле дә минем күз алдымда, ә колагымда: «Әти-и килә-ә!» – дигән дәһшәтле тавыш әле дә ишетелеп торган кебек.

Әтине төштә мин шулай күрдем. Ә чынлыкта ул нинди булган икән? Аны каян белергә? Инде хәзер әтине күргән-белгән кешеләрне дә таба алмыйсың. Әни дә, әтине күреп-белгән туганнар да вафат. Урыннары җәннәттә булсын! Бары бер генә чыганак – язма истәлекләр генә кала. Аларны каян табарга?

Миңа шунысы мәгълүм: атаклы Бәйрәкә мәдрәсәсендә укыган булса да, әтидән калган язмалар бик аз. Бары бер кесә дәфтәре сакланып калган. Ярый әле, ул сакланган; аннан аз гына булса да мәгълүмат алырга була.

Бу дәфтәр әтигә хәрби хезмәттә чакта, 1924 елда бирелгән. Мәктәп укучыларының гадәти сары тышлы 12 битле (аның да уртадан өч кенә бите), туры сызыклы дәфтәрен өчкә кискәннәр дә, шуның бер өлешен әтигә биргәннәр (ул елларда дәфтәргә дә кытлык булган ахры). Тышына «Красноармейская Памятная Книжка кр-ца Аракчинской кадроты 5 взвода Шарипова» дип язылган (язуы матур, почеркы грамотный). Ә әти аңа, гарәп язулы китапларда-

гы гадәт буенча, дәфтәрнең артыннан яза башлаган: дәфтәрнең арткы тышына гарәп хәрефләре белән: *«Ошбу дәфтәр Мәгъдәнинур (әтинең мулла кушкан исеме чыннан да Мәгъдәнинур булган) Шәрифовка бирелде 1924 сәнәдә, төрле нәрсәләр язар өчен»*, дип язып куйган. Дәфтәрне ачабыз. Беренче биткә, өскә кызыл кара белән әти түбәндәгеләрне язып куйган: *«Мин Казандан бөтенләй котылып кайтдым 1926 елда, 24 гыйнвар дүшәнбә көн, кич берлә сәгать 9да. Үзем Бөгелмәгә явиться 26 гыйнварда бардым, дүшәнбә көн. Янә волостка чәһәршәнбә көн 28 гыйнварда явиться булып кайтдым»*. Шуннан хәрби хезмәте турында болай өстәгән: *«Һәм дә үзем тегендә 29 ноябрьдә чирләп, 1 декабрьдә военный госпитальгә бардым. Анда 16 декабрьдә мине (бер сүз бозылган) илтделәр. Һәм дә анда 30 декабрьдә мине тагын кире госпитальгә кайтардылар. Анда мин 13 гыйнварда комиссия булып, частька кайтдым. Мәгъдәнур Шәрипов»*.

Шуннан соң дәфтәрдә карандаш белән язылган язулар китә. Әти анда халык җырларын язган. Җыр текстлары дәфтәрнең уртасына кадәр бара. Хезмәт иткәндә, туган якны, авылны сагынып, ул, бәлки, шул җырларны җырлап юангандыр. Ул гадәти халык җырлары, бирәдә аларны китереп тормыйбыз.

Әтинең хәрби хезмәттәге чагына караган тагын бер документ сакланган (бу язу әле күптән түгел генә әнинең язулары арасыннан килеп чыкты). Ул – белешмә-справка. Анда болай язылган: *«Начальнику ст. Юдино. Прошу принять к перевозке по требованию №1 за №0258316 от ст. Юдино до ст. Бугульма красноармейцев роты Халиуллина и Шарипова за счет норм пробегов Отдела Военных сообщений Приволжского военного округа. Комроты отд. (подпись), Военком (подпись)». Кәгазьнең сул ягына дүртпочмаклы печать басылган. Анда болай язылган: «Р.С.Ф.С.Р. Командир отдельной Караульной роты по охране Аракчинского Отдела Порохов КАЗАРТСКЛАДА. 20/1 – 1925 г. № 611. Аракчино»*. Димәк, әти Хәлиуллин дигән бер иптәше белән 1925 елның 20 нче гыйнварында Юдинодан Бөгелмәгә кадәр поездга утырып киткәннәр, дигән сүз. Бу, бәлки, аларны хәрби хезмәттән азга гына өйгә кайтып килергә җибәрүләре булгандыр. Әтинең үзенең язуы буенча (алда карап уздык), ул хәрби хезмәттән бары 1926 елның 24 гыйнварында гына кайтып төшә бит. Ә Хәлиуллинның кем икәнлеген әлегә ачыклап булмады.

Кесә дәфтәрендәге язулар болар белән генә бетми. Хәрби хезмәттән кайткач, үз тормышындагы яңалыкларны әти карандаш белән дәфтәрнең икенче ягыннан башлап язып киткән. Анда, беренче биттә: *«Бу дәфтәргә языла башланды 1929 нчы елда 6 нчы февральдә. Кәрәкәшле авылының Гыйльманов Мөхәммәдшәриф углы Мәгъдәнур»*, – дип башлап җибәргән. Монда ул фамилиясен Гыйльманов дип күрсәткән. Моны ничек аңларга? Эш шунда: фамилия мәсьәләсендә әти иркенрәк эш иткән булса кирәк. Гыйльман – әтинең әтисе ягыннан бабасы. Мөхәммәдшәрифне (минем бабайны) авылда «Гыйльман Шәрифе» дип атап йөрткәннәр. Хәрби хезмәттә чакта минем әти фамилияне үзенең әтисе исеменнән алып,«Шәрипов» дип йөргән булса, инде өйгә кайткач (монда мәҗбүриләү юк), үзенең бабасын хөрмәтләп, шәҗәрәсен искә төшереп, бары кесә дәфтәренә генә үзен «Гыйльманов» дип күрсәткән. Бу – әтинең үзенә күрә шәҗәрәсен күрсәтергә теләве булгандыр, бәлки.

Башка бер генә җирдә дә ул үзен «Гыйльманов» дип атамый.

Дәфтәрнең бу өлешендә әти үзенең кайчан өйләнүен теркәп куйган: *«Зәй-Каратай авылының мелла Габделгалим хәзрәт кызы Маһипәрваз исемле алынды 1929 елда һәм никах булды шул елда февральнең 6сында... Хак Тәгалә хәзрәте үзе гакыйбәтен (ахырын) хәерле кыйлсын инде»*. Шуннан соң әти Кәүсәр абыемның 1930 елның 28 февралендә тууы, Мөдирә исемле кызының 1932 елның 14 августында тууы һәм 1934 елның 5 мартында вафат булуы, бертуган абыйсы Нәҗипнең 45 яшендә 1933 елның 29 гыйнварында вафат булуы, 1934 елның 19 декабрендә апам Даниянең тууы һәм башка шундый мөһим даталарны теркәп куйган. Һәр язмадан соң үзен күрсәтеп, «Язучы Мәгъдәнур Шәрипов» дип язып барган.

Билгеле инде, мондый мәгълүматларның безнең нәсел өчен әһәмияте һәм кыйммәте әйтеп бетергесез. Аларны шәҗәрә төзегәндә файдаланырга мөмкин.

Шунысы шатлыклы, әлеге кесә дәфтәре әти турында бердәнбер язма чыганак түгел икән бит. Әле соңгы вакытта гына, әнидән калган язмаларны карап утырганда (ә ул озак еллар буе авылның остазбикәсе булды), әнинең бик күптән язылган кәгазьләре килеп чыкты. Үзенең кәгазьләре янына ул әтинең дә кечкенә генә дүрт бит кәгазен җеп белән тегеп куйган икән. Кәгазь кырыйларына үз кулы белән ике урынга «Мәгъдәнинур язулары» дип язып та куйган. Укып карасам, исләрем китте: менә бу табыш ичмасам! Шушы кечкенә генә дүрт кәгазьчектә төрле язмалар арасына әтинең өч шигыре язылган! Аларны әти үзе шәмәхә карандаш белән язып куйган. Бу минем өчен зур яңалык булды: моңа кадәр минем беркемнән

Утырганы – Шәрипов Хаҗиб (әтинең бертуган абыйсы), басканы – әтием. Бәйрәкә мәдрәсәсендә укыган вакытлары. 1913-1914 еллар тирәсе.

дә әтинең шигырьләр язганлыгы турында ишеткәнем юк иде. Укып карагач, шундый фикергә килдем: ул бу шигырьләрне Бәйрәкә мәдрәсәсендә укыган чакта язган булса кирәк. Икесен бергәләп укып карыйк әле, ничегрәк язган икән?

ГЫЙЛЕМ, БЕЛЕМ ХАКЫНДА

Бу дөньяда белемдән дә
үткен корал һич булмас.
Белем илә коралланган дөнья-ахирәт
хур булмас,
Белем илә коралланган хуҗа
буладыр илгә,
Бер белемсез булган адәм –
кол буладыр һәр җирдә.
Һәм Ходаның пәйгамбәре ниләр әйтде
безләр, кеше,
Һәм шуңа колак салыгызлар
инәй шуны сүзләр, кеше,

Кемдер тели яхшы дөнья,
мәгънәви зур хис илә,
Вә зур дәрт илә җан атып,
мин укыйм вәҗдал илә.
Рәхәтләнә, ләззәт таба,
күзләремнән акрын-акрын
Энҗе төсле яшь тама.
Шулвакытда баш ия нәфсем
бу Корьән әмренә,
Кул бирә мең җан берлән
җандин артык Тәңренә.
Әй, бөтен Җир, Күк Шаһы,
син сал күңлемә хаклык нурын,
Дип Ходайдан шулвакытда
нәфсем өчен тәүфыйк сорыйм.

БЕР ҖАН ШИГЫРЬ

Бән сокланам ислам диненә,
ислам белән мин мактанам,
Әл дә ислам исемен алганмын
әле, дип шатланам.
Булмаса да миндә һичбер
башка динне кимсетү,
Аламын ислам динне тик,
башка динне мактамам.
Иң ачык юл, иң төзек юл,
алың матур ислам юлы,
Кил, ачык, кергел, төзек юл.
Әй, матур ислам юлы!
Йөрмә юлсыз, булма юньсез,
китмә тар сукмак белән,
Гәр ахмак булма, адашма,
монда бит инсан тулы.
Монда хаклык, монда тугрылык,
монда юк айрым караш,
Монда эшлек, монда кешелек,
булса синдә айрырга баш.
Монда Җидегән, монда Чулпан,
монда ай берлән кояш.
Көн тик монда төн дә якты,
Ай белән Чулпан тугач.
Монда якты, монда яхшы,
монда акты күп кеше,
Тапды яктылыкны адәм,
«Аң» исемле таң тугач.

Шуңа игътибар итик, соңгы юлда сүз «Аң» журналы турында бара. Ә «Аң» журналы 1912 елның 15 декабреннән Казанда чыга башлый һәм 1918 елның мартында туктатыла.

Димәк, бу соңгы шигырь шул «Аң» журналы чыга башлагач, 1913-14 елларда язылган булырга кирәк. Минем уйлавымча, әти бу шигырь кисәкләрен үзалдына «Тукта, шигырь язйым да шагыйрь булыйм әле», дигән максат куеп язмагандыр, ә бәлки мәдрәсәдә уку дәверендә, яшьлек чорында, күңелләр чиксез ераклыкларга омтылган вакытта туган хис-омтылыш һәм фикерләр үзләреннән-үзләре кәгазьгә килеп төшкәннәрдер. Шигърият турында махсус белем алмаган кеше күңеленнән ургылып чыккан фикер-омтылышлар болар.

Соңгы вакытта табылган әлеге мәгълүматлар моңа кадәр минем аңымда формалашкан әти образына, әлбәттә, яңадан-яңа төсмерләр өстәде. Шулар янына мин тагын әтинең үземдә булган өч фотосы турында да әйтеп китәргә телим. Аның беренчесендә әти үзенең өлкән абыйсы Хаҗиб абзый белән Бәйрәкә мәдрәсәсендә укыган чакта төшкән (басып төшкәне – минем әти). Ә икенчесендә ул инде ир уртасы кеше; бәлки, чама белән 1929 нчы еллар тирәсендә төшкәндер. Ә өченчесе – бармак бите кадәр генә бәләкәй бер фото кисәге; аның артына күренер-күренмәс кенә «Шарипов Магданур. 28/IX – 41 г.» дип язылган. Бу фотода әти бик ябык. Бу вакытта ул Суслонгерда булган бит; сөйләүләр буенча, сугышка алу белән аны Суслонгерга җибәргәннәр. Ә анда инде, шулай ук кешеләр сөйләве буенча, солдатлар өчен яшәү шартлары бик авыр булган.

Узган ел, Бөек Җиңүнең 70 еллыгын билгеләп үтәргә җыенганда, сугышта һәлак булган әти турында минем кулда әнә шундый мәгълүматлар барлыкка килде. ■

Гали ага киңәшләре...

(Бер рәсем тарихы)

Рәис Сафин

Бу фоторәсемдә фронтовик шагыйрь Гали Хуҗи белән мин фәкыйрегез сурәтләнгән. Казан моторлар төзү берләшмәсендә татар телендә чыгарыла торган «Завод правдасы» газетасының мөхәррире Зыя ага Сәләхетдинов, каләм тибрәтүчеләрне җәлеп итеп, әдәби-иҗат түгәрәге оештырган иде. Түгәрәкнең утырышларына еш кына танылган шагыйрь Гали Хуҗины да чакыра иде.

Мин, әле күптән түгел генә армия хезмәтеннән кайткан, солдат каешын да билемнән салырга өлгермәгән егет, халык телендә 16 нчы завод дип йөртелгән предприятиедә слесарь булып эшли башладым. Сменалар туры килеп, вакытым булганда, түгәрәк утырышларында булырга тырыштым.

Гадәттә, түгәрәккә йөрүче егетләрнең берәрсе үзенең иҗат җимешләрен иптәшләренә тәкъдим итә. Түгәрәк әгъзаларының күбесе яшьләр булганлыктан, ул мәхәббәттән башы әйләнгән авторның шигыре була. Утырышларда фикер алышулар кызу һәм җан авазларына кушылып үтә. Яшьләрнең дәртле ашкынуларга уралган ялкынлы чыгышлары маңгайларына тир булып куна.

Соңгы, төпле сүзне, әлбәттә инде, Гали абый әйтә. Ул профессионалларча фикерләп, файдалы киңәшләрен

көндерә. Бериш шигырьләрне «Завод правдасы» газетасына тәкъдим итә. Ә беришләрен өлкә газета-журналлар редакциясенә юллый.

Шушындый кызу утырышларның берсендә, берничә шигыремне тыңлап, иптәшләрем мине дә кызган табага бастырганнар иде. Ничек кенә булса да, бер шигырем күптиражлы «Завод правдасы» газетасында басылырга лаек табылды. Шушы утырышта, Гали абый, йомгак ясап: «Синҗа, энекәш, һичшиксез, укырга, белемеңне күтәрергә кирәк. Фикер бар, образ бар. Ләкин белем һәм тәҗрибә җитешми», – дигән иде.

Ә инде әлеге фотосурәтнең барлыкка килү тарихы, шул чорларда С.П.Горбунов исемендәге Казан авиация заводында татар телендә чыгып килгән «Алга» газетасы каршындагы әдәби берләшмәнең бюро рәисе Илгизәр Фазлуллин белән бәйле. Соңарак үзе «Алга» газетасының мөхәррире булган, Татарстан Җөмһүриятенең атказанган мәдәният хезмәткәре Илгизәр Фазлуллин төшергән иде бу сурәтне.

Гали абыйның киңәшләрен тормышка ашыру теләге белән, (моңарчы төп һөнәрем – слесарьлык буенча разрядымны күтәрү курсында укыдым) кичке эшче-яшьләр татар мәктәбе директоры хөрмәтле Мәхмәт абый рөхсәте белән, уку елының икенче яртысыннан, 8 класста укый башладым.

Әйе, ач-ялангач сугыш чорында авыл мәктәбендә алган белемнең ни дәрәҗәдә булуына карамастан, укымый үткән тугыз ел юлларында белем хәзинәсе хәйран ук чәчелеп калган булып чыкты. Фәннәрне үзләштерү миңа бик авыр булды. Җитмәсә тагы, каты авырып китүем сәбәпле, 9 классның да икенче яртысын шифаханәдә дәваланып үткәрергә туры килде. Боларның барысы да алгебра, геометрия, тригонометрия дигән фәннәрнең миңа баш бирергә теләмәүләренә сәбәп булды. Башка фәннәрдән яхшы билгеләренә укыганымны күргән, әлеге фәннәрне укыткан класс җитәкчебез Әминә апаның зур тырышлыгы һәм рәхим-шәфкатьлеге аркасында, мин урта мәктәпне тәмамлау таныклыгына ия булдым.

«Тырышкан табар, ташка кадак кагар», ди безнең хикмәтле халкыбыз. Үзем дә, шушы тырыш, булдыклы милләтемнең бер улы буларак, Казаныбызның горурлыгы һәм безгә саналган В.И.Ленин исемендәге данлыклы университетның журналистика бүлеген 1968 елны уңышлы тәмамладым.

Һәм... шул елдан алып, 1999 елга кадәр мин бернинди дә әдәби-иҗади эш-гамәлләр белән шөгыльләнмәдем. Кем әйтмешли, җаным-тәнем белән бирелеп, хөкүмәт эшләре белән мәшгуль булдым.

Ләкин кайда гына, кем генә булып эшләсәм дә, әдәби-иҗади түгәрәктә алган уңай тәэсирләрем, уй-фикерләрем, изге ниятләрем мине гомерем буе озата барды. Мөхтәрәм шагыйрь Гали ага Хуҗиның күңелемдә уелып калган акыллы киңәшләре тормышымда дөрес юл табарга булышты. Мин аны еш кына олы ихтирам белән искә алам. Китапларын укып илһамланам. Меңмең рәхмәтләр аңа! Аллаһы Тәгалә рәхим-шәфкатеннән ташламасын, урыны оҗмахта булсын. Шулай ук, киң күңелле, изге ниятле шагыйрь белән мине фотосурәткә төшергән Илгизәр Фазлуллинга да ихлас күңелдән рәхмәтемне әйтәм. Зур рәхмәт сиңа, Илгизәр туган. ■

Әтиемнең фронт эзләреннән

Айдар Хәмзин

Кечкенә чакта мине өй түрендә торган өстәл тартмасы, дөресрәге, шул тартмадагы соры төстәге күн тышлы папка эчендә әтиемнең язган кенәгәләре кызыксындыра иде. Укый белмәсәм дә, искә төшкән саен идәнгә ятып шул кенәгәләрне актара торган идем. Бераз үсә төшеп укырга өйрәнгәч, мин әтинең, Хәмзин Наил Зиннур улының, 1955 елдан башлап, көненә өч тапкыр һава торышын, авыл тормышын, колхоз-совхоз яңалыкларын язып барганлыгын аңладым.

Алар арасында өстән аска ачыла торган, башкаларына охшамаган, үзенчәлекле, саргаеп беткән кесә дәфтәре мине аеруча кызыксындырды. Әти анда 1942 елның 11 августыннан алып (туган йортыннан чыгып китүдән башлап) 1945 елның 28 июненә кадәр, Харьков каласы госпиталеннән чыгып, туган якларына кайту көненә кадәрге чор турында язып барган. Көндәлектә атап үтелгән Ярославль, Сталинград, Курск, Киев, Львов кебек шәһәрләр әтинең кай тирәләрдә сугышып йөрүе турында сөйләсә дә, бик күп кечкенә кала, авыл исемнәре турында минем ишеткәнем дә юк иде. Шунлыктан, әтинең сугышта үткән юлын картага төшерү теләге туды. Кечкенә форматка (А3 форматы) зур шәһәрләр белән кечкенә авылларны берләштереп урнаштыру эше җайлы булып чыкмады, масштабын саклап, кырыклап картаны кулланып, аларны кечерәйтеп бер картага җыю шактый вакытны алса да, бик мавыктыргыч һәм кызыклы эш булып чыкты. Бу эшләрне башкарып чыгарга миңа улым Айзат ярдәм итте. Менә, ниһаять, картаны ясап бетереп принтердан чыгардык та бөтен гаилә белән (90 яшьлек әни, мин, җәмәгатем Илүзә һәм балалар – Айзат, Айзилә, Айбулат) әтинең Бөек Ватан сугышында йөргән эзләре буйлап карта сәяхәтенә чыгып киттек.

Башлангыч ноктабыз (пунктыбыз) – Түбән Кама районының Ташлык авылы. Бөек Ватан сугышы башланганда Хәмзин Наил Зиннур улына 16 яшь (1924 елның 1октябрендә туган) була. Сугышка яраклы бөтен ир-атны Ватанны сакларга алалар, авылда карт-коры, хатын-кыз, малай-шалай гына кала. Аларга тырыш хезмәт куеп, фронтка икмәк, ит, сөт һәм башка авыл хуҗалыгы продуктларын җитештерү максаты куела. Һәр кешенең фашизм-



Сулдан уңга: өстәге рәт – Кәлимуллин Риан, Зөфәров Шәрипҗан, Гайнетдинов Фаиз;
астагы рәт – Хәмзин Наил, Гәйфетдинов Фәүзи.
1940 ел, июнь

ны җиңүгә үзеннән лаеклы өлеш кертәсе килә. Авыл халкы үзе өчен дә, сугыштагы ир-атлар өчен дә эшли. Колхоз идарәсе шушындый авыр вакытта яшь егет Наилне өч кырчылык әртиленең җитәкчесе итеп куя. Ул бу эштә үзен оста оештыручы, сәләтле җитәкче итеп күрсәтә. Әртил үзенең басуларыннан мул уңыш җыеп алып, дәүләт заказын арттырып үти, 1942 елгы язгы чәчү эшләрен кыска вакытта югары сыйфатлы итеп башкара. Бу хезмәтләре өчен Ватаныбыз аны «1941-1945 елларда намуслы хезмәте өчен» медале белән бүләкли.

Унсигез яше дә тулмаган Наил Зиннур улын 1942 елның 11 августында Ширәмәт военкоматыннан армиягә алалар. 1924 елгылар авылда күп булган. Бөтен авыл халкы аларны зурлап, гармун белән җырлап-биеп, елап сугышка озаткан. Ул елларның шаһитлары, яшь солдатларны озатканда җыенга (безнең якларда Сабан туен ул елларда җыен дип йөрткәннәр) җыелган хәтле халык булган, дип искә ала. Бик күпләр, атлар җигеп, Тоба авылына кадәр озата барган. Әтине дә, ат арбасына утыртып, әнисе Мәликә, сеңелләре Динә, Финә (әтисе Зиннурны 1941 елны ук сугышка алып китәләр, энесе Әзәл ФЗУда укый) Тоба авылына илтеп куялар, Смыловка авылы пристаненнан аларны пароход белән башлангыч хәрби әзерлек үтәр өчен Ярославль каласына озаталар, аннан поездга утыртып Сурок станциясенә алып киләләр.

Матбугатта Мари Республикасының данлыклы Суслонгер һәм Сурокта сугышчан әзерлек үтүче яшь солдатларның ачлыктан, ялангачлыктан күпләп үлүләре турында шактый язылды. Әти менә шул мәхшәрдә 1942 елның 1 октябреннән алып 28 декабрьгә кадәр (89 көн) була. Өйгә килгән хатларда солдатның авыр тормышы турында ачык итеп язылмаса да (хатларны даими тикшереп торганнар), әнисе Мәликә улының бик куркыныч җиргә эләгүен аңлап (өстәге хәрби җитәкчеләр белмәсә дә, якын-тирәдәге халык солдатларның кырылуын белгән), ашамлыклар, йон оекбашлар, җылы кием-салым тутырып посылка җибәрә. Бераз вакыттан соң адресаты табылмады, дип посылка кире кайта, ачып карагач, эченнән кирпечләр килеп чыга. Улының язмышы өчен борчылган ана Кәримә исемле авылдашы белән (аның да малае шунда була) өйдә булган азык-төлеген биштәренә салып, балаларын олы яшьтәге каенанасы Хәдичә әбигә калдыра һәм Сурокка кузгала. Мең газаплар белән Казанга килеп җитүләре турында сөйләп тормыйча гына, Сурок станциясенең кайда икәнлеген белмәгән хатын-кызлар, кешеләрдән сорашып, тимер юл буйлап җәяүләп кенә, Казаннан туксан чакрым ераклыкта урнашкан хәрби частьне эзләп китәләр. Килеп җиткәч, андагы хәлләр Мәликә белән Кәримәне тәмам аптырашта калдыра. Күптән юньле ризык күрмәгән ач, пычрак киемле, бетләп беткән совет солдатларының аяныч хәлләре 1921 елгы ачлыкны кичергән хатын-кызларны тетрәндерә. Көчле рухлы, нык ихтыярлы совет солдаты алар алдында мескен, көчсез, очраган бер кешедән кулларын сузып ашарга теләнеп сораучы кыяфәтендә килеп баса. Мәликә әби гомеренең соңгы көннәренә кадәр бу җан өшеткеч вакыйгаларны искә төшерә иде. Балаларына дип алып килгән ашамлыкларын шул солдатларны кызганып бирә торгач, хатын-кызларның биштәрдәге азык-төлеге дә бетә яза. Ашарга эләкмәгән солдатларның ялварулы күз карашларыннан качып, ике ахирәт газиз балаларын эзләп китә. Яңа килгән солдатлар җир эченә казып ясалган «землянкаларда», «өлкәнрәк» солдатлар җирле халык өйләрендә, ә командирлар махсус төзелгән кечкенә ба-

ракларда яши. Бәлки безнең балалар яхшырак хәлдәдер, дигән өмет очрашуның беренче мизгелләрендә үк чәлпәрәмә килә. Шул ук ач чырай, тырпаеп торучы колаклар, әчкә баткан күзләр, бетләп беткән чәч, ябык гәүдә, пычрак кием... Очрашу шатлыгыннан соң, тамак ялгап алгач, ике ана солдат киемнәрен юарга керешә, Сурокта яшәүче берәүнең мунчасына кертеп балаларын яхшылап юындырганнар. Күпне күргән ике ана бу мәһшәрнең тизрәк бетүен теләп, кайтып китәргә мәҗбүр була, чөнки аларны өйдә берсеннән-берсе кечкенә балалары, өлкән яшьтәге Хәдичә әби, колхоз эше көтеп тора.

Әтинең исә Суроктагы хәлләр турында сөйләгәне булмады. Бары бер очракны гына искә ала иде. Салкын җилле төнне аны каравылга куялар, янәсе хәрби хезмәткә өйрәтәләр. Тикшерүчеләр килеп киткәннән соң, әти салкын җилдән ышыкланып, коймага терәлеп утырган җиреннән оеган... Уянгач, янында мылтыгы юклыгын абайлап ала да, эзләргә керешә. Каравылда торучы башка солдатлар да кайсы баскан, кайсы утырган җиреннән йоклый, шулар арасыннан йоклап ятучы берәүдән үз мылтыгын табып ала да кабат постына китә. Күрәсең, теге солдат мылтыгын әллә үзе югалткан, әллә тикшерүчеләр ул йоклаган вакытта алып киткән, анысын әтидән сорарга башка килмәгән.

Әти белән бер көнне армиягә алынган Би авылыннан Җиһангиров Хадий Габделхак улы Сурокта туңган җирдә землянка казытуларын, урманда агач кисү, хәлсез солдатларның агач астында басылып үлүләре, бүрәнәне бер көнне бер урынга, икенче көнне кабат үз урынына кире ташытуларын, үзләренең бик ачыккач, агач кайрыларын ашаулары турында еш искә ала торган булган.

Тизрәк фронтка җибәрүләрен көтеп яткан әтинең теләге кабул була, аны яңа ел алдыннан, 28 декабрьдә поезд белән Сталинградка җибәрәләр. «Сугышчан тәрбия»не нык өйрәнгән яшь солдатларны Сталинград фронтында совет гаскәрләренең һөҗүмгә күчкән вакытында алгы сафка куялар. Әти беренче сугышка кергән 9 гыйнвар көнен еш искә ала иде. Яшь солдатларны окопларга урнаштыралар, рөхсәтсез атарга ярамаганлыгын аңлаталар. Кышкы салкын үзенекен эшли, тик яткан солдатлар туңа башлый, командирлардан бераз язылып, җылынып алырга иде, дип үтенәләр. Тегеләре исә көлеп: «Сейчас, жарко будет», – дип кенә җавап бирә. Чыннан да, бераздан немесләр ата башлагач, куркудан тирләп-пешеп беттек, дип әти көлеп сөйли иде. Һөҗүмгә күтәрелгән «нык әзерлекле» яшь солдатлар ул көннәрдә бик күпләп кырылган. «Командирыбызның окоптан чыкмаска боеруы гына безне исән калдырды», – дип әти искә ала иде.

Әтием бер якташының яраланып өенә кайтып киткәнен искә алгалады. Ул фронттагы авыр шартларга түзә алмыйча, үз аягына мылтыктан ата – янәсе ялгыш мылтык курогына баскан. Исемен язып тормыйм, ул абый, исерек хәлдә, 2006 елда әтигә инсульт булганын ишетеп хәлен белергә килгән иде. Әти, яткан җиреннән нишләргә белмичә, нәрсәдер әйтергә теләп (инсульттан соң бераз сөйләү сәләте бетеп торды), җаны-тәне белән нәфрәтен күрсәтеп, манма тиргә батты. Аның бераз параличланган уң кулы белән юрганын чытырдатып тотып, кунакны өйдән куып чыгарырга теләвен күрдем. Ул абыйны озата чыккач, әти янына бүтән килмәвен үтендем. Исән калган Бөек Ватан сугышы ветераннары арасында ул кешенең пенсиясе иң зур булганлыгын да әйтеп китми булмас.

13 гыйнварда әтинең кулы яралана. Госпитальдә дәваланып чыккач, леген-

Әтине сугышка озаткан көнне төшкән фото. Әнисе Мәликә, сеңелләре Динә һәм Финә. 1942 елның 11 августы, Тоба авылы

дар Ленин орденлы, ике тапкыр Кызыл Байраклы 13 нче укчы гвардия дивизиясе составында Курск-Орел дугасы өчен барган каты сугышларда катнаша. Әлеге хәлиткеч көрәштән соң дошманны бөтен фронт буйлап куа башлыйлар, берәм-берәм авылларны, калаларны фашистлардан азат итәләр. Әтиемне аеруча зур батырлыклар күрсәткәне өчен Ватан сугышы ордены һәм бер медаль (исеме истә калмаган) белән бүләклиләр. 1943 елның 18 августында, башы яраланып госпитальгә эләккәч, орден белән медаль югала. Әти сугыштан соң военкомат аркылы язып эзләтеп тә караган иде, тик очына чыга алмады. Терелеп чыкканнан соң Украина җирләрен азат итүдә дә катнаша. Яңадан әтинең хатирәләрен искә төшерәм: «Совет гаскәрләренең бөтен фронт буйлап һөҗүмгә күчкән вакыты. Көн саен диярлек бер авыл яки кала азат ителә. Кайвакыт һөҗүмчеләр шулкадәр алга китәләр, алар артыннан баручы азык-төлек белән тәэмин итүчеләр өлгерә алмый. Безнең бер төркем солдатлар дошманнан азат ителгән бер украин авылына бәреп керәләр һәм анда нимеснең ташлап калдырган ашамлыкларына тап булалар. Тамакны ныклап туйдырганнан соң, бар булган кесәләргә, биштәрләргә, күтәрелгән шинель итәген кулланып куенга азык-төлек тутырыла, автоматлар аркага асыла. Берничә көн юньләп ризык күрмәгән, мондый байлыкка ия булып, шатлыклары чиктән ашкан солдатлар үзләренең хәрби

частьларын эзләп китәләр. Ачык басу аша үткәндә, әллә каян килеп чыккан немесләр ата башлый. Башта куркытырга теләп аяк астына аталар, юлдан төянеп баручы совет солдатларыннан көлгәннәре аермачык ишетелеп тора. Аннан безнең солдатларның төрле якка таралып, трофейларын күтәреп йөгерүләрен күреп (азыкны ташламыйлар, частьта ач иптәшләре көтеп тора бит) чынлап ата башлыйлар, тик тигезә генә алмыйлар». Әти шушы очракны искә алып, ничек шулвакытта немесләр тигезә алмаганнардыр, һаман да аңлый алмыйм, ди торган иде.

Шулай бервакыт, февраль аеның көчле буранлы төнендә ике татар егете, якташлар – Хадий белән Наилне тирә-юньне яхшырак өйрәнер өчен разведкага җибәрәләр. Күз күреме юк дәрәҗәсендә булган караңгы төндә ике разведчик юлларны, елга-чокырларны, якын тирәдәге авылларны өйрәнеп кайта. Шыкраеп каткан егетләр үзебезнең позицияләргә җиткәндәрәк: «Стой, кто идет? Пароль?» – дигән тавыш ишетә. Разведчиклар: «Свои, свои», – дип җавап бирә. Тегеләре исә һаман пароль сорый, ә болар исә парольне әллә туңып беткәнгә, әллә курыкканга онытканнар, бер үк сүзне кабатлыйлар: «Свои, свои». Парольне әйтмәгәч, безнең позицияләрдән автоматтан ата башлыйлар. Башлар, гәүдәләр белән карга чумып, көч-хәл белән исән калдык, дип искә ала Хадий абый. Боларның командирлары ату тавышын ишетеп килә һәм ике солдатының разведкага китүен хәбәр итә. Ату туктатыла, Хадий Җиһангиров һәм Наил Хәмзинне строй алдына бастырып командирлары пароль турында сорый. Оныттык, дигәч, башта Хадий абыйның яңагына, аннан Наилнекенә чалтыратып җибәрә. Атылып барып төшкән егетләр командирның пароль турындагы соравына «Звезда, звезда», – дип җавап кайтаралар. Икенче көнне көндез парольне гомернең соңгы көненә кадәр онытмаслык итеп хәтердә калдырган егетләрне яңадан разведкага җибәрәләр. Егетләр якын тирәдәге иңкүлекләрнең берсендә немеслар тарафыннан ташлап калдырылган хәрби техникага, солдат кием-салымына тап була. Иң беренче эш итеп, икесе дә табылган шинельләрнең итәкләрен кисеп, үзләренә портянка ясый, катып-туңып йөргән аякларына җылы керә. Шунда ук немес офицерлары планшетларын да табып алалар, кайткач иптәшләренә өләшәләр, берничәсен үзләренә дә калдыралар. Хадий абый, соңгы планшетны, яраланып госпитальгә эләккәч, карта уенында оттыруын искә ала торган була.

1944 елның 1 гыйварын әти Киев шәһәрендә каршылый, аннан, язмалардан күренгәнчә, Житомир, Верба, Кременец... 1944 елның 20 апреленнән 31 августына кадәр кече лейтенантлар әзерләү курсларында укый. Аны тәмамлагач, Польша, Чехословакияне азат итү сугышларында взвод командиры булып катнаша. Сандо-

мир плацдармы өчен барган сугышларда 9 ноябрь көнне аягына снаряд кыйпылчыгы тиеп каты яралана, уң аягын кисәләр. Аягыңны кискәндә бик авырттымы, дигән сорауга: «Операция җирле наркоз астында эшләнде, табиблар белән сөйләшеп яттым, кискәндә аркылы пычкы белән кистеләр, йомшак ипи кискәндәге кебек кенә булды, ләкин соңыннан бик нык авыртты, сызлады», – дип сөйли торган иде. Аннан Польшаның Жешув, Украинаның Львов, Тернополь, Проскуров (Хмельницкий), Жмеринка, Киев, Лубны госпитальләре... 1945 елның 16 февралендә яңадан операция ясатырга туры килә. 19 март көнендә өйдән килгән хат аша Хәдичә әбисе үлгәнлеген белә. Җавап хатында: «Вечная слава әбигә!» – дип язган сүзләрен сеңелләре Динә белән Финә хәзер дә искә төшереп сөйлиләр.

Бер хатында әти госпитальдә ашау яклары әйбәт булуын, төрле ашлар, боткалар, чәй, компот бирүләре турында яза. Җавап хатында сеңелләре язылган бар нәрсәләрнең дә аңлашылганлыгын, бары тик компот сүзенең мәгънәсен аңлатып язуын үтенәләр. Көндәлектә шулай ук, офицер буларак, 600 сум хезмәт хакы алганлыгы, аның 200 сумын енекәше Әзәлгә җибәрүе турында да мәгълүмат бар. Өйдә чирек капчык он була торып, аннан бернәрсә дә пешермәүләре сеңелләре Динә белән Финәне аптырашта калдыра. Алар тамаклары ач булганга берәр нәрсә пешереп ашау турында берничә тапкыр әниләренә сүз кузгатып карыйлар. Тик әниләре Мәликә генә онның олы малае Наилнең сугыштан җибәргән акчага алынуын һәм ул кайткач кына шушы онны кулланачагын әйтә. Язмалардан күренгәнчә, савыгу җиңел генә бармаган. Әтием 9 апрельдә егылып аягын тагын бик нык авырттырган, ике көн югары температура белән башын күтәрә алмыйча яткан. 9 май, Җиңү көнен әти Полтавада каршылый. Аңа бу шәһәрнең госпиталендә протез эшләп бирәләр.

Көндәлегендәге соңгы язма Харьков каласында 1945 елнын 28 июнендә язылган. Юлга чыгар алдыннан әти авылга хат юллый: «Смыловка пристанена ат белән килеп каршы алыгыз, килмәсәгез, пароход белән кире китәчәкмен», – дип язып куярга да онытмый. Әнисе Мәликә ат җигеп каршы алырга китә, өрлектәй малаеның таяк ярдәмендә генә көчкә хәрәкәт итүе ананы бик борчыса да, исән кайту шатлыгы бөтен хәсрәтне онытырга ярдәм итә. Алар кайтканда бөтен авыл халкы Хәмзиннәрнең капка төбенә җыела. Бу вакыйганың шаһитлары сугыштан инвалид булып кайткан әтинең утырган җиреннән генә авыл халкы белән күрешеп чыкканнан соң, ат арбасыннан төшәргә читенсенеп торганын, йөзләгән күз текәлеп карап торганда егылмыйча гына йөреп китәчәгенә бик үк ышанып җитмәвен, аннан саклык белән генә арбадан төшеп, таякка таянып өйгә кереп киткәне турында искә алалар.

Без кечкенә чакта «мылтыклы» уйный идек. Дошманыбыз һәрвакыт нимес (фашист) булды, уен рейхстагны алу белән тәмамланды. Ак кар эченә казып ясалган окоптан дошманга аткан чагында, «ура» кычкырып һөҗүмгә барганда, әти дә яу кырында шулай йөрде микән, дигән сабыйларча беркатлы уй барлыкка килә иде. Төннәрен уенга үземчә анализ ясаганда, кабат әти турында уйлыйм: ул бик батыр сугышчы булгандыр, әллә ничә тапкыр яралануга карамастан, һаман сугыш кырыннан китмәгән, автоматчы да, разведчик та булган...

Әтинең батыр сугышчы булуы тыныч тормышта да исбатланды. Гомеренең күп өлешен ул авыл советы рәисе, «Уңыш», «Ленин» исемендәге

күмәк хуҗалыкларда рәис ярдәмчесе, аның дәвамчысы булган «Коммунизм байрагы» совхозында партоешма секретаре булып эшләде. Ул вакытта халык гаиләдә берәр хәл булса, парткомга (халык телендә шулай атала) килә иде. Шулай бервакыт, 1970 нче еллар тирәсендә, кичке уннар булгандыр, куркуы йөзенә чыккан, чәчебашы тузган бер апа йөгереп кереп каенатасының балта күтәреп үз малаен чабып үтерергә җыенуын хәбәр итте. Ул апаның йөз-кыяфәте хәлнең чыннан да җитди булуы турында сөйли иде. Әти тиз генә протезын аягына киде дә, күршеләргә кереп китте. Күрше апа мин анда керергә куркам, дип бездә калды, аның әледән-әле кычкырып елавы, үтермәсә генә ярар иде, дип ире өчен борчылуы мине дә бик куркытты. Ул вакытта күрше апага бик ачуым да килгән иде. Ничек инде, илле биш яшьлек олы гәүдәле әтисе утыз яшьләрдәге ат егардай гайрәтле малаен куркыткан, ә минем бер аягы булмаган инвалид әтием шул абыйны җиңәргә тиеш? Үзе бездә качып ята. Бераздан кулына балта күтәреп, теге апаның ирен ияртеп әти килеп чыкты: «Мә, балтагызны җыебрак йөрегез, кулыннан тартып алдым, Аллага шөкер, яшьләрне генә куркытырлык көч калган икән әле. Бик ярсыган иде, көчкә тынычландырдым», – дип, бу вакыйгага нокта куйды.

Икенче тапкыр әти ялгыш пычак белән кулын кисте, ярасы шактый зур иде, каны нык тамды. Айрат абыйның яңа гына килен булып төшкән җәмәгате Роза апа, яралы кулны күрү белән, өйдән марля, йод алып чыгарга йөгерде. Ул чыкканда әти кулына туфрак алып, ярасына сибеп утыра иде. Моны күргән Роза апа чүт егылып китмәде, янәсе кулына инфекция керер, үлекләр, шешәр... Әти ярасын туфрак белән эшкәртүен дәвам итеп:

– Әй, кызым, сугышта без яраны һәрвакыт туфрак белән эшкәрттек, санитарлар килгәнне көтеп ятмадык, сугышырга кирәк иде, юк-бар ярага игътибар итәргә вакыт булмады, – дип җавап кайтарды.

Көндәлекне өйрәнгәндә мин менә нәрсәләргә игътибар иттем. Әти сугышта 1942 елның 11 августыннан алып 1945 елның 28 июненә кадәр була, ягъни – 1052 көн. Шуның 232 көнен госпитальләрдә дәвалана, өч тапкыр яралана. Гомеренең соңгы елларында күрше Фәндия апаның Җиңү көненә нишләп бармыйсың, дигән соравына: «Җаный, анда сугышкан кеше калмады диярлек. Ныклап сугышканнар йә сугыш кырында ятып калды, йә кайткач, яраларыннан үлеп бетте. Дүрт ел сугышта булып бер пуля, снаряд кыйпылчыгы да тимәгән солдат йә штабта яткан, йә сугыш вакытында төрмәдә утырган яки качып кайткан», – ди торган иде.

Ниһаять, әтинең фронт юллары буенча төзелгән карта буйлап сәяхәт тәмам. Картаны ясаганда күп эзләнергә, туганнарның хатирәләрен яңартырга туры килде. Динә һәм Финә апалар абыйлары турында шактый мәгълүмат бирде.

Авылыбызның мөхтәрәм карты, утны-суны кичкән батыр фронтовик әтиебез 2006 елның 21 июнендә бакый дөньяга күчте, ә сугыш башланган көн – 22 июньдә аны бөтен авыл халкы, туган-тумачалары, хөрмәтләп, соңгы юлга озатты. Батырлар даны – мәңгелек! Әтием турындагы истәлекләр дә тарих сәхифәләрендә уелыр, мәңге җуелмас, яшь буын аны өйрәнер һәм аларны тыныч тормышта яңа Җиңүләргә рухландырыр, дигән өметтә калам. ■

Безнең халыкның тормыш күге беркайчан да болытсыз булмады. Егерменче гасырның беренче яртысында яшәгәннәргә аеручa күп кайгы-хәсрәт, авырлыклар кичерергә туры килде. Бу чорда кешеләрнең язмышларын дүрт сугыш һәм ике инкыйлаб билгеләде. Алар арасында иң җимергече, иң кан коюлысы немец-фашист баскынчыларына каршы дүрт елга тартылган сугыш булды. Бөек Ватан сугышы 1418 көн һәм төн дәвам итте.

Афәт

Әгъзам Фәйзрахманов

Сугышның беренче сәгатьләреннән үк республика хәрби комиссариатларында йөзәрләп, меңәрләп иреклеләр чиратка басты. Беренче көнне үк фронтка җибәрүне сорап, 14 мең кеше гариза китерде. Татарстан сугыш елларында армиягә 560 мең сугышчы бирде. Әлеге коточкыч афәткә кадәр үк солдатка алынганнарны да исәпләсәк, фронтларда безнең республикадан гына 700 меңгә якын кеше сугышты. Безнең төбәктә 7 укчы дивизия, уннарча полк һәм батальон формалашты.

Якташларыбыз аяусыз сугышта дошман белән йөзгә-йөз очрашучыларның иң алгы рәтендә булган. Брест крепосте оборонасын җитәкләүче Питрәч егете, керәшен татар Пётр Гаврилов исеме күпләргә таныш. Ул һәм аның карамагындагы сугышчылар дошманның тулы бер дивизиясен ай буе тоткарлап торган. Фашист командованиесе крепостьның алынуы турында Гитлерга ике тапкыр доклад ясый. Ә крепость яши һәм каршылык күрсәтүен дәвам итә. Брест тирәсендә дошманны чик сакчылары Хәким Маннапов, Шәмси Мәрдиев кебек кыю егетләр каршылый.

Якташларыбызның батырлыклары сокландыра. 437 нче укчы полк комбаты, капитан Фёдор Баталов 1941 елның 9 августында ук батырлыгы өчен татарстанлылардан беренче булып Советлар Союзы Герое дигән югары исем алган. 1941 елда ук Казан егете Фәрит Фәтхуллин эскадрильясы тулы

составы белән Герой исеменә лаек булган. Бер эскадрильяның барлык очучыларын Советлар Союзы Герое исеменә тәкдим итү очрагы сугыш һәм авиация тарихында, мөгаен, бердәнбер булгандыр. Сугыш вакытында дан казанган югары дәрәҗәле гаскәр башлыклары – армия, фронт белән җитәкчелек иткән күренекле шәхесләр Василий Чуйков, Леонид Говоров, Василий Гордов, Андрей Еременко, Иван Конев, Родион Малиновский милләттәшләребезнең тиңдәшсез батырлык күрсәтеп сугышуы, хәрби бурычларын үтәүдә үз-үзләрен аямаулары хакында язып калдырган. Советлар Союзы Герое исеменә лаек булучылар саны буенча да татарлар рус, украин, белоруслардан кала, СССРда дүртенче урында тора.

Халкыбыз кылган батырлыклар онытылмасын, сугыш вакыйгалары хәтердән җуелмасын өчен, аларны һәрвакыт искә төшереп торырга кирәк. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәрләре, әтиле-уллы язучы-галимнәр **Лирон** белән **Булат Хәмидуллиннар** яңарак кына шундый игелекле гамәл башкарды. Алар «Җиңү җиңел бирелмәде»* дигән китап чыгарды. Китапның фәнни мөхәррирләре тарих фәннәре докторлары, профессорлар – Индус Таһиров һәм Искәндәр Гыйләҗев.

Әлбәттә, бер китапта гына Бөек Ватан сугышы тарихын тулаем колачлау мөмкин эш түгел. Авторлар андый максат куймаган да. Төп максатлары – Татарстан Республикасы һәм аның халкының Бөек Җиңүгә керткән өлешен чагылдыру, шул исәптән республикабыздан читтә яшәүче милләттәшләребезнең дә сугышта күрсәткән батырлыгын барларга тырышу. Республикабызда оешкан дивизияләрнең сугышчан юлы һәм кылган гамәлләре китапта киң як-

Советлар Союзы Герое Фәрит Фәтхуллин

тыртылган. Татарстан халкы сугыш елларында Җиңү фондына туплаган акчасы хисабына 200әр машинадан торган өч танк колоннасы, йөзәр штурмовик-бомбардировщик тупланган эскадрильяларны, берничә бронепоезд һәм бронекатерны фронтка бүләк итеп җибәрә. Сугышның беренче дүрт аенда гына да республиканың җирле сәнәгать предприятиеләре фронтка ике миллионга якын хәрби кием-салым, 265 мең плащ-палатка, 1500 пар аяк киеме озата. Казандагы өч авиазавод еракка оча торган йөзгә якын авыр Пе-8 бомбардировщигы, 11 меңгә якын тиз очышлы Пе-2 бомбардировщик-пикировщигы эшләп чыгара. Бишбалтадагы завод исә аеруча хатын-кыз бомбардировщиклар полкында кулланылган җиңел У-2, По-2 очкычларын 10,5 мең данәдә җитештергән.

«Сугыш афәте илдәге барлык кешеләр өстенә авыр йөк булып төште.

*Китап Татарстан Республикасының Дәүләт киңәшчесе М.М.Шәймиев ярдәме белән дөнья күрде.

Советлар Союзы Герое Пётр Гаврилов

Советлар Союзы Герое Мәгубә Сыртланова

Ул кыенлыкларны җиңеп чыгу өчен олыларга да, үсмер балаларга да күп көч сарыф итәргә туры килде. Һәм миллионлаган кеше, бу кыенлыкларны җиңеп чыгып, корал тотып, дошманга каршы көрәшүче сугышчыларның Бөек Җиңүгә ирешүенә үз өлешен кертте», – дип яза китапка кереш сүзендә армия генералы, тарих һәм хәрби фәннәр докторы, Хәрби фәннәр академиясе президенты Мәхмүт Гәрәев.

Татарлар – төрле төбәкләргә сибелеп яшәүче халык. Китапта билгеләп үтелгәнчә, Советлар Союзы Герое исеменә лаек булучылар арасында чит төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребез саны да бик ишле. Мәсәлән, Самара шәһәрендә туган Ольга Санфирова, Башкортстаннан Мәгубә Сыртланова, Оренбургта туган Шамил Абдерәшитов, Арча районының Иске Кишет авылында туып үссә дә, сугышка Казахстаннан мобилизацияләнгән генерал-лейтенант Гани Сафиуллин, Ульянов өлкәсендә туган Хәмзә Багданов, Казанда туган, 1929 елда Татар-башкорт хәрби мәктәбен тәмамлаган Фёдор Баталов һәм башка бик күпләр бар. Шулай ук бу хезмәттә искә алынган сугыш батырлары арасында республикада яшәгән төрле милләт вәкилләре исемлеге дә бик озын: Борис Васильев, Михаил Девятаев, Һибазә Доспанова, Борис Кузнецов, Леонид Соколов, Алексей Чулков, Евдокия Корабут һәм башкалар – яу кырында иңгә-иң торып, дошманга каршы көрәшкән, Бөек Җиңүгә үз өлешләрен керткән батыр шәхесләр.

Китапта Испаниядәге гражданнар сугышында интернациональ бурычны үтәүче сыйфатында катнашкан, үткән гасырның 30 нчы еллары ахырында СССРның Хәсән күле, Монголиянең Халхин-Гол елгасы тирәсендә, 1939-1940 елларда СССР-Финляндия арасындагы сугышта катнашкан якташларыбыз турында да материаллар тупланган. Бу нисбәттән әле 1941 елның 22 июненә чаклы, ягъни Бөек

Ватан сугышы башланганчы ук унбер милләттәшебезгә Герой исеме бирелүен искәртеп үтү урынлы булыр.

Татарстан АССР вәкилләреннән Советлар Союзы Герое исеменә иң беренчеләрдән булып Чирмешән районында туып үскән мордва егете, каптиан Павел Цаплин лаек була. Ул Испаниядәге гражданнар сугышында катнаша. Танкистлар ротасы командиры буларак, берничә бәрелештә җиңүгә ирешә. Харам фронтындагы сугышларның берсендә исә, зур батырлык күрсәтеп, танкта янып һәлак була. Шул сугышта күрсәткән батырлыклары өчен 31 яшьлек танкист СССР Югары Советы Президиумы Указы нигезендә (27 июнь, 1937 ел) иң югары бүләккә лаек дип табыла. Шундый ук мәртәбәле бүләккә Хәсән күле чик буе отрядының кече командиры Гыйльфан Батыршин белән 119 нчы укчы полк пулемётчысы Кәрим Яһудин да ия була. Ике сугыш арасында тупчылар хәрби мәктәбен тәмамларга өлгергән К.Яһудинның сугышчан юлы 1944 елның августында Литва җирләрен азат иткәндә, ә майор Г.Батыршинныкы исә, японнарны җиңү тантанасын үткәргәннән соң, самолёт һәлакәтендә өзелә. Казанның бер урамы хәзерге көндә Гыйльфан Батыршин исемен йөртә.

Тарихка совет-фин сугышы буларак кереп калган яуда Казанда тупланган дивизия дә иң хәтәр юнәлешләрдә сугыша. Дивизиянең 12 гаскәриенә Советлар Союзы Герое исеме бирелү дә шуның бер ачык дәлиле. Бу батырлар арасында полк командиры, полковник Михаил Зашибалов, дошман танкларына каршы торучы тупчылар дивизионы командиры, лейтенант Хәбибулла Ибраһимов, укчылар ротасы командиры, лейтенант Гыймазетдин Вәзетдинов, пулемётчылар взводы командиры, лейтенант Хафиз Сабиров та бар. Совет-фин сугышында башка дивизия һәм бригадаларда хезмәт итүче якташларыбыз да катнаша. Шулар арасыннан танкистлар батальонынннан кече командир Гафиятулла Арсланов, укчылар батальоны командиры капитан Иван Зиновьев, шул ук яуда һәлак булган танк командиры, Минзәләдә туган якташыбыз Борис Винокуров та була.

Татарлар Берлинны алу өчен барган сугышларда да танылалар.

50 меңләп сугышчыны берләштергән укчы корпус командиры генерал-лейтенант Якуб Чанышев «Берлин операциясе»н үтәгәндәге уңышлары өчен Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим ителгән була. Гвардия полковнигы Хәмзә Багдановның 22 нче мотоукчы бригадасы танклары 1945 елның 23 апрелендә беренчеләрдән булып Берлин урамнарына барып керә. Шул сугыштагы осталыгы һәм батырлыгы өчен милләттәшебез Советлар Союзы Герое исеменә лаек була. Подполковник Исхак Гомәров полкы да Берлин урамнарындагы сугышта дан казана. Аның полкы дошманның Империя канцеляриясен зур югалтуларсыз сугышып алганы өчен И.Гомәровка чираттагы югары дәрәҗәле орден тапшырыла.

Китап авторлары сугышның беренче көннәре турында материаллар туплауга, аларны ныклап анализлауга да күп көч куйган. Хезмәттә тарихи әдәбиятта моңарчы өстән-өстән генә якдыртылган фактлар нык конкретлаштырылган. Сугышның беренче айларындагы зур югалтуларның сәбәпләре уйландыра, борчу гына түгел, үзенә тапшырылган җаваплы эшне тиешенчә оештыра алмаучыларга карата нәфрәт тә уята: «Сугышның беренче көннәрендә үк *чик буенда урнашкан аэродромнарда – самолётлар, гаражларда килеш танк-машиналар күпләп юк ителә. Штабы*

РФ Президенты В.Путин Армия генералы Мәхмүт Гәрәевне Бөек Җиңү белән тәбрикли

ТР җитәкчеләре Бөек Җиңү көне уңаеннан Казанның Җиңү паркында

Минск каласында урнашкан Көнбатыш хәрби округы идарәсе беренче көндә үк төрле типтагы 738 самолетын югалта. Шуларның күпчелеге аэродромнарда килеш бомбага тотыла, – дип яза авторлар. – Әлеге хәлләрне чик сагында торучы кайбер гаскәр башлыкларының сугышны ярым-йорты әзерлек белән каршы алуын дошман якның ялган вәгъдәләренә ышанудан башлары әйләнү белән генә аңлатып буладыр, мөгаен».

Лирон һәм Булат Хәмидуллиннар хезмәтендә яу кырында барган вакыйгалар да, яңа төр самолёт, миномёт һәм башка коралларга мөнәсәбәтле фактлар да китерелә. Заманча корал белән тәэмин ителгән сугышчының яу кырында уңышка ирешәчәге шик тудырмый. Бу җәһәттән Татарстан халкы үзенә йөкләнгән бурычны уңышлы үтәп чыга. Армияне яңадан-яңа корал белән даими рәвештә тәэмин итеп тора.

Бөек Ватан сугышы тәмамлануга 71 ел вакыт үтсә дә, бик күпләр әле һаман да этиләренең, бабаларының кайтуын көтеп яши. Ни кызганыч, сугыш ветераннары сафы да елдан-ел сирәгәя бара шул. Киләчәктә сугыш дигән афәтне беребезгә дә күрергә язмасын икән. ■

Җәлил мирасы

Назирә Фәттахова, Ләйсән Харасова



1

Дорогие мои,
Нина и Чулпаночка!

Я вам вчера отправил два письма. Одно через почтовый ящик лагеря. Но это, говорят, очень долго доставляется. Другое, (коротенькую записку) через жену одного бойца. Но, сомневаюсь, отнесет-ли она к тебе его или нет. Поэтому вот уже третье письмо пишу, которое хочу послать через попутчика в город, где он опустит его в ящик.

Меня зачислили в артиллерию, конным разведчиком. Это в армии самая ответственная, самая сложная и опасная работа. Туда подбирают людей с большим образованием (надо иметь дело с оптическими приборами и высшей математикой) и надежных. Вот я и попал туда. Но плохо то, что я рядовой. Еще ни с кем не говорил, но хочу поговорить с командованием о том, чтобы меня быстро подготовили и сделали хотя-бы командиром орудия. Хотя-бы командиром орудия и положение было-бы лучше.

По всей вероятности нас здесь долго не будут держать. Как получат оружие, так пошлют. В Казани не отпускают. Поэтому очень боюсь, что я вас больше не увижу. К нам в лагерь каждый день несколько вот женщин

Муса Җәлилнең хатыны Әминә һәм кызы Чулпанга язган хаты. 1941 ел

«Моабит дәфтәрләре» белән дөньяга танылган герой-шагыйрь Муса Җәлилнең мирасы ТР ФАнең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында һәм ТР Милли архивында саклана. Шулай ук ТР Милли музееның Җәлил фондында да өч меңнән артык экспонат бар. Аларның бер өлеше Муса Җәлил музей-фатирындагы мемориаль экспозициягә куелган. Елдан-ел бу фонд төрле кызыклы экспонатлар белән тулылана бара.

Быел исә, Муса Җәлилнең тууына 110 ел тулуны билгеләп үткән көннәрдә, шагыйрьнең кызы Чулпан Җәлилова музейга үзендә саклаган кайбер әйберләрне тапшырды. Алар арасында аеруча әһәмиятлеләре – шагыйрьнең үзе исән вакытта ук гарәп графикасы белән татар телендә Мәскәүдә басылып чыккан «Иптәшкә» (1929), «Алтынчәч» (1941) (опера өчен либреттоның әдәби варианты) китаплары, 1941 елның 17 июлендә тормыш иптәше Әминә ханым һәм кызы Чулпанга язган 1 хаты, М.Җәлилгә Әхмәт Ерикәй язган 3 хат. Калган 6 хатта сүз Шәйхи Маннурның «Муса» романы турында бара.

«Алтынчәч» либреттосының әдәби варианты аеруча кызык. М.Җәлилнең бу әсәрне озак язганлыгы мәгълүм. ТӘһСИ Мирасханәсендә аның уннан артык варианты саклана. Китап форзацының өске уң як почмагына гарәп хәрефләре белән «Җ.Фәйзи» дип теркәлгән. Алга таба да һәр биттә карандаш белән язылган байтак төзәтмәләр бар. Аларны кем язганын төгәл генә әйтеп булмый. Җәлил булуы да мөмкин…

Шагыйрьнең 1941 елның 17 июлендә



«Алтынчәч» китабы.
1941 ел

«Иптәшкә» китабы.
1929 ел



Кадерле Муса дус!

Киткән чакта сине күрә алмадым. Әле ничек җирләр кибәет китте. Сара миндә „Галиябануны" басып бирде. Оригиналын һәм бер данасын үзем белән алып киттем. Синдә дигән ике данасын Имамутдиновка калдырдым. Ләкин ул экземплярларны укырга өлгерә алмадым. Бер барганда укып китәрмен. Син аның берсен Музафаровка тапшырсаң бик шәп булыр иде. Москвада яңа хәбәрләр юк шикелле. Көннәр бик матур айдың.

Әминәгә һәм кызыңа сәлам.

12/VI-41 Әхм. Ерик.

Б. Калужская 9, 16
кв. 55

Әхмәт Ерикәйнең
Муса Җәлилгә
язган хаты.
1941 ел

язылган хаты гаиләсенә хәрби лагерьдан җибәрелгән. Хат дүрт биттә, карандаш белән рус телендә язылган. Анда Муса үзенең артиллериягә атлы разведчик итеп билгеләнүе турында хәбәр итә. Билгеле булганча, бу армиядә җаваплы, катлаулы хезмәт саналган, чөнки оптик приборлар һәм югары математика белән эш итәргә кирәк булган. *«Мин артиллерияне яратам, артиллериядән китәсем килми, ләкин рядовой булып түгел: югары белемле, партия стажым зур, партия-комсомол җитәкчелеге эшендә зур тәҗрибә тупланган, 22 еллык әдәби стажы булган зур шагыйрьләрнең берсе, ВЛКСМ Үзәк Комитетының элекке работнигы, хәзер дә җаваплы партработник, депутат буларак, ВКП(б) Өлкә комитетында учетта торам. Шулай булгач, армиядә мине рациональрәк файдаланып булмыймыни – политсостав яки начсостав итеп?»*, – дип яза ул.

Алга таба гаиләсен кайгыртып: *«Сезнең материаль хәлегез ничек? Безнең литфондта мобилизованныйларга билгеле күләмдә акчалата пособие бирәләр. Син Әхмәт Исхак белән сөйләш һәм ул акчаны ал»*, – дип тә өсти. Хатта шулай ук: *«Минем сезне күрәсем килә. Якшәмбе көн килегез яки үзең генә кил! Мин инде көн-төн Чулпанны сагынам, аны юксы-*


Отв.Секретарю Союза Советских Писателей Татарии

тов.М.ЗАЛИЛОВУ.

В виду ряда семейных и иных обстоятельств я в данное время нахожусь в исключительно тяжелых жилищных условиях.В данное время я никакой жилплощади не имею.Прошу,тов.Залилов,оказать мне содействие в получении жилплощади в Москве,т.к.отсутствие жилья окончательно выбивает меня из колеи и лишает возможности заниматься творческой работой.

С просьбой: (Ахмед ЕРИКЕЕВ)

24/1-40

Әхмәт Ерикәйнең Муса Җәлил исеменә язган үтенече. 1940 ел

нам. Аңардан аерылып китү ничек авыр», – дигән юллар да бар.

Фондка алынган өч хатны Муса Җәлилгә Әхмәт Ерикәй җибәргән. 1939 елны каләм белән язылган беренче хатта көндәлек вакыйгалар турында сүз бара. Ә.Ерикәй Казанга кайтып киткән Мусаны сагынуын, күрәсе килүен, Мәскәүдә эч серләрен сөйләрлек кеше калмавын ассызыклый. Икенчесе – рәсми хат. Ә.Ерикәй 1940 елның 24 гыйнварында Татарстан Язучылар берлегенең җаваплы сәркатибенә Мәскәүдә фатир алырга ярдәм кылуны үтенеп мөрәҗәгать итә. Өченчесе исә 1941 елның 12 июнендә дәфтәр битен урталай ертып, карандаш белән юлларга аркылы язылган. Хатта бары тик бер генә мәсьәлә күтәрелә – «Галиябану» либреттосының күчермәләре. Имаметдиновта калдырылган ике экземплярның берсе Мусага, ә икенчесе Мозаффаровка тапшырылырга тиешлеге аңлатыла (либретто М.Фәйзинең «Галиябану» драмасы буенча Ә.Ерикәй тарафыннан язылга).

1947 елның 17 апрелендә Әминә һәм Чулпан исеменә Нәфисә (Нәфисә Сөнчәләева Татарстан Язучылар берлегендә секретарь-машинист булып эшләгән) тарафыннан язылган хат та игътибарны җәлеп итә. Ул рус телендә, машинкада басылган. Анда: *«...шушы көннәрдә чит ил эшләре министрлыгыннан Мусаның блокнотын алдык»*, – дигән юллар бар. Биредә сүзнең икенче Моабит дәфтәрләре турында барганлыгы аңлашыла.

Калган хатлар 1966-1967 елларда

Мирсәй Әмирнең Әминә ханымга язган хаты. 1967 ел



1

Хөрмәтле Әминә ханым !

Сезнең Язучылар Союзы правлениесе һәм нәшрият исеменә язып калдырган хатыгыз буенча түбәндәгеләрне хәбәр итәм:

Ш.Маннурның " Муса " романы Язучылар Союзы правлениесе утырышында тикшерелде. Утырышта нәшрият работниклары дә катнашты. Правление членнары романның байтак кимчелекләре булуын әйттеләр, бигрәк тә беренче кисәкне ныклап эшкәртергә кирәклекне күрсәттеләр. Шул ук вакытта сөйләүче иптәшләр Сезнең хатыгыз белән дә тулысынча килешеп бетмәүләрен белдерделәр. Сез хатыгызда романның беренче кисәген / 6 главасын / бөтенләй сызып ташларга кирәк, дисез. Фикер алышуда катнашкан иптәшләр беренче кисәктә Муса образын җанландыруга, аны тулыландыруга ярдәм итә торган әһәмиятле глава һәм эпизодлар барлыгын әйттеләр. Аеруча Мусаның лагерьда Әминә һәм Чулпан белән очрашу эпизодын, Минзәләдә уку чорын тасвирлаган, Актабановка бәглы булган, Ш.Камал белән саубуллашу һ.б. кайбер урыннарын күрсәттеләр.

Шуның өчен правление, нәшрият һәм автор Сезнең моңа карата булган фикерегезне беләргә телиләр. Беренче кисәктәге кайсы моментларга каршы булуыгызны конкрет күрсәтеп җибәрсәгез әйбәт булыр иде. Автор шул замечаниеләр буенча эшләргә нияте барлыгын белдерде.

Сезне һәм Чулпанны матур Яз бәйрәме – 1 нче май белән котлыйм, һәр кайсыгызга исәнлек – саулык, эшегездә, тормышыгызда уңышлар теләп калам.

М. ӘМИР

28.1У-67 ел.

язылган. Аларда сүз «Муса» романының беренче бүлеге турында бара. Билгеле булганча, 1959-1965 елларда язучы Шәйхи Маннур танылган шагыйрь Муса Җәлил хакында күләмле «Муса» романын иҗат итә. Ул 1965 елда «Казан утлары» журналында, аннан соң 1968 елда аерым китап булып дөнья күрә. Хатларның эчтәлегенә караганда, шагыйрьнең гаиләсе романның бу вариантын кабул итми һәм нәшрият аларның фикерен истә тотып, журнал вариантында да, китапта да беренче бүлекне төшереп калдыра. Филология фәннәре докторы Рәмил Исламов шагыйрьнең тууына 110 ел тулу уңаеннан оештырылган Халыкара конференциядә: *«Күләме 3-27 битләрне тәшкил иткән һәм төшереп калдырылган беренче кисәк нидән гыйбарәт соң? Ул – яшь Мусаның Мәдинә исемле кызга мәхәббәте турында»*, – дип чыгыш ясавын искә төшерик.

Күргәнегезчә, хатлар шагыйрь тормышындагы кайбер вакыйгаларны ачыкларга ярдәм итә. Бу чыганаклар булачак экспозицияләрдә һәм күргәзмәләрдә дә халыкка тәкъдим ителер, дип ышанабыз. ■

«Әби патша» каретасы

(ТР Милли музее фондларыннан)



Патшабикә Екатерина II 1767 елда Идел буенча сәфәре вакытында 5 көн Казанда була. Язма чыганаклар хәбәр иткәнчә, «Әби патша» шәһәр буенча каретада йөргән, ә аннары экипажын Казан һәм Зөя архиепископы Вениаминга бүләк итеп калдырган. Карета

1896 елдан шәһәр музеенда саклана. Гасыр дәвамында үз төсен югалткан ядкярне 1987 елда төзекләндерергә карар кылалар. Карета, фәкать 16 елдан соң гына, реставрацияләнеп музеебызга килүче кунакларга күрсәтелә башлады. Мәскәү белгечләре, җентекле рәвештә эшләп, аңа әүвәлге зәвыкны, затлылыкны кайтарды. Бүгенге көндә карета музей залларының берсен бизәп тора. Аның бронзадан ясалган күчерелмәсен башкалабыз Казанның Бауман урамында күреп тә хозурлана аласыз.

***Гүзәлия Җәләлева** әзерләде.*

Фоторәсемнәр ТР Милли музей архивларыннан алынды. ■

Миллият сүзлеге

Адлер Тимергалин

ӨММӨГӨЛСЕМ (I) – Мөхәммәд Пәйгамбәрнең өченче кызы. Сөнгатулла Бикбулат Өммөгөлсем «Гутайбә ибн әбү Ләһәбкә кияүгә чыккан булса да, «Тәббәт» сүрәсе иңгәч, талак кылынды», – дип яза. Мәгълүм булганча, бу сүрәдә (111) Мөхәммәд Пәйгамбәрнең явыз дошманы Әбү Ләһәбкә һәм аның хатынына ләгънәт укыла. Шушы сүрә иңгәннән соң, Өммөгөлсем кияү куенына кермәгән килеш талак кылына һәм, апасы Рокыя вафатыннан соң, Госман хәзрәтләренең җефете була. Чыганакларга караганда, Рокыя да Әбү Ләһәбнең Готбә исемле улында кияүдә булган һәм ата-анасы кушуы буенча ире Готбә аны талак кылган. Сөнгатулла Бикбулат язган Гутайбә һәм Гутбәләр (Готбә) бер үк шәхес булсалар кирәк. Өммөгөлсемнең вафаты – Һиҗрәнең тугызынчы елында (миляди белән 631 елда, Пәйгамбәрнең вафатыннан бер ел элек). Әнәс бине Маликтан килеп ирешкән бер хәдистә Өммөгөлсемне җирләгән вакытта Пәйгамбәр кабер читенә утырып җылаган һәм шундагы кешеләрдән: «Арагызда бу төнне хатын-кызга якын килмәгән кеше бармы?» – дип сораган. Әбү Тәлһа: «Мин», – дигәч, Пәйгамбәр аңа кабергә төшәргә һәм мәетне уң ягына борып яткырырга кушкан.

Кайбер чыганакларга караганда, Өммөгөлсем исеме аңа улы Күлсум туганнан соң бирелгән, ягъни Күлсумның анасы дигән мәгънәдә. Төрки халыклар Өммикүлсум исемен кыскартып, Күлсум исемен кыз балаларга куша башлаганнар, тора-бара ул, «гөл» сүзенә нисбәт ителеп, Гөлсемгә әйләнгән. Ә чынлыкта ул «түгәрәк йөзле» мәгънәсендә булып чыга.

ӨРӘК *тар.* – Гарәпчә *әрвах* сүзеннән (*рух*-ның күплек саны). Каюм Насыйриның *өрәк* сүзен *өрмәк*-кә кайтарып калдыруы нигезләнми. Чуаш телендә өрәк – *ерех*. Русча – *призрак*, тагын чит ил сүзе *фантом* күзәтелә, ләкин анысы җансыз нәрсәнеке дә булырга мөмкин.

Өрәк – татар мифологиясендә явыз рух. Ул көчләп үтерелгән кешенең үлгән җирендә, йә булмаса кеше каны агызылган урында очрый, гадәттә катыйль кылынган кешенең гүре өстендә күренә. Кешеләргә ул күп усаллык тидерми. Өрәк якын килсә, әшәке сүзләр белән сүгенергә генә кирәк, шуннан башка аны куркытып та булмый имеш. Борынгы татарлар кешенең җанын

*Дәвамы. 2014 елның 3 нче саныннан басылып килә.

өрәк дип атаганнар (*җан* – фарсы сүзе). Димәк, өрәккә ышануда борынгы бабаларыбызның исламгача булган төшенчәсе чагыла.

Галимнәр арасында «өрәк» кайчандыр хатын-кыз җенесеннән яхшылыклы тәңре булган, матриархатка алмашка патриархат килгәч кенә явыз һәм үчәш тәңрегә әйләнгән, дигән фикер дә бар. Патриархат заманында төркиләр каүмендә бөтен яхшылык символы котта тупланган. «Өрәк – үлгән кешенең җаны, кот – эмбрион, ягъни тереклекнең, яңарышның башы». («Татары Среднего Поволжья и Приуралья», М., 1967.)

Тевриз яклары сөйләшендә – *купкын*.

Гайре фәнни лептон теориясе буенча, өрәкләр *(фантомнар)* «уйформалар»дан гыйбарәт булып, *лептон* дип атала торган үтә вак микрокисәкчекләрдән торалар имеш.

Америка тикшеренүчесе Луиза Райн өрәкләр күзәтелгән 8000 очракның фәкать берсен генә галлюцинация нигезендә аңлата алмаган. Өлкән яшьтәге кешеләрнең яртысы диярлек үзләренең мәрхүм ирләрен яки хатыннарын күрүләре яки аларның тавышын ишетүләре турында хәбәр иткәннәр.

ӨСТӘЛ – *Өстәл* – татар сүзе түгел, төрки сүз дә түгел. Ул Е.Н.Шипованың «Словарь тюркизмов в русском языке» дигән сүзлегенә теркәлмәгән, ә рус телендә ул бик борынгыдан ук күзәтелә. Әйтик, *стольный град* – башкача: *столица*; тәхет шәһәре, пайтәхет, тәхетгяһ. «Столовая» сүзендә дә катнаша. «Столовые горы» терминында ул өстәл сыман яссы мәгънәсен бирә. «Стол» күпчелек славян телләрендә (поляк, чех, словен һ.б.) бар, кайбер Көнбатыш Европа телләрендә (нимес, инглиз, исланд) охшаш сүз «урындык», «табуретка», «эскәмия» мәгънәсендә йөри. Тагын шунысы кызык, яссы геометрик дүртпочмаклыкның бер төре *трапеция* дип атала (1931 елгы «Татарча-урысча сүзлек»тә трапеция термины геометрик фигура буларак *таганнык, таганлык,* ягъни атынгыч, таган/даган дип аңлатылган). Трапеция сүзе латинча өстәл мәгънәсендәге «трапезиум» сүзеннән (русча «трапеза» сүзе дә шуннан килә). Борынгы рәсемнәрдә өстәлнең (өстәл өстенең) трапеция рәвешендә сурәтләнүен, ләкин перспективаның киресенчә (!) булуын (өстәлнең безгә якынрак кыры аргысыннан озынрак итеп түгел, бәлки кыскарак итеп күрсәтелүен) искә төшерик.

Төрек телендә өстәл – *маса* һәм *софра* сүзләре белән бирелә. Соңгысы татар телендә сөфрә (гарәпчәдән) рәвешендә очрый; аш өстәле, табын, ашъяулык, тастымал мәгънәләренә ия. Ибне Фазлан сәяхәтнамәсендә (921-22 еллар) борынгы болгар патшасы Алмыш хозурына килгән гарәп илчеләрен сыйлаганда һәрбер кунак каршына шундый тәбәнәк өстәлчек (табынлык, сөфрә, *дәстүрхан?*) китереп куюлары турында сөйләнә. Себер татарлары диалектында *урын өстәл* – сәке өстенә куела торган тәбәнәк өстәл, дәстүрхан. Шуларда ук «өстәл» сүзенең *урындык* мәгънәсе дә бар (Д.Г.Тумашева).

Кануни шәригатьтә өстәл телгә алынмый, табын гына бар.

Бездә элекке мәдрәсәләрдә парта хезмәтен үтәгән озынча тәбәнәк өстәлне *көрси* дигәннәр. Бу хакта Җамал Вәлиди: *«Алар [мөселманнар] Аурупаның өстәлен, партасын да аякларын кисеп кенә кабул иттеләр»*, – дип яза.

Фарсыдан кергән *сандалия* сүзе тумбочка сыман өстәлне белдергән.

«Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә теркәлгән *чәһарпая* сүзенең мәгънәләре: 1) Урындык. 2) Өстәл (дүртаяклы әйбер).

Борын заманда татар өендә өстәл урынына сәке (түрсәке һәм янсәкеләр) хезмәт иткән.

Электә дворян йортларында кунак җыйганда барысын да утыртып бетерү өчен ясалган бик озын өстәлләрне руслар «кырык аяклы өстәл» («стол-сороконожка») дип атаганнар.

Рус телендәге «рундук» сүзе («зур сандык» мәгънәсенә ия, башка мәгънәләре дә бар; корабльдә чылбыр җыештырып куела торган әрҗә) татарча «урындык» сүзеннән килә дип саныйлар. Шул рәвешле, без руслардан «өстәл» сүзен алган булсак та, күрәмсең, гел үк бушка алмаганбыз, аларга рундук/урындык биргәнбез икән.

Озын сүзнең кыскасы, көнбатыштан килгән «стол» сүзенә хуҗа булырга, аңа кәләпүш кидереп, русча «столяр» сүзен татарча «осталар» сүзеннән чыгарып маташмаска иде (борынгы кульъязма сүзлекләрдә «столяр» мәгъәсендә «кырмачы» сүзе теркәлгәнлеген әйтеп китик (русча «токарь» мәгънәсенә тарта шикелле); «Гарәпчә-татарча-русча алынмалар сүзлеге»ндә *дөрудгәр* – балта остасы, столяр сүзе теркәлгән). Шагыйрь әйтмешли, «без болай да бәләкәй түгел».

«Өстәл» сүзе европалыларга гына түгел, безгә – евроазиатларга да карусыз хезмәт итә һәм итәчәк.

//Кухня өстәле. Канцелярия өстәле. Язу өстәле. Түгәрәк өстәл.

ӨСТӘЛ БИЕТҮ – Спиритизмның бер формасы, үлгәннәрнең җаннары белән сөйләшү. Мондый хорафат XIX гасырда киң таралыш алган. Русчасы – *столоверчение*.

Кара: ***Спиритизм.***

ӨТЕР г. – Борынгы төркичәдә: өтүр, өтүрү – «аннан соң, аннары» мәгънәсендә (бәйлек). Ягъни бүген тыныш билгесе генә булган өтер асылда кыскартылма булып чыга. Р.Әхмәтҗанов «өтер» сүзен гарәпчәдән дип саный. Иске әдәбиятта «өтер» мәгънәсендә *виргел* сүзе очрый . ■

Сүзләр картаямы?..

Рашат Низами

Ай белән тургай
картаймый, алар гел булачак...
Ибраһим Гази

Үенчык калейдоскоп кулга тотып әйләндергәләсәң генә хәрәкәткә килә, үзгәреш арты яңа сурәтләрне китереп чыгара. Сүзне хәрәкәткә китерүче, аны туендырып торучы көч — җәмгыять.

Сүз – социаль-иҗтимагый тормышка турыдан-туры бәйле. Алыйк безнең эрага кадәрге борынгы чорны. Әле бернинди цивилизация — авыллар, шәһәрләр юк, промышленность һ.б. юк. Бары мәгарә тормышы... алачыклар тезмәсе... кабиләләр оешу... аннары инде ашау-яшәү, биләмәләр өчен көндәшлек барлыкка килү (эволюция!). Без борынгы бабаларның иң беренчел сүзләрен-сөйләмнәрен белә алмаячакбыз, билгеле. Һәрхәлдә, алар җиргә, суга, утка, ташка, эш коралларына бәйле булгандыр.

Безгә шактый якын тарих — патша заманнарында никадәрле яңа сүзләр «сәхнәгә» менгән! Бу яңа кискен борылыш татар теленең сүзлек составында да киң чагылыш тапкан. Иренмәстән, аларның истә калганнарын бер җепкә тезеп чыгасы килә: дворян, купец, губернатор, кантон, өяз...

Ике сүзнең «феномен»ына гына аерым тукталасы килә.

Фермерлык хуҗалыклары беренчеләрдән булып XIV гасырда Англиядә оеша башлый. «Фермер» сүзе шул вакытта барлыкка килә (француз теленнән ясалган — аренда, түләү дигәнне аңлата). Бактың исә, аның төп нигезләрен үзенең фәнни хезмәтләрендә безнең академик Чаянов язып калдырган була.

Шунысы кызык һәм контраст: безнең өчен югалган, инде тәмам онытылган «фермер» сүзе, һавадан төшкән кебек, авыл хуҗалыгы тормышына ялт итеп әйләнеп кайтты! Хәзер авылларда фермерлыкны бик тә үстермәкче булабыз, әмма йөз ел чамасы вакытны суга салганбыз икән шул...

«Губернатор» сүзен дә әнә шундыйрак язмыш сагалап торган икән, фаразан. Большевиклар бу сүзне кырып-себереп тарих сәхнәсеннән алып ташлаган иде. Вәләкин, «обком секретаре» дигән вазифа үзенең яшәвен-мәгънәсен югалткач, шушы буш урынга Мәскәү көчләп диярлек «губернатор» сүзен тагып куйды. Совет заманында тәрбияләнеп үскән менталитетка никадәр ят тоелмасын, әлеге сүзгә кешеләр һәм җәмгыять инде ияләшеп килә.

Сүзебезне дәвам итеп, безнең буынга яхшырак таныш булган совет чорына таба якын килик.

Совет чоры тел составын баетуга («чуарлауга» дип әйтсәк тә була) шулай ук шактый өлеш кертә. Бу аңлашыла: чөнки революция давылы, аннары инде социализм һәм коммунизм төзү идеяләре җәмгыятьнең барлык катламнарына тирән үтеп керә, өр-яңа сүзләр һәм атамалар сорый. Галимнәр билгеләп үткәнчә, актив лексика телдә туган яңа сүзләр исәбенә туктаусыз тулыланып, баеп тора. Мәсәлән, аклар, кызыллар, инкыйлаб, ликбез, кызыл почмак, күмхуҗ, нэпман, райком, сельсовет, председатель, секретарь, бухгалтер, партия, юлбаш-

чы, мәктәп, пионер, комсомол, вожатый һ. б. Шушы типтагы неологизмнар тора-бара халыклашып китә һәм актив сөйләмгә күчә.

Шиксез: совхоз, колхоз, колхозчы дигән сүзләр пассивлашып, сөйләмнән төшеп калып, тарихта гына үзләренә урын алачак, билгеле. Ә менә «коммунизм» сүзе, минем уйлавымча, үзенең урынын, кешелек аңында ныгып калган позициясен тиз генә бушатырга ашыкмастыр. Коммунизм идеясе үзенең асыл табигате белән, һәрхәлдә, яхшылыкка, матур киләчәккә таба өнди.

Заманалар алга барган саен неологизмнар һаман саен үрчеп-туып тора. Моның иң ачык мисаллары: космонавт, космодром, атомщик, программист, компьютер, интернет, сайт, кредит, менеджер, дизайнер, ипотека, маркетинг... Хәзер аларның укыганда яки әйткәндә телеңне сындырырдай һәм тиз генә аңлашылмый торган «кәттә»ләре дә очрап куя әле.

Сүз башым бит Шүрәле дигәндәй, без бит «сүзләр картаямы?..» дигән сорауга җавап эзләргә тиеш идек.

Тарихта сүзләр эволюциясе булганмы — булган, моны исбатлау кыен түгел. Тел — тере организм кебек: туа, яши һәм үлә дә... Борынгы латин телен, әнә, үле тел, дип исәплибез. Үз заманында никадәр куәтле, дәрәҗәле тел саналган ул! Латин теле ни өчен үлгән соң? Мин бу сорауга җавап бирергә әзер түгелмен, укучы мине гафу итсен. Хәзер үле телләрдән саналса да, ул бөтенләй үк юкка чыкмаган. Бүгенге көнгә кадәр медицинада һәм фәннең төрле тармакларында (барыннан да элек термин буларак) «гөрләтеп» яши, кулланылышта йөри.

XVIII гасыр азакларында Европада шундый бер вазгыять килеп туа: әдәбиятта, барыннан да элек проза жанрында, аерым алганда, канцелярия һәм физика, математика, химия, экономика фәннәре буенча махсус сүзләр-терминнар уйлап табарга кирәк була. Аңа кадәр болар барысы да латин телендә гамәлдә йөргән. Милли үзаңның уянуыдыр, күрәсең: устав, декрет, боерык дигән формулировкаларны һәм андагы җөмләләрне һәр халык, һәр дәүләт, һәр милләт үз телендәге чаралар ярдәмендә бәян итә башлый. Менә шуның нәтиҗәсе буларак, XIX гасырда Еврпоа, рус һәм татар әдәбиятында да өр-яңа тел катламы күтәрелә, жанр һәм тел байлыгы ягыннан яңа бер сикереш ясала.

Күрәбез: агачлар ел саен яфракларын алмаштырган кебек, гасырларны кичә торгач, күп кенә иске сүзләр дә, ирексездән, өр-яңа кардәшләренә юл бирә башлый. Шул ук вакытта кайбер иске сүзләр, өрфия «күлмәк» ябынып, яңадан тел-сөйләш-язу мәйданына кабат әйләнеп кайта. 1990 нчы еллар башында Татарстанның суверенитеты игълан ителгәч, милли хәрәкәт аеруча куәт алган елларда, моның мисаллары бик нык артты: икътисад (экономика), сәясәт (политика), җөмһүрият (республика), сәнәгать (промышленность), мөхәррир (редактор), союз (берлек) һ.б.

Бүгенге татар әдәби теле халык теленә бик якын. Бу дөрес гамәлдер, шулай булырга тиеш. Борынгы, иске сүзләргә астөшермәләр (аңлатмалар) бирү Хәйям, Тукай, Дәрдемәнд әсәрләрен нәшер иткәндә аклана. Әдәби әсәрләрдә иске сүзләрне куллану тенденциясе көчәеп китте шикелле: әйтик — фәләк (фәрештә), сөхбәтләшү (киңәшү), сәмави (илаһи), кария (авыл), мәүзуг (тема), шәкел (форма), инкыйлаб (революция), инсан (кеше), тәфтиш (шәрехләү), һәдия (бүләк) һ.б. Әнә шундый сүзләр уңышлы кулланыламы — укучы үзе әйтсен. Икенче караганда, әгәр татарча бик яхшы аңлашыла торган халыкчан сүзләребез

бар икән, нигә әле телне чуарларга? Без бит халыкка хезмәт итәбез. Киң катлам халык массаларына аңлашылмый, «барып җитми» торган сүзләр белән эш иткәндә шулай ук чама хисе кирәк.

Архаизмнар, ягъни искергән атамалар (ислах — реформа, шивә — диалект, мөгаллим — укытучы) халык телендә шулай ук киң чагылыш тапмый. Боларны көндәлек матбугатта, барыннан да бигрәк фәнни һәм әдәби кулланылышта очратырга мөмкин. Минем үземә, мәсәлән, мөхәррир сүзенә караганда латин теленнән кергән редактор (redactus) сүзе күбрәк ошый. Республика сүзе дә — латиннан (менә сиңа үле тел!). Бу сүзләр, чарлана торгач, тәмам интернациональләшкән, халыклашкан, алардан кача алмыйсың.

«Спорт» сүзенә дә тукталыйк булмаса. Без матбугатта көн саен укый, телевизордан көн саен ишетә торган бу популяр сүз этрусклардан (римлеләрнең борынгы токымы) килә. Бик тә заманча яңгырый торган әлеге сүзнең яше — өч мең еллар тирәсе.

«Эгоизм» сүзе фәкать XVII гасырда француз һәм инглиз телләрендә күренә башлый. Кызык бит: тормыш-яшәештә эгоизм күренеше аңа кадәр дә мәңге яшәп килгән. Бу күренешкә бирелгән атама исә тел составына никадәр вакытлар соңарып килгән!

Тел картаямы, дидек. Картаер өчен иң әүвәле туарга кирәк бит әле. Бу урында ирексездән икенче бер сорау да ярала: ә тел хәзинәсе ни хисапка баеган соң? Артык җәелмичә һәм мисаллар белән мавыкмыйча, төп чыганакларын санау белән чикләнәм:

1. Татар теленең үз сүзләре, үз фонды җирлегендә туган хәзинә.

2. Чит һәм кардәш телләрдән кергән сүзләр (гарәп, фарсы, инглиз, француз, немец, грек, латин, итальян һ.б.).

Татарлар географик яктан һәрвакыт диярлек Гареп белән Шәрык урталыгында яшәгәннәр, «тел вә лөгать алмашканнар». Икенче чыганакта без моның ачык чагылышын күрәбез.

Безнең телдә рус теленнән кергән алынмалар да байтак. Күпләр, бигрәк тә филолог галимнәребез, аларның рус теленнән кергән килеш язылуын тәнкыйть итәләр. Уңышлы һәм телебезгә ярашлы дигәннәрен нигә әле кулланмаска? Тупас яисә авыр яңгырый торганнарын үз телебезгә тәрҗемә итү дә бик мәслихәт. Әйтик, шайба — алка, болельщик — җанатар, вертолет — боралак. Ә инде заманында «колхоз» сүзен «күмхуҗ» дип аударырга тырышулар бары ирония тудыра.

Тарихи «декабрист» сүзен «декабрьче» дип тәрҗемәләү дә көлке тудырыр һәм аңлашылмас иде.

Моннан егерме-утыз еллар элек Бразилиянең «Рабыня Изаура» сериалын караганнан соң, бездә «фазенда» (бакча дигәнне аңлата) сүзе сөйләм теленә кереп киткән иде, әмма ул озын гомерле булмады шикелле...

Кемнәрнеңдер эсперанто дигән ясалма телне гамәлгә куярга тырышуы миндә бары гаҗәпләнү уята. Әгәр Җир шарында бер генә тел калса, бу — кешелекнең иң зур хатасы булыр иде. Урман-кырлар һәм болыннарның бөтен матурлыгы — андагы агачлар, чәчәкләрнең күп һәм төрле булуында лабаса!

Бүлекнең азагын, әдип Ибраһим Гази фикеренә таянып, болай тәмамлыйсы килә: «Ай, тургай, сүзләр картаймый, алар гел булачак...» ■

قوياش

«Кояш» газетасында «Казан хәбәрләре»: 1916 елның июнь ае

Текстны һәм искәрмәләрне басмага Ленар Гобәйдуллин әзерләде.

Мосафир

Петроград дарелфөнүненең [университетының] приват-доценты мөстәшәрык [шәрык белгече] Александр Николай углы Самойлович җәнаплары шәһәребездә мосафирдыр. Ул Петроградның Александр III нче музәханәсе[1] тарафыннан авыл татар хатынының борынгы киемен табып, музейга алыр өчен җибәрелгән.

Кояш. — 1916. — №975. — 2 июнь.

Мелла Габдулла Апанаевтан

Ошбу сәнә утын кыйммәт булу гына түгел, тәмам утынга аптырап калу ихтималы булдыктан тирестән утын әзерләргә эшчеләр китердем. Һәрбер мөселманнардан, аеруча двор тотучылардан тиресләрен, ике бистә арасындагы дамба берлән барып, букчылар китә торган юл чатына, уң якка, су янына илтеп салуларын үтенәмен. Дворникларга чәйлек бирелер.

Кояш. — 1916. — №977. — 7 июнь.

Тәгаен

Мөгаллим һәм хәрби цензор Миргаяз әфәнде ибне мелла мәрхүм Хәсән Иманаев җәнаплары матбугат баш начальнигының тәкъдиме буенча Дахилия вәзире [Эчке эшләр министры] тарафыннан Казандагы Матбугат назараты комитетының әгъзалыгына тәгаен ителгән. Миргаяз әфәнде җәнаплары – бу көнгә кадәр дә укыту ысуллары һәм тәхрирләре илә исеме танылган кешедер.

Кояш. — 1916. — №978. — 9 июнь.

Бер хәзрәт

Мөхбирегезгә мондый риваять ишетергә тугры килде: «Кояш»ның соңгы номерларының берендә басылган качак мөселманнарның рамазан өчен мәчет урыны сорап кылган мөрәҗәгатьләре Печән базары әһле арасында зур шау-шуга сәбәп булган. Моназарә [бәхәсләшү] сәбәпләренең нигезе бу мөрәҗәгатьтәге «Качак хатыннарының мәсҗедкә, имамның үз телләрендә сөйләгән вәгазьнәсыйхәтләренә ихтыяҗлыры» дигән сүз икән. Гавам [халык] өчен хатыннарның мәсҗедкә баруы өр-яңа бер мәсьәлә булып төшкән ки, гавамнең дини хисләре китеп, мөселман качакларның хәтта мөселманлыгында шөбһә тотуларга барып җиткән. Мәсьәлә саф дини булганлыктан, гавам, гадәтләренчә, фәтва эзләп хәзрәтләргә мөрәҗәгать итүне, шулай итеп моназарәгә чик куюны тиеш тапкан. Хәзрәтләребездән Ибраһим мелла хатыннарны мәсҗедкә җибәрмәү ягын яклап фәтва биргән. Гавамның моңа хилаф [каршы] ягы игътираз кылган [кире каккан]: «Рәсүлулла заманында хатыннарга мәсҗедкә барырга мөсагадә ителгән

---

* Даталар иске стиль белән бирелә.

[1] Хәзерге Рус дәүләт музее.

[мөмкинлек бирелгән] бит, шәригатебездә дә бу хакта ачык кагыйдәләр бәян кылынган бит, хәзрәт, сез аны ничек итеп рәд [инкяр] кыласыз?» Фәтвачы хәзрәт үзенең дәгъвасын болай исбат иткән: «Хәзер инде Рәсүлулла заманында эшләнгән эшләрнең һәммәсен эшләргә, шәригатьтә дөрес гамәлләрнең һәммәсен кылып бетерергә ярамый шул инде».

Кояш. — 1916. — №980. — 12 июнь.

Әбүбәкер әфәнде Терегулов

Табиб Әбүбәкер әфәнде Терегулов Казан дарелфөнүне хозурында табиб хәкиме (доктор медицины) имтиханнарын муаффәкыятьле [уңышлы] сурәттә биреп тәмам итте. Әбүбәкер әфәнде соңгы елларда Казан клиникасында ассистент иде. Моннан соң ул приват-доцентлыкка әзерләнәчәк.

Һиммәт ияләре дикъкатенә

Мөселман җәмәгасе, һәр елдагы гадәт буенча, хәбесханәләрдәге [төрмәләрдәге] мөселманнар өчен бу ел да ифтар вә сәхәр бирәчәкләр. Бу ифтар вә сәхәрлекләр иганә тарикынча [юлы белән] җыелып биреләдер. Изге таныган бу юлга ихсан итәргә [ярдәм] теләгән затлардан садакаи важибә вә нафиләләрен[2] Печән базарында Нургазиз әфәнде Хөсәеновка тапшыруны үтенәләр.

Кояш. — 1916. — №981. — 14 июнь.

Тизәк утыны

Г.Апанаев шәһәрнең хайван бугазлау йортыннан чыккан тиресне тизәк утыны ясарга сораган булган. Сыйххия [сәламәтлек саклау] вә байтария [ветеринария] комиссиясе бу тирестән тәҗрибә өчен утын ясарга мөсагадә [рөхсәт] итәргә вә беренче мәртәбәсендә ясалып чыккан утыннарны ягып карап, әгәр якканда күршеләргә сыйххия җәһәтеннән зарар китермәслек табылса, шуннан соң тизәк утыны ясарга мөсагадә итеп, бугазлау йорты якынында шундый утын ясарга Г.А.га мөсагадә итәргә карар кылган.

Качаклар мәсҗеде

Җәмгыяте хәйрияи исламиянең идарәсе мәҗлесендә, мөселман качакларның рамазан өчен мәсҗед урыны теләп Казан мөселманнарына мөрәҗәгате телгә алынган булган. Кыска бер аңлашыштан соң, мөселман качаклар Казан мөселманнары белән дини вә мәзһәби һич аермалары булмаганлыктан, мөселманнарда гомумән мәсҗед һәркем өчен ачык булганлыктан, аерым мәсҗед ачуга дагый [өндәүче] юк, дигән карарга киленгән вә һәрхәлдә качакларга махсус мәсҗед урыны табу яки тапмау мәсьәләсен качаклар комитеты хәл итәр, дигән фикергә киленгән.

Кояш. — 1916. — №983. — 17 июнь.

Сөембикә манарасы

Моннан ике ел элек төзәттерелә башланган Сөембикә төзәтелеп беткән инде. Беренче июльдән башлап сәяхәтчеләргә кереп карарга ачык куярга исәпләнәдер. Бу вакыткача манараны төзәтер өчен куелган агач бугач та тәмам алыначактыр. Манараны төзәтү өчен барлыгы 7 мең сум мәсариф [чыгым] тотылган.

Кояш. — 1916. — №984. — 19 июнь.

[2] Садакаи важибә вә нафиләләрен – түләнүе мәҗбүри һәм мәҗбүри булмаган сәдакаларын.

КӨЛКЕ КУА КИЛӘ...

Радик Фәизов (1931-2011)

ЙОМЫКЫЙ

Исеме Сибгат булса да, аны үзара Йомыкый дип кенә йөрибез. Ник дисәң, чынлап та йомыкый ул. Бервакыт тавышын күтәрмәс. Беркемгә авыр сүз әйтмәс. Борын астында ботка пешереп йөрер шунда.

Без – өйләнмәгән егетләр. Әллә ни аптырап торган юк. Получкадан соң ресторанга да сугылабыз, җыйналып та утырабыз. Ник, акчаны кешедән ким төшерәбезме әллә? Без кемнәрдән ким? Яшьлекнең рәхәтен күреп калыйк. Дөнья кайгысы сул якта торсын әнә... Шулай ич!

Йомыкый гына читтә. Йә кочагы белән китаплар ала, йә авылдагы эти-әнисенә бүләкләр җибәреп азаплана. Үгетли калсаң, авыз эченнән нидер мыгырдый башлый. Ата-ана рәхмәте гөнаһны кичерә, ди бугай. Хан заманындагы бу сүзне каян казып алган диген? Яшьлеген әрәм үткәрә шунда, җүләр.

Ә шулай да бәла аңа килмәде, миңа килде.

Беркөн, хезмәт хакы алып, тулай торакка кайттым. Тумбочкада кәгазь кисәге ята. Язуын укыган идем, кемдер бозлы кулы белән муенымнан кысып алгандай булды: «Фәлән йорт почмагындагы таш астына егерме сум акча саласың. Югыйсә... Милициягә дәшсәң – әҗәлеңне бездән көт! Балда».

Торараш булдым да калдым. Бу ни әкәмәт тагын? Каян килгән бу заманда бандитлар? Нәкъ менә Америка гангестрлары кебек кыланалар... Нишләргә?

Бүлмәдә китапка багынып утырган Йомыкыйдан башка җан иясе юк иде. Аптырагач, аның янына килдем. Язуны укуга куркып калды бичара. Көзге яфрак кебек калтырый. Җәт кенә үз тумбочкасын актарып ташлады. Юк, бандитлар Йомыкыйны җәлләгәннәр...

– Миңа нишләргә хәзер? – дим. – Киңәш бир!

– Ни әйтим мин? – ди. – Теләсәң нишлә. Бәлки, берәрсе шаяргандыр гына әле... – ди.

Бу куян юньле киңәш бирер дисеңме?

Шаярсалар, акчамны кире бирерләр, шаярмасалар, егерме сумга карап башымнан колак кагар хәлем юк. Илтим дә салыйм. Күргәне-күрмәгәне шул булсын...

Әмма бандитларның күргәне ул гына булмады әле. Икенче получкадан соң мин тагын егерме сумга «чакыру билеты» алдым. Өченчесеннән соң тагын... Тәмам изаланды кеше. Акчасы, анда-монда дигәндәй, әллә ни жәл түгел аның. Шул берике рәт ресторан ишегеннән кире борылып китәргә генә туры килде. Әмма менә хурлыгы... Иптәшләргә сөйләргә дә куркам. Милицияне читләтеп кенә үтәм хәзер.

Артымнан авызына пычак капкан бандит күзәтеп бара кебек. Юк, болай булса, расчёт алып, шәһәрдән үк чыгып ычкынмый булмас.

Дүртенче хезмәт хакын алып кайтсам, өстәлдә хат ята. Авылдан, әнидән. Кара тирләрем чыкты. Акча сорый инде! Әле тумбочканы ачкан юк, шулай да анда нинди кәгазь ятканын белеп торам инде... талыйлар! Хәзер инде уңлап-суллап талыйлар.

Хатны укый башлаган идем, чәчләрем үрә торды. Менә нәрсә язылган иде анда:

«Сөекле улым Камил! Инде бу айда акча салмасаң да ярар. Үзеңә авырлык килмәсен. Җибәргән акчаларыңа үземә шәл, атаңа пима, сеңелең Мөршидәгә күлмәк алдык. Синең ярдәмең ярап куйды. Сиңа тәүфыйк биргән өчен Аллага...»

Мин артык укый алмадым... башымны күтәрсәм, каршымда Йомыкый басып тора. Авызы колагыннан узып бара тегенең.

Тып итеп урыныма утырдым, телсез калдым.

Менә сиңа Йомыкый!

1965

Мәхмүт Хөсәен (1923-1993)

....

БУЙ БӘЛАСЕ

(Шаяру)

Акылым да бар, төс тә әйбәт кебек,
Әллә нишләп тик буй кечкенә,
Кызык хәлләр кайчак булып ала
Шуның аркасында еш кына.

Беркөн менә, кулга акча төшкәч,
Ирешергә уйлап морадка,
Билетка дип театрга барам,
Керәм, касса, басам чиратка.

«Менә җиттем инде», – дип торганда,
Бер милиционер килә каршыма,
Караш ташлый буй-сыныма минем,
Торышыма, өсте-башыма.

Үзе шунда мине читкә алып:
– Кичен йөрү сиңа ярамый,
Балакаем, бар, өеңә кайт! – ди,
Егет икәнемне аңламый.

Алай итеп, болай итеп карыйм,
Аңлаталмыйм үзенә һич кенә;
Нишләтим соң, янда паспорт та юк,
Бар хикмәте – буем кечкенә.

Кайчак шулай клубларга барам,
Чибәр-чибәр кызлар күргәлим,
Артларыннан тәпи-тәпи генә
Эзләренә басып йөргәлим.

Берсе шунда бер үк каравында
Үзәгемне өзеп җибәрә;
Бар уйларым, тупыл мамыгыдай,
Сиздермәстән аңа ияра.

Мин беләсем килә исемен аның,
Кем икәнен, кайда, нишләвен...
Хатым аша ныклап сүз куешам,
Очрашырга әйтеп кичләрен.

Барам. Кыз да килә, тик күрүгә,
Күзләремә текәп күзләрен:
– Ник абыең синең килмәде соң? –
Дип кырт кисә шунда сүзләрен.

Алай итеп, болай итеп карыйм,
Аңлаталмыйм үзенә һич кенә;
Нишләтим соң, янда паспорт та бар,
Бар хикмәте – буем кечкенә.

1965

ТАЯК

(Халык мәзәге)

Бер байның алтын белән бизәлгән таягына кызыгып, ике угры берничә көн күзәтеп йөри. Ләкин кулга төшерә алмыйлар. Ниһаять, беркөнне теләнче киеме кигән берәү, чатанлап, байга каршы чыгып, аннан сәдака сорый. Яхшы кием киенгән икенчесе, байга карап:

– Берүк сәдака бирә күрмә! Бу бер хәйләкәр адәмдер. Юри ялганлап, чатанлап йөргән була. Бир әле таягыңны! – дип, бай кулыннан таякны алып кизәнгәндә, теләнче бар көче белән йөгерергә тотына. Бусы да аның артыннан куа китә. Бай башта гаҗәпләнеп, көлеп карап торса да, икәве күздән югалгач, таяктан колак какканын аңлый...

Халит Кумысников

БИШЕНЧЕ КЛАСС БУЛМАГАНГА

Габдулла Кариев ярлы булса да мәгърур кеше булган, дип сөйлиләр. Аның спектакльләрендә көлкегә калганнар Кариевны бик өнәп бетермиләр икән.

Бервакыт Габдулла Кариев, арзанлы гына урынга билет алып, пароходта утырып, каядыр бара икән. Өске катта кесәсе калыннар шәйләнә. Анда ашауэчү дә, күңел ачу да башка.

Өстәге байбәтчәләрнең берсе, атаклы артистны танып, кычкырып җибәрә:

– Һәй, Абдулла әфәнде, син бит татарның мәшһүр артисты, син бит безнең зур талантыбыз, нишләп син шундый хөрмәтле башың белән дүртенче класста барасың?

– Бишенче класс булмаганга! – дип җавап биргән ди Габдулла Кариев.

18 октябрь, 1981 ел

(Р.Батулланың «Тузга язмаган хәлләр» китабыннан).



Шамил Маннап (1938-2012)

ҮҖӘТЛЕКНЕҢ ҮЛЧӘҮ БЕРӘМЛЕГЕ

Дөньяда һәрнәрсәнең үлчәү берәмлеге бар. Әйтик, авырлыкны граммнар, килограммнар... белән, озынлыкны метрлар, сантиметрлар белән, мәйданны квадрат метрлар... һәм башка берәмлекләр белән үлчиләр. Ә үҗәтлекнең үлчәү берәмлеге бармы? Бар икән. Ышанмасагыз, милләтпәрвәр язучы, бәхәстә һичберкемгә баш бирмәс, үз сүзеннән бер миллиметр да

чигенмәс Зәки Зәйнуллиннан сорагыз. Ул болай сөйләр:

– Ригадагы мин укыткан хәрби училище начальнигы болай ди торган иде: «Сила электрического тока – один ампер, сила сопротивление электрической цепи – один ом, а упрямство измеряется так: один Зайнуллин...

1998 ■

Мирасворд

Ашлык, кибәк ташу өчен кабыктан ясалган зур әрҗә

Кәлтә, аждаһа (иск.)

Компози-тор ... Мөлеков

Урта гасыр Идел буе Болгары шәһәре

Сибгат Хәким поэмасы

Сәйдәшев, Баттал

Грек хәрефе

Алдан бара торган гаскәр, авангард (бор.)

Ханлык чорында дәүләт аппа-ратындагы югары чин

Грек мифологиясендә тугыз музаның берсе

Вальтер Скоттның тарихи романы

Аның хәлен тук белми

Галимҗан, Кави

Ризаэддин Фәхреддин-нең тарихи-библиог-рафик хезмәте

Кыйммәт-ле мехлы җәнлек

Башка, бүтән (иск.)

«... Газизә» (Таҗетдин Ялчыгол)

Монарх

Киле сабы

«Архи-пелаг ...» (Александр Солжени-цын)

... Терьян (әрмән шагыйре)

Гарәп хәрефе

Тотка

Кайнозой, мезозой

Скандина-вия халык-ларында батырлар турында хикәят

Конус рәвешен-дәге печән кибәне

Латвия акчасы

Очрак, мөнәсәбәт (иск.)

Гектар

Кубәю, ишәю

Гаскәри-ләрнең зур төркеме, полк (бор.)

Гармунның бер төре

«Иманнар тамыр җәйгәндә» романы авторы

Корбан (иск.)

... Базар (борынгы Болгардагы сәүдә, һөнәрчелек бистәсе)

Зур скрипка

Чулман-ның уң кушыл-дыгы

Мексика милли ризыгы

Хөсәен Ямашев чыгарган газета

Жанна д' ...

... Карнай (башкорт әдибе)

Рәис Габдулла төзеде.

4 нче санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:

Султан уңга: җилпуч, михраб, Ака, Ильяси, углан, «Олау», викинг, чирү, Лиепа, Галия, Ио, Атум, Броз, өмид, ки, лива, Урманче, Нәкый, Иркә, Моор, Еники.

Өстән аска: өленге, Луиза, ми, Ивик, җам, «Илиада», «Инсаният», Әйди, ләх, Ге, «Уку», Ра, Памир, Лука, чабагач, Ибраһим, луидор, Роу, «Ончыко», Нәүрүз, Әрә.

Казан Кремле.
1930 нчы еллар

«Безнең мирас»
елъязмасы / июнь

● 820 ел элек (1196)

Бөек Болгар дәүләтенең күренекле галиме, болгар-татар язма тарих белеменә башлангыч нигез салучы Якуб ибне Ногман «Болгар тарихы» дигән китап яза. Бу хакта галим вә сәяхәтче Әбү Хәмид әл-Гарнати язмаларында бәян ителә.

● 135 ел элек (1881)

Мәгърифәтче, гарәп теле белгече, гарәпчә-татарча сүзлек авторы Таһир Әхмәтҗан улы Ильяси (1881-1933) дөньяга килә.

● 130 ел элек (1886)

Җәмәгать эшлеклесе, мәгърифәтче, географ Нәҗип (Мөхәммәтнәҗип) Латыйф улы Хәлфин (1886-1937) дөньяга килә.

● 95 ел элек (1921)

5 июньдә Уфада Габдулла Тукай исемендәге клуб эшли башлый.

● 80 ел элек (1936)

22 июньдә Казанда күренекле тел галиме Гыйбад Алпаров (1888-1936) вафат була.

● 75 ел элек (1941)

22 июньдә Германия, Советлар Союзы чиген бозып, һөҗүм итә. Сугыш башлана.

● 60 ел элек (1956)

«Совет әдәбияты» журналында Абдулла Алишның концлагерьда һәм фашистлар төрмәсендә язылган шигырьләре дөнья күрә.

● 45 ел элек (1971)

19 июньдә Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында Фатих Кәрим музее ачыла.

27 июньдә «Социалистик Татарстан» газетасында Гомәр Бәшировның «Җидегән чишмә» исемле яңа әсәреннән өзек («Әтинең кадере») бирелә. ■

Фәрит Габдрахман улы Суюров 1939 елның 7 гыйнварында башкалабыз Казанда туа. Казан сәнгать училищесын (1962), Чуваш дәүләт педагогия институтын (1969) тәмамлый.
Фәрит Суюров – Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Бакый Урманче исемендәге премия лауреаты, Россиянең Рәссамнар берлеге әгъзасы.
Рәссамның әсәрләре Төркия, Голландия, Бөекбритания һәм Финляндиянең шәхси вә дәүләти тупланмаларында саклана.

Фәрит Суюров

(1939-2016)

Июль. 2013.
Кәгазь, пастель

Соңгы нур. 2008.
Кәгазь, пастель

ИГЪТИБАР! ИГЪТИБАР!
Хөрмәтле абунәчеләребез!
Журнал индексын каталогтан эзләп вакытыгызны югалтмыйча, турыдан-туры элемтә бүлеге хезмәткәрләренә мөрәҗәгать итә аласыз.

www.beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС» белән бергә булыгыз!

ИНДЕКС:
Татарстанда – П-2343
Россиядә – 70275

«Безнең мирас» журналына башкача язылу:
- *www.uslugi.tatarstan.ru сайты ярдәмендә*
- *редакциядә*
- *www.tatpodpiska.ru сайты ярдәмендә электрон версия*

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» (Бауман ур., 19; 29/11) кибетеннән, «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), Казан киоскларыннан сатып алырга мөмкин.

Безнең мирас №06 / 2016